

**Сафиуллина Рузания Касыйм кызы 1937 нче елның 10 нчы декабрендә Саба районы Кызыл Мишә авылында гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә.**

Хәзерге көннәрдә Бөек Ватан сугышы ветераннары бик әз калган. Ләкин алардан яшьрәк буынга сугыш тагын да зуррак тәэсир калдырган. Аларны сугыш чоры балалары дип атыйлар. Минем дәү әнием дә алар рәтенә керә. Сугыш чоры баласы буларак, бу авыр елларда үткән балачагы, аның күргәннәре турында үзе сөйләгән хәтирәләрен язасым килә.

Әтисе (без аңа “дәү бабай” дип дәштек)– Касыйм Нәгыйм улы, тегүче һәм Саба урманында умартачы була. Дәү әбиебез – Шаһимәрдан кызы Гыйльмениса колхозда фермада эшли.Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлануга, 1941нче елда ук, Касыйм бабай сугышка китә һәм шул елда ук әсирлекккә эләгә.

Сугыш башланганда дәү әнием әле 3 яшь ярымлык кына булган. Шуңа да ул бу елларны төгәл хәтерләми, бары шул чорның күңелендә сакланып калган кайбер күренешләрен искә алып сөйли. Ул вакытларны, башыннан кичкән вакыйгларны сорасаң, еш кына, тел белән генә әйтеп, аңлатып бетерә торган түгел, дип кабатлый .

Гаиләдә иң зур бала – Илһам абыйга сугыш башланганда 11 яшьләр була. Аннан кала 3 кыз: Нуршания, Мәдехия апайлар һәм дәү әнием. Сугыштан соң тагын 4 бала туа, икесе үлә. Бу дәһшәтле елларда, әтиләре сугышка киткәч, гаиләдә әнисенә төп таяныч, ярдәмче булып Илһам абый кала. Төп йортта әтиләренең әниләре Нәфисҗамал әби белән, аны да тәрбияләп яшиләр. Олы кызлар әниләренең кул арасына кереп, җиңелчә эшләрдә булышып үсәләр. Бу

вакытта, әле кечкенә бала булганлыктан, дәү әнием әнисе эштә вакытта күбрәк әбисе белән булуын, аның үзен аеруча яратып тәрбияләвен, кайгыртуын искә ала.Ачлык, мохтаҗлык михнәтләрен балалыгы белән бик тоеп бетермәсә дә, кычыткан, кузгалак җыеп, алабута ипиләре пешереп, чи бәрәңге ашауларын сөйли, бүгенге нигъмәтләрне күреп кат-кат шөкер итә.

Сугыш елларындагы авыр эшләр, ачлык, мохтаҗлык газаплары өстенә, кешеләр күңелендә сугыштагы якыннарын көтү, алар өчен борчылып яшәү, иң яманы – алардан кара хәбәр алу. Тылдагылар һәр көн сугыштан, уллары, ирләре, әтиләреннән бер хәбәр көтә... Кызыл Мишәгә дә андый хәбәрләр килеп тора. Дәү бабайдан озак кына хәбәр килми торганнан соң, хат ташучы кыз фронттан хат алып килә. Хәерле хәбәр: ул исән-сау! Кыскача үз хәлләрен тасвирлаган. Бу хат Гыйльмениса әбиемне бик сөендергәнен, хат ташучы кызга ире турында сөенечле хәбәр алып килгәне өчен кадерләп саклап кына токан матур ашъяулыгын бүләк итүен дулкынланып сөйли дәү әнием. Шулай ук бер вакыт дәү әнинең әбисе Нәфисҗамал әби дә бераз авырып, кәефсезләнеп китә. Озакламый ул бик матур төш күрә: пар күгәрчен өй кыегына очып килеп кунганнар. Берсе очып киткән дә яңадан килеп кунган. Шушы төштән соң әбинең күңеленә тынычлык иңгән, төшне матур итеп яхшы юраган: “Очып китте дә, яңадан килеп кунды, кайтыр балам, тигезлектә яшәрсез. Инде хәзер күңелем тыныч,” дигән. Бу вакыйгадан соң әби озак яшәми. Ә Касыйм бабай, чыннан да, 1945 нче елның җәендә бер кайтып килә дә, яңадан хезмәт итәргә китә һәм 1947 нче елда бөтенләйгә әйләнеп кайта.

Дәү әнием үзе 4 ел Кызыл Мишә урта мәктәбендә һәм 3 ел Тимершык урта мәктәбендә белем ала. Белем алу шартлары уртача булган.Математика фәнен аеруча яратып үзләштерүен сөйли. Әгәр дә белемен дәвам итү мөмкинлеге булса, дәү әнием, мөгаен, төгәл фәннәр буенча хисапчы яки шушы юнәлештәге башка бер һөнәрне үзләштерер иде. Ләкин ул елларда, әлбәттә, моның өчен мөмкинлекләр булмый.Мәктәптән кайткач, дәү әнием өй эшләре белән шөгыльләнгән. Кечкенәдән ул чисталыкны, тәртипне яратып үскән. Безгә дә бу



хакта бик еш искәртә, балачагыннан тырышып башкарган хезмәтләрен, уракка йөрүләрен сөйли.

Мәктәпне тәмамлагач, дәү әнием Мәскәү өлкәсенә торф чыгару хезмәтенә эшкә китә. Анда 6 ай дәвамында эшли һәм кире туган авылына кайта. 2 ел Лаеш районында һәм Сабабашта урман кисә. Соңрак колхозда сыер савучы, яшелчә үстерүче булып эшли. Пүкәл авылына килен булып төшкәч, колхозда төрле эштә эшли, соңрак 14 ел бригадир булып, 9 ел сөт җыючы булып эшли. Үзенең башкарган хезмәтләре өчен Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышы илебезгә китергән афәт беркемне дә аяп узмаган. Ул күпләрнең гомерен, яшьлеген, ваемсыз балачагын урлаган, һәлак иткән. Дәү әнием дә сугыш һәм аннан соңгы елларның авырлыгын, күңелгә салган тирән яраларын онытмый. Бүгенге көнебезне шул чорлар белән чагыштырып, безне гел шөкер итеп яшәргә өйрәтә.

*Касыйм Сафиуллин, Эзмә урта мәктәбенең 9 сыйныф укучысы.*



**Багаутдинов Харис Борхан улы 1936 нчы елның 21 нче сентябре көнне Буа районы Суыксу авылында туган.**

Харис абый сөйләгәннәрдән: Шулай әйбәт кенә үсеп килгәндә, 1941нче елны сугыш башланды . Миңа ул вакытта 5 яшь иде. Без семьяда 5 бала – 3 кыз, 2 ул үстек. Мин кечкенә булуым сәбәпле, сугышны башта ныклап аңлап та җиткермәгәнмен, мәктәпкә укырга кергәндә инде ныклап аңлый башлаган идем.

1943 нче ел. Сугыш бара,ашарга юк, киемнәр иске. Гаилә тоткасы булган әтиебез сугышта, без әни янында 5 бала тәрбияләнәбез. Ул вакытларда кышлар да үтә суык була торган иде, мичкә ягарга утын да юк . Шуның өстенә үзебездә булган аз – маз ашамлыкны да фронтка дип җыялар иде. Әнинең “Нәрсә ашатыйм инде бу балакайларыма“,- дип елап утырганнары әле дә күз алдымда тора. Яз көне черек бәрәңге, ә җәй житсә, кычыткан ашлары (аңа азрак сөт кушып) пешереп бирәләр иде. Иске эскерт урыннарыннан төрле чүп, алабута орлыгы алып кайтып тартып, аннан ипи пешерәләр иде. Ул күгәргән булу сәбәпле, без гаиләбез белән агуланып, чак кына үлми калдык. Өйгә ягарга утын да юк иде, аны җылытыр өчен салам яга идек.

Сугыш беткәч, әти район үзәгенә самолет белән кайтып төште. Ул вакытта анда аэродром бар иде. Район үзәгеннән колхоз рәисләре аны, атка тарантаслар җигеп барып, алып кайттылар. Без, биш бала тезелеп, урамда әтине каршылаган чагым истә әле. Безнең ябык, хәлсез булуыбызны күрү әтигә бик авыр булды инде. Сугыштан соң, бик авырлык белән генә булса да, тормышлар акрынга җайлана барды .

Буа ветеринария техникумына укырга кереп, аны 1960нчы елда тәмамлагач, Саба районына ветеринария врачы булып эшкә кайттым. Шул ук вакытта, читтән торып, Казан Дәүләт ветеринария институтын тәмамладым. Эшләү дәверендә 35 студент минем кул астында производство практикасы үтеп, минем эш тәҗрибәсен өйрәнделәр. 42 ел буе шушы яраткан эшемдә эшләп, 2001нче елның июль аенда лаеклы ялга чыктым.

Хөкүмәтебез хезмәтемне югары бәяләде. Һәр елны диярлек мактау грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләндем:

- В.И.Ленинның тууына 100 ел уңаеннан “Фидакарь хезмәте өчен” медале;
- ТАССР президиумы указы нигезендә “Хезмәт ветераны” медале;
- ТР президиумы нигезендә Татарстан Республикасының Мактау грамотасы;
- Татарстан ветеринария тарихы китабына кертелгән.

Хәзерге көндә хәләл җефетем Кәфия белән тигезлектә яшәп, һәр туган көнгә шатланып, гомер итәбез. Кызларыбыз, кияүебез, оныгыбыз кайтып хәлебезне белеп, эшләребездә ярдәм итеп торалар.



**Нурисламов Мәсгуть Нурислам улы 1935 нче елның 12нче апрелендә Саба районы Эзмә авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

1941 нче ел 22 нче июнь. Сызылып кына таң атып килә. Табигатьнең иң гүзәл чагы. Үләннәргә саф чык тамчылары яткан, агач-куаклар үзләренең матур чәчәкләре белән бизәлгәннәр. Авыллар тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенынына кереп яткан нәни сабыйлар, тәмле төшләр күреп, изрәп йоклаган чакта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып, авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоталар. Бөек Ватан сугышы башлана. Авылның төп көче булып, үсмер кызлар,малайлар кала.

Авылдашыбыз Нурисламов Мәсгуть абый бу елның тере шаһите. Әтисе Нурислам колхозда бригадир һәм комсомол җитәкчесе, ә әнисе колхозда эшли. Гаиләдә 4 бала-3 малай, 1 кыз була. Нурислам бабай сугышка китә.

Сугыш башланганда бабаема 6 яшь кенә була. Бабаем энекәшләрен ияртеп, урманнан бәләкәй арба белән утын алып кайткан, тамак туйдыру өчен болыннан ашарга яраклы үләннәр җыйган. Шул ук вакытта малларын туендыру өчен печән ташыганнар.

1941 нче елның җәендә аларга бик авыр булган. Сугыш башланып 4-5 ай үтүгә, этиләренең югалган хәбәре килгән. Бу вакытта күпме михнәт, кайгы кичерергә туры килгәнен үзе генә беләдер.

Мәсгуть абый әнисенә ярдәм итәр өчен ат абзарына төшкән, ат җигеп, тырмага йөргән, бәрәңге басуыннан черек бәрәңге җыеп, өзелгән тамакларын ялгаганнар. Язгы чәчү вакытында, картлар тубал белән чәчү чәчкәндә, аларга юл күрсәтүче хезмәтен үтәгән. Урып-җыю вакытында калган башакларны җыеп, колхозга тапшырган, шуның өчен үзенә хезмәт көне ала торган булган.

Мең төрле газап, кыенлыклар белән бер ел үтә. Мәсгуть абыйның укырга керер вакыты җитә. Мәктәп кирәк-яракларын алу өчен, урманнан куак чикләвеге җыеп, аны Шәмәрдәндә саткан һәм китап-дәфтәрләр алган...

Җиңү җырын, «Без җиңдек, җиңдек!»-дигән шатлыклы хәбәрне ул авылда каршылаган. Никадәр сөенеч, шатлыклы күз яшьләре түгәргә туры килгәндер аларга бу минутларда... Сугыш тәмамлангач та, ул кешеләргә файда китерергә омтыла, сугыш китергән авырлыкларны җиңүдә зур көч куя ул.

Мәсгуть абый бик яшьли механизатор булып эшли башлый. Аның авыл хуҗалыгы өлкәсендә югары күрсәткечләр белән эшләве – үзе зур батырлык. Республикабызның уңышларга ирешүендә авылдашларыбызның һәм Мәсгуть абыйның да өлеше бар. Тырыш хезмәте өчен аны ТАССР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтәләр, сайлаучылар аның өчен тавыш бирәләр. Ул барлык тырышлыгын, көчен халыкның тормышын, көнкүрешен яхшыртуга багышлый. Юлларны төзекләндерүдә, торак йортлар, мәктәпләр, клублар салу буенча күп эшләр башкарыла. Урып-җыюда, терлекчелектә күрсәтелгән план арттырып үтәлә. Бу нәтиҗәләр барысы да җитәкчелек тарафыннан югары бәяләнгән: ул дипломнарын, грамоталарын кадерләп саклый.

Күпме михнәт күрсә дә, һәрбер кайгы аның ягымлы йөзендә җыерчыклар калдырса да, ул һаман сабыр холыклы, яхшы киңәшләр биреп торучы кеше. Аның теләкләре изге: «Дөньяда тынычлык хөкем сөрсен, һәрбер көнебез бәхетле, шатлыклы булып узсын. Күк йөзен каплап алган кара болытлы көннәр башка була күрмәсен, балаларга ятимлек ачысын татырга туры килмәсен, булмасын сугыш!»

Хәзер Нурисламов Мәсгут абый - мәктәптән кайткан оныкларын «бәбкәм» дип сөйкемле карашы белән каршы алучы. Без аның һәрвакыт елмаеп торуын , киңәшләрен биреп, авырмыйча, озак еллар яшәвен телибез.



## Мөхәммәдиев Рим Шамил улы, 1940нчы елның 7нче гыйнварында Иләбәр авылы колхозчы гаиләсендә туа.

Сугыш беткәндә аңа биш яшь була. Әмма ул авылда кешеләр җыелып сугыш бетүе турында сөйләгәнне хәтерли. Сугышта аның гаиләсеннән берсе дә катнашмаган.

Мәктәптә 7 класс белем ала. Аннары ата-анасы белән колхозда эшли. Өч ел армиядә хезмәт итеп кайта. Армиядән кайткач авылдагы җитен комбинатына эшкә урнаша. Бераз вакыт узганнан соң гаилә корып җибәрә. Алар тормыш иптәше Алмазия апа белән өч бала тәрбияләп үстерәләр. Аның бик яшьли хатыны вафат була һәм ул өч баласын бер үзе тәрбияли. Ике малае Ришат һәм Рифат,бер кызы Резеда. Аның балалары хәзерге көндә барысыда үзләре гаиләле. Бүгенге көндә ул Рифат абый тәрбиясендә. Мин Рим бабай белән һәркөнне диярлек күрешеп торам. Ул бик ачык йөзле, яхшы бабай.



*Инсаф Әскәров, Эзмә урта мәктәбенең 9 сыйныф укучысы.*

**Әхтәмов Тимершаех Әхтәмҗан улы 1941 нче елның 25нче ноябрендә Иләбәр авылында дөньяга килгән.**

Әтисе Әшрәфҗанов Әхтәмҗан (1907нче елның 30нчы октябрендә туган) сугыш башлангач та фронтка киткән. 1948 елда исән-сау әйләнеп кайта. 1998нче елның 2нче февралендә вафат булган, шушы авыл зиратында җирләнгән.

Әнисе Әшрәфҗанова Гөлбану Минһаҗетдин кызы (1912 нче елгы)- колхозчы.

Сугыш еллары Тимершаех абыйның нарасый чагына туры килә. Күбесе хәтердә дә калмаган. Тик ашарга, кияргә булмау, чи утынның янмыйча азаплавы беркайчан да онытылмас.

Бервакыт урамда бик күп кешеләрнең җыелып сөйләшеп торганнарын, аларның сүзләре сугышның бетүе турында икәнен ишетә. Шатланып, этисен көтә. Тик күрешү мизгелләре бик озак көттерә, Әхтәмҗан абый , пленда булу сәбәпле, 1948 нче елда гына кайта.

Тимершаех абый Әхтәмов 7 яшендә этисе сугыштан кайтканда мәктәпкә укырга кергән була. Иләбәр авылындагы башлангыч мәктәптә 4 ел Габдулла абый Раков һәм Нәсимә апалардан белем ала.

Авыр еллар... Мәктәп еллары... “Барлык предметка да бер уртак дәфтәр иде. Анысын да бик авырлык белән генә юнәтә торган идек. Мәктәптә хәзерге шикелле туклану оештырылмаган. Биштәребезгә өйдә ипи булса, тыгып алып барабыз, булмаса, ач йөрергә мәҗбүрбез. Өйгә кайткач, йорт эшләрендә булышабыз, тирес түгү, бакча эшкәртү, печән чабу кебек эшләр бар да безне көтеп тора”,- дип искә ала Тимершаех абый. Укуын Эзмә мәктәбендә дәвам итә, 7 классны бетерә. Ә 8 нче классны кичке мәктәптә укый. Шуннан бирле колхозда терлекчелектә төрле эш башкара: ат җигеп, терлек азыгы кертү, иген игү, тракторда эшләү. Тырыш хезмәтен бәяләп, төрле мактау кәгазьләренә ия булган, шуларның берсе – 5 нче 9еллыкка бирелгән.

Иләбәр кызы Әлфинур апа белән Тимершаех абый бераз очрашып йөргәннән соң 1973нче елның 13 нче маенда гаилә корып җибәрәләр, гөрләтеп, заманына күрә хәлле генә туй үткәрәләр. 4 бала: 2 кыз, 2 малай үстерәләр. Олы кызлары Зөлфирә – Сәрдә авылы килене, терлекчелектә алдынгы сыер савучы, Әлфирәләре Сабада кибетче, уллары Марат һәм Инсаф икесе дә Ватан алдында торган бурычларын үтәп кайтканнан соң туган районнарында хезмәт куялар.

Бүгенге көндә Тимершаех абый белән Әлфинур апа үзләре корган нигездә тигез гомер итәләр. Балалары, 6 оныклары янәшәсендә, аларның кайгыртуын тоеп, пар күгәрченнәр кебек чөкердәшеп яшиләр.



Тимершаех абый  тормыш иптәше Әлфинур апа белән.



**Ханнанова ( Рамазанова) Бүләк Хөсәен кызы 1933 нче елның 8 нче октяберендә Пүкәл авылында эшче гаиләсендә туганмын.**

Бүләк апа сөйләгәннәрдән: Әнием Мәликә, Әтием Хөсәен исемле иде. Кызганыч, әни тәрбиясендә генә яшәргә туры килде миңа. Мәктәптә барлыгы 4 класс белем алдым .

Сугыш башланганын әнидән ишетеп белдем . 12 яшемдә артельгә эшләргә кердем. Ашау һәм киенү яклары уртача булды. Буш вакытларда дуслар белән төрле уеннар оештыра идек. Сугыш беткән дигән хәбәрне авылдашлардан ишетеп белдем .

1955нче елның 25 августында кияүгә чыгып , бер малай , бер кыз тәрбияләп үстердек. Үз эшемә тугырылыклы булып, Шәмәрдән промкомбинатында 43 ел тегүче булып эшләдем. Мактау кәгазьләрем бик күп. “Хезмэт ветераны” дигән исемем дә бар.

Хәзергесе көндә Пүкәлдә кызым тәрбиясендә гомер кичерәм.

**Гафурова Тайфә Заһидулла кызы, 1938 нче елның 2нче мартында Саба районы, Олыяз авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Әнисе Хәдичә, әтисе Заһидулла фермада хезмәт куйганнар. Тайфә апа 4 класс кына белем ала алган. Сугыш башланганын әти-әнисеннән ишеткән. Тормышлары авыр булган, кычыткан, кәбестә, черек бәрәңге ашаганнар. Кызлар, егетләр белән аралашмаган, ата-ана хакын саклап, аларны тәрбияләп, кияүгә чыкмаган, балалар үстермәгән.

Сугыштан Миннегали, Хәкимулла абыйлары исән – сау әйләнеп кайта. Котдус абыйсын да озаталар, ул бер аяксыз кала. Ул пленда була, анда ашарга булмаганлыктан, бакалар белән тукланганнар. Сугыш беткәч, бөтен авыл шау итте. Сугыштан соң да ачлык була, акчалар юк, алабута ашыйлар. Тайфә апа көнне төнгә ялгап фермада эшләгән. Җилкәсенә күтәреп салам ташыган, бозау көтүе дә көткән.

Бүгенге көндә ялгызы яши. Һәр көн иртән күршесе Мөдәрис кереп хәлләрен белеп чыга.



**Гыйләҗиев Тимершаех Гыйләҗи улы 1935 нче елның 1 нче апрелендә Саба районы Өтернәс авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.**

Өтернәс башлангыч мәктәбендә 4 сыйныф белем ала. Сугыш башлану турында багана башындагы радиодан ишеткән. Ашарларына булмау сәбәбле, ул 1 ел укуыннан туктап торырга мәҗбүр була, кияргә дә киемнәре калмагач, алар сыерларын саталар. Сугыш вакытында, кар астыннан чыккан башакларны, өшегән бәрәңгеләрне һ.б пешереп ашаганнар. Сугышка әтисенең беренче хатыныннан туган Гәрәфетдин абыйлары китә. Сугыш вакытында аягы өшетеп, бармакларын кискәч, ул өч айга өйләренә кайтып тора һәм кабат сугышка китә.

Әтиләре инвалид булу сәбәбле, аны сугышка алмыйлар. Алар гаиләдә алты бала булалар. Аларның иң олы апалары 1926 нчы елда туган, ул әнилэре белән бергә колхозга эшкә йөргән. Урак уралар, ашлык сугалар, көрәк белән бәрәңге казыйлар. Сугыш вакытында- өч туганнары ачка үлә. Сугыш беткәндә өч туганнары гына исән кала. Абыйлары сугыштан кире әйләнеп кайтмый, сугышта хәбәрсез югалды дигән хәбәре генә килә.

1962нче елда гаилә кора. Саба районында Хөсәен кызы Бәлхия белән алар 4 бала үстерәләр, 1 ул һәм 3 кыз. Хезмәт юлын колхозда дәвам итә. Башта колхоз көтүен көтә. 1954-1957 нче елларда совет армия сафларында хезмәт итә. Туган авылына әйләнеп кайткач, ул колхозда маторист булып хезмәт итә башлый. 1961 нче елда Тенеки совхоз техникумына читтән торып укырга керә. Аны тәмамлагач, җәй көненнән башлап 1 ел колхоз умарталыгында хезмәт итә. Кыш җиткәч, яңадан маторист булып эшли. 1971нче елдан кладовщик булып билгеләнә һәм 1985нче елга кадәр шунда хезмәт күрсәтә. 1985нче елда склад мөдире булып эшли башлый һәм 1997нче елга кадәр шунда эшен дәвам итә. Шуннан соң аны лаеклы ялга җибәрәләр һәм шул ялга киткәндә аңа “Атказанган колхозчы” исеме бирелә. Хәзерге көннәрдә ул төпчек кызы Рамилә гаиләсе белән яши.



**Әскәров Энгелис Габдрахман улы**
**1933 нче елның 26 нчы сентябрендә**
**Саба районы Өтернәс авылында**
**колхозчы гаиләсендә туа.**

Энгелис абый сөйләгәннәрдән:

Мин башлангыч белемне Өтернәс мәктәбендә Әһмәдиев Кәрим абыйдан алдым. 4 ел гыны укытып калырга өлгерде ул безне. Бөек Ватан сугышы башланып, аны сугышка алдылар.Бу вакыт аралыгында төрле укытучылар белем бирде безгә.Хәзер инде мин аларның исемнәрен хәтерләмим.Тиздән, Кәрим абый яраланып кайтып, янәдән безне укытуын дәвам итте .

Сугыш башланган дигән сүзне урамга чыккач кешеләрдән ишеттем мин. Миңа ул вакытта нибары 8 яшь кенә иде шул әле. Балалык белән “сугыш” дигән сүзнең асылын бәлки аңлап та бетермәгәнбездер.Һәр сугыш чоры баласына хас булганча, балачак тормышы шуның белән тәмамланып, авыр тормыш арбасын сөйрәп бару авылда калган карт-коры, хатын-кыз һәм без балаларга калды.Ындыр табагында ашлык суктыра торган 6 ат җигелгән барабаннар бар иде. Мин дә калган малайлар

“ Сугыш
чоры балалары”

“Баш иябез
Бөек елларга”

белән шунда ат куарга йөрдем.Аннан яз җитү белән үгез җигеп, басу тырмаларга да йөрергә туры килде әле. Бар эшне дә балаларга авылда калган бер-ике өлкән кеше өйрәтте.

Минем әти балачакта бик каты кызамык белән авырый. Шуннан аның бер күзе сукырая.Аннан колхозда житен талкыганда уң кулының бармакларын машинага кыстырып өздерә ул.Шул сәбәпләр аркасында аны сугышка алмадылар. Бәлки бу безнең бәхеткә дә булгандыр. Сәламәтлеге булмаса да,безнең әти бик тырыш кеше иде, җитәкче эшләрдә дә эшләде.1929 нчы елда колхозлар оешып, “Калатау” колхозының беренчне председателе дә ул була. Олыгайгач тимерче булып эшли.

Сугышка безнең өйдән китүче булмады.Олы бала өйдә мин, миннән кала 3 энем һәм бер сеңлем бар иде. Гаиләдә 5 бала идек.

Сугыш беткән дигән сүзне урамда кешеләрдән ишеттем . Сугыш беткәч авыллар бераз җанланып китт. Акрынлап сугышка киткән авылдашлар кайта башлады. Иң беренчеләрдән булып Гафур Корбанов, Шәвәли Тимергалиевлар кайтты . 1952 нче елда армия сафларына алындым. 3 ел хезмәт итеп, 1955нче елда армиядән исән- сау туган якка әйләнеп кайттым. Армиядән кайткач та, туйганчы ипи ашый алу бәхетен тиз генә татый алмадым әле мин.1957 нче елның 17нче ноябрендә Пүкәл авылының бик тырыш, уңган кызы Назифа белән тормыш корып җибәрдек. 1959нчы елда беренче кызыбыз Рәзифә туды, Резедабыз тугач яңа йорт җиткереп чыктык.

Барлыгы биш балабыз: 2 малай һәм 3 кызыбыз булды. Ни кызганыч, 2010 нчы елда 50 елдан артык бергә гомер иткәннән соң, тормыш иптәшем Назифа вафат булды.

Хезмәт юлымны 1955 нче елдан тимерче булып башладым. Ә 1966 нчы елда Олыяз авылына токарь булып дәвам иттем. Лаеклы ялга чыкканчы “Киров” исмендәге колхозда шул хезмәттә булдым. Хезмәтемне хөрмәтләп, 1988 нче елда “Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы” исеменә лаек булдым. Шулай ук “ 3 нче дәрәҗәдәге хезмәт даны орден”ы, хезмәт ветераны исемнәре белән бүләкләндем. Ә мактау грамоталарымның саны исә, дистәдән артып китә.

Хәзерге вакытта барына да шөкер итеп, төп нигездә гомер кичерәм. 5 балам, 7 оныгым, 6 оныкчыгым хәлләремне һәрвакыт белеп торалар.



**Нигъмәтҗанова (Исламова) Мөслимә Ислам кызы 1942 нче елның 2нче гыйнвар көнендә Саба районы Олыяз авылында колхозчы гаиләсендә туган.**

Әбием истәлекләреннән:

“Сугышның нәрсә икәнен белмәдем. Аңлый башлагач кына әнинең әтине сугышка озатканын, әтинең сугыштан кайтмаганын белдем. Мин гаиләдә 2 нче бала булып туганмын. Абыем Миннисламов Кәшиф 1938 нче елгы. Аның мина әтинең кая киткәнен аңламыйча “мин хәзер кайтам”,-дип битеннән үпкәнен сөйләгәне бар. Ләкин әти кайтмаган.

1949 нчы елда Олыяз башлангыч мәктәбенә укырга кердем. Башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, Эзмә урта мәктәбендә 5 нче класста белем алдым. Тормышлар авыр, ягарга, ашарга, кияргә булмаганлыктан, мин укуны дәвам итә алмадым. Эзмә мәктәбенә йөргәндә аякта күтәртмәле чабата булды. Ипи ашаган балаларны күрсәм кызыга идем. Әни безне ач-ялангач итмәс өчен тырышты. Кычыткан ашы ашаганны хәтерлим. Черек бәрәңге күмәче ашадык. Без басу янында торганлыктан, күрше кызы белән черек бәрәңге җыярга чыга торган идек. Әни чи бәрәңге кырып ипи пешереп ашата иде, әзерләп эшкә киткән вакытында үземә дә пешерергә туры килде. Ашарга булмагач, бераз кием-салым алу, акча эшләү уе белән әни, безне әби белән бабайга калдырып, торфта эшләргә китте. Анда 1 елга якын эшләп кайтты. Безгә аннан күлмәк белән галош алып кайтканын хәтерлим. Аннан соң үзем дә колхоз эшенә чыга башладым. Сарык фермасында эшләдем, таналар карадым, кул көче белән сыер саудым. Малларга азыкны җилкәгә куеп ташыдык. Кич белән тау башыннан олырак кызларның уеннарын карарга бара идек. Шул вакытта бераз булса да арыганнар онытылып тора иде.

1965 нче елның февраль аенда Пүкәл авылына килен булып төштем. 2 кыз, 2 малай үстердек. Лаеклы ялга да сөтчелек фермасында эшләп чыктым. Бүгенге көнемнән мин бик канәгать. Без күргән ачлык-ялангачлыкны сез күрергә язмасын. Рәхәт вакытта тормышның кадерен белегез. Тыныч тормыш кына булсын!



**Фәйзрахманова (Шакирова) Миннегөл Мөхәммәтгали кызы Саба районы Өтернәс авылында 1935 нчы елның 21 нче гыйнварында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.**

Әбием сөйләгәннәрдән:

Әнисе Минневафа, әтисе Мөхәмматгали исемле. Алар гаиләдә өч бала үсәләр, әбием беренче була. Ул бары тик дүрт класс белем ала, аннары эшли башлый. Аңа 6 яшь булганда сугыш башланган. Әтисе 1941нче елда сугышка китә һәм әйләнеп кайтмый, хәбәрсез югала. Әнисе өч бала белән бер үзе кала.Әбиемә сугыш елларының ачлыгын да, ялангачлыгын да күрергә туры килә. Яз көне черек бәрәңге җыеп аны пешереп ашаганнар. Җәй айларында кузгалак, алабута, балтырган кебек үләннәр ашаганнар. Ипине дә ул вакытта талонга гына биргәннәр. Өсләренә киярга кием-салым булмаган. Аякларында чабата булган.

Әбием сугыш беткән дигән сүзне мәктәптә ишетә. Сугыш беткәч тә әле җиңеллек килми. Әбиемә 13 яшь вакытта әнисе дә үлеп китә. Ул дүртенче классны тәмамлаган ел була. Шуннан сон инде әбием укуын башкача дәвам итми. Чөнки энесе белән сеңлесен аякка бастырасы була. Колхозга эшкә чыга. Ул зурлар белән бер рәттән басуга эшкә йөри. Кечкенә генә булуына карамастан, урак урган, көлтә бәйләгән. Шул көлтәләрне атларга төяп амбарларга ташыганнар. Амбарда ашлык сукканнар. Яз көне Бөгелмәдән чәчүлек орлык ташыганнар.

Алар 1957 нче елны бабабыз Фәйзрахманов Гыйльмулла Заһидулла улы белән гаилә корганнар. Аларның гаилә корып яши башлауларына быел 59 ел була. 2007 нче елда алар алтын туйларын билгеләп үттеләр.

Әбием белән бабаем 5 балага гомер биргәннәр. Бүгенге көндә 3 кызлары исән-сау. Аларга белем, тәрбия биреп, олы тормыш юлына бастырганнар. Алар 6 оныкның һәм 2 онықчыкның сөекле әбисе-бабасы булып яшиләр.

*Алинә Нәбиуллина, Эзмә урта мәктәбенең 8нче сыйныф укучысы.*



**Сәетгәрәева ( Фәхертдинова) Хәербанат Фәхертдин кызы 1934 нче елның 25 нче декабрендә Саба районы Сәрдә авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Әбием 3 ел башлангыч белем ала.

Сугыш башланганда әбиемә 6 яшь булган. Әбиемнең әтисе дүрт баланы калдырып сугышка киткән. Авыр еллар, ачлык- ялангачлык, берсеннән -берсе кечкенә дүрт бала, бу авырлыкларны әбиемнең әнисенең йөрәге күтәрә алмый күрәсең, 1943 нче елда вафат була. Әбиемнәр дүрт кыз бала ятим калып, бик күп кыенлыклар күреп, кешедән- кешегә йөреп үскәннәр. Аларның ашарларына, киярләренә булмаган. Черек бәрәңге, алабута орлыгыннан ипи пешереп, кычыткан ашап үскәннәр. Алабута, ат кузгалагы орлыкларын җыйганда кечкенә кулларыбыз канап бетә иде дип сөйли әбиебез. Әбинең әтисе Фәхертдин бабай сугыштан исән- сау кайта. Кайткач өйләнә, әбиебез үги әни тәрбиясендә яши. Сугыш тәмамлангач, әбием комбайнер, трактористка ,плугар булып эшләгән, кул белән урман кискән. Урман кискәндәге пычкы яралары әбиемнең кулында һаман саклана.

1952- 1953 нче елларда Үрнәк совхозындагы училищеда укыган. Әбием һәр өлкәдә дә үзен тырыш, уңган итеп күрсәткән.

Эштән арып кайтуга карамастан, әбиемнәр клубларга чыгып, кичке уеннар уйнаганнар, спектакльләр куйганнар, мәдәни чараларда актив катнашканнар. Тормышлары авыр булса да, яшь вакытлары бик күңелле узган. 1 нче, 9 нчы Май бәйрәмнәрендә иске галошларын йомырка агы белән сөртеп, ялтыратып, өсләренә матур күлмәкләрен киеп урам йөргәннәр.

Әбием 1959 нчы елның бик матур 8 март көнендә Олыяз авылына бабаем гаиләсенә килен булып килгән. Әбием башта төрле эшләрдә, фермада, аннан соң

балалар бакчасында җыештыручы булып эшләгән. Бабаем белән бик тату, дус, үрнәк гаилә булып яшәп, дүрт кыз, бер малайга гомер биргәннәр. Кызганыч, әбиемнең йөрәгенә авыр яра салып, туып кырык көн торгач малайлары үлеп китә. Дүрт кызны үстереп, олы тормыш юлына бастыралар. 2003 нче елда кырык дүрт ел иңне- иңгә куеп яшәгән бабаемны әбием соңгы юлга озата.

Бүгенгесе көндә әбиемнең сигез оныгы, өч оныкчыгы бар. Әбиебез безнең янда кызы белән кияве тәрбиясендә яши.

Мин күп авырлыклар күргән чал чәчле әбиемне бик яратам. Аның күргән авырлыклары алдында баш имичә, бүгенге көнгәчә исән- сау яшәве белән горурланам, аның алдында баш иям, рәхмәт әйтәм. Безне шушы рәхәт тормышка алып чыгу өчен әбиемнең кечкенә генә куллары күпме авыр ир- ат эшләре башкарган бит. Әбиемнең тагын да озын- озак еллар безнең арада гомер итүен телим!

*Инзилә Шаһабиева, Эзмә урта мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы.*



**Яхин Нәҗип Яхъя улы 1933 нче елның 25 нче гыйнварында Иләбәр авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.**

Иләбәр башлангыч мәктәбендә белем алган. Сугыш башланганын әтисеннән белә. Печән җыерга төшкән җиреннән әтисе сугыш башланды, улым, әйдә кайт, мин сугышка китәм дигән . Әтисе, Идрис исемле абыйсы, әтисенең энесе сугышка киткән. Туганнары берсе дә әйләнеп кайтмаганнар.

Сугыш беткәндә бабайга 12 яшь була. Бөтен дөнья шау иткән, сугыш беткәнен радиодан ишеткәннәр. Гомер буе колхозда эшләгән. Лаеклы ялга чыкканда рәхмәт хаты белән бүләкләнгән.

Нәҗип абый Нажия апа белән тормыш корып җибәрәләр. Аларның бер-бер артлы 7 балалары дөньяга килә, 5 кыз, 2 малай. Кайгы җиле аларның да ишекләрен шакый, бабайның яраткан хатыны, балаларның газиз әниләре каты авыртудан соң вафат була . Эзмә авылыннан яшь кыз Миннегөл апа әни булып килә. Ул җиде баланы да үз итеп, аларга тормышны өйрәтеп, тату гаилә булып яшиләр. Балалар да Минөгел апаны әни дип йөртәләр, эшләрендә булышалар. Нәҗип бабай белән Миннегөл апа җиде баланы башлы – күзле итеп олы тормыш юлына аяк бастыралар. Балалар да эти-әниләренең фатихалары белән тату тормыш итәләр. Әби белән бабай тату гына картлык көннәрендә яшәп ятканда, кинәт кенә авыртып, 80 яшендә Миннегөл әби дәякты дөньядан китеп бара. Бабай бер ялгызы кала. Балалары кайтып бабайга кадер - хөрмәт күрсәтәләр, өйләрен тәртипкә китерәләр.

Бабай күрше тирәсенә, балаларга үрнәк . Чисталыкны ярата, саклый, кешегә акыллы киңәшләрен бирә. Аңа исәнлек-саулык телибез.

*Ләйсән Әхмәтшина, Эзмә урта мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы.*



**Газизуллина Хәлимә Хәлил кызы Саба районы Олыяз авылында 1939 нчы елның 18 нче ноябрендә дөньяга аваз сала.**

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башланганда аңа нибары 2 яшь була. Сабый бала булганлыктан бу куркыныч вакыйга башлануын ул аңламый да кала. Ләкин аларның гаиләсендә балалар ишле булганлыктан әниемә бала назы,бала игътибары эләкми. Моңа, әлбәттә, шушы ачы сугышның да этәргече зур була.

1947нче елны, Олыяз башлангыч мәктәбенә укырга керә ул.1951 нче елны аны тәмамлап,Эзмә җидееллык мәктәбенә укырга төшә.Шушы мәктәпне тәмамлагач,Шәмәрдән урта мәктәбенә 8нче класска укырга йөри башлый.1957 нче елны бу мәктәпне тәмамлагач,элемтә бүлеге белгечлеге буенча училищега укырга керә.Аны тәмамлагач, районның төрле авылларындагы почта бүлегендә почта начальнигы вазыйфасын башкара.

1965 нче елны алар этием Фәрит белән матур гаилә корып җибәрәләр.Тормышка чыккач,әнием хезмәт юлын сыер савучы булып дәвам итә. Ә 1966 нчы елның 1 июнь балаларны яклау көнне аларның гаиләләрендә беренче балалары-кызлары Венера дөньяга аваз сала. Бер-бер артлы тагын ике кызлары туа.

Фермада эш гаять авыр булуына карамастан,хезмәттә сынатмый әнием.Эшен яратып башкара , иртән иң тәмле йокы вакытында кояш белән торып, сөтбикәләре янына ашыга ул.



Ударник пятилетки медале,мактау кәгазьләре,дипломнар - әниемнең матур хезмәт нәтиҗәсе.

Хәзерге көндә этием Фәрит белән матур гына гомер кичерәләр. Кызлары-кияүләре оныклары һәрвакыт хәлләрен белеп торалар. 2015 нче елның көзендә ,эти белән бергә парлы гомер итүләренең 50 еллыгын бәйрәм иттеләр .

*Язманы кызы Лидия Әхәтова әзерләде.*



-

**Газизуллин Фәрит Шәрип улы 1938 нче елның ямьле август иртәсендә Саба районы Олыяз авылында дөньяга килә.**

Сугыш башланганда аңа нибары 3 яшь була. Дәһшәтле сугыш еллары бала вакытына туры килгәнлектән аңа иркәләнеп утырырга туры килми. Сугышның нинди ачы хәсрәт икәнлеген нәни йөрәге белән төшенә

Бөек Ватан сугышы тәмамланганда аңа нибары 8 яшь була. Шул ук елны әти Олыяз дүртьеллык башлангыч мәктәбенә укырга керә.

1951 нче елда башлангыч мәктәпне тәмамлап, Эзмә җидееллык мәктәбенә укырга төшә. Аны 1953 нче елда тәмамлый. Урта мәктәптә укуны дәвам итәргә туры килмәгән әтигә,колхозда атлы эштә эшли башлаган. 1957 нче елда Үрнәк бистәсендә урнашкан механизаторлар әзерләүче курсларга укырга кергән. Аны тәмамлагач, чирәм җир эшкәртергә Казахстанга китә .

Ел ярым эшләгәннән соң,аны армия сафларына алалар. Анда 8 ай укыганнан соң, Украинаның Винница шәһәрендә радист-кодировщик булып хезмәт итә. Барлыгы 3 ел хезмәт итә ул. Армия срогы тәмамлангач, 1962 нче елның ноябрендә хезмәт срогын тутырып кайта. Аннан кайтканнан соң, Шәмәрдәндә радиолелейная линиядә эшли башлый.

Урта белемне ул 1963-1967 нче елларда Шәмәрдән урта мәктәбенең кичке бүлегендә укып тәмамлый.

1965 нче елны алар әнием Хәлимә белән матур гаилә корып җибәрәләр. Ә 1966 нчы елның 1 июнь балаларны яклау көнендә аларның гаиләләрендә беренче

балалары-кызлары Венера дөньяга аваз сала. Бер-бер артлы тагын ике кызлары туа.

1967 нче елга кадәр дезилист-машинист булып эшли. 1969 нчы елда отпускада авыл хуҗалыгында комбайнёр хезмәтен дә яратып башкара әле ул. 1967нче елдан 1981 нче елга кадәр радист-машинист хезмәтен үти. 1981 нче елдан башлап, өлкән электромеханик булып 2011 нче елның 1нче июленә кадәр эшләп, лаеклы ялга китә. Бер урында барлыгы 48 ел эшли. Эшләгән хезмәтенең матур нәтиҗәләре дә бар. Мактау кәгазьләре, Хезмәт ветераны медале - шул турыда дәлилләр.

Әтием хәзерге көндә әнием Хәлимә белән матур гына гомер кичерәләр. Кызлары-кияүләре, оныклары һәрвакыт хәлләрен белеп торалар.

2015 нче елның көзендә ,әни белән бергә парлы гомер итүләренең 50 еллыгын бәйрәм иттеләр .



*Язманы кызы Лидия Әхәтова әзерләде.*



**Габизова Нәсимә Ислам кызы (Исламова) 1940 нчы елның 11 апрелендә Саба районы Тимершык авылында гади крестьян гаиләсендә дөньяга килә.**

Ул үзенең туган авыл мәктәбендә 7 класс белем ала.

Сугыш башланган көннәрдә Нәсимә әби 1 яшь тә 2 айлык бала була, шунлыктан ул көннәрне бөтенләй хәтерләми. Бөек Ватан сугышына аның әтисе, әнисенең абыйсы Шәрхемулла китә. Бала гына булу сәбәпле, сугыш беткән дигән хәбәрне дә хәтерләми ул Нәсимә әби.

1945 нче елда дәһшәтле Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, әтисе 2 нче төркем инвалид булып сугыштан кайтып керә. Әтисенең сугыштан кайтып кереп, үзен кочаклап алуын да әзме -күпме генә хәтерли ул.

Балачагы, үсмер еллары авыр була аның. “Өскә киндер күлмәк, аякка чабата киеп йөрдек. Рәхәтләнеп, туйганчы ашарга да булмады инде, - дип искә ала ул елларны, чәчләренә чал кергән Нәсимә әби.

Ул 1963 нче елда Олыяз авылындагы бер баласы белән тол калган Габизов Миннәхмәткә тормышка чыга. Алар бергәләп ике малай, ике кыз тәрбияләп үстерәләр.

Ул үзенең хезмәт юлын мөгезле эре терлек фермасында яшь бозаулар карап, сыер савып үткәрә. Авыр хезмәт юлы үтеп, шушы эшеннән лаеклы ялга чыга.

Нәсимә әби бүгенге көндә, Олыяз авылында бик бәхетле тормыш кичерә.Үзенең балалары, оныклары аның янына бик еш кайтып, хәлләрен белеп торалар.

Бүгенге тормышыннан бик канәгать ул Нәсимә әби.



**Шәйхиев Тәхәветдин Бәдыгетдин улы 1940 нчы елның 15 нче августында Саба районы Эзмә авылында колхозчы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә.**

Үз авылында 7 класс белем ала.

… Йөрәк елый, таныш яңакларда
Канлы яшь һәм сулган төс күреп,
Күргәннәрем шомлы экият кебек,
Кичергәнем авыр төш кебек…

Сугыш дигән ачы афәт аларның гаиләсендә читләтеп узмый. Аның әтисе Бәдыгетдинга да сугышка китәргә хәбәр килә. Алар өч бертуган Бәдыгетдин, Габдерәүф, Шәрәфетдин илебез азатлыгы өчен көрәшкә чыгып китәләр. Бар авырлык әнисе Миңкамал җилкәсенә кала. Гаилә шактый зур: әткәй, әнкәй, кызы Зөһрә һәм нәни Тәхәветдин .,,Илебез бирешмәсен, балаларым ятим булмасын, ирем тизрәк дошманны җиңеп кайтсын”,- дип, бөтен көчен эшкә багышлый Миңкамал апа. Бөтен борчу-хәсрәтен эш белән баса. ,,Вакыты шундый булгач, ике балам бар дип тормадым, барысына да чыдадым, урман кисәргә киттем.Ишектән чыгуга,чабатадан аякка йә суык, йә су үтә иде. Сәгать булмагач, төннең кайсы вакыты икәнен дә белмибез, юлга чыгабыз”,- дип искә ала Тәхәветдин абый әнисе сөйләгәннәрен.

Әнисе урман кисүдән кайтып унбиш көн торуга, апасы Зөһрә эче авыртуга түзә алмыйча, үлеп китә. Әбисе белән бабае да бик картаялар. Шуның өстенә әбисе Маһиҗамал сукырая. Шулай булса да : ,,Алар үлсәләр, без ничек торырбыз “,- дип кайгыра ул.

Әтисе Бәдыгетдиннан башта хатлар килеп тора. 1942 нче елда хатлар килү туктала. Һәм аларга әтисенең хәбәрсез югалуы турында хат килеп төшә.

Өйләре дә искерә, матчаны берничә җирдән терәү генә тотып тора. Менә Бөек Ватан сугышы Җиңү белән тәмамлана. Илебез азатлыгы, киләчәк буын бәхете өчен көрәшеп үлүче совет кешеләре белән бергә, әтисе Бәдыгетдин да чит җирләрдә ятып кала. Ләкин әнисенең өмете өзелми, күңеле белән аның кайтуын көтә ул...

Шулай итеп, Тәхәветдин абый , әтисен күрмичә, әти сүзен әйтергә тилмереп, бик акыллы, эшчән, бар эшне дә булдыра ала торган егет булып үсеп җитә. Аңа бик яшьли тормыш арбасына җигелергә туры килә . Мәктәптә укыган вакытта ук көтүен дә көтә, урагын да ура, ат белән бәрәңге аралары да ерып йөри. Җиденче классны тәмамлау белән тимерчелеккә эшкә урнаша. Аны бире дэ бик яраталар.

-Әниеңә охшагансың, энем,- диләр.

1960 нчы елда Кукмара районы Яниль авылында профессиональ училещесында тракторчы – машинист һөнәрен үзләштерә. Ул бу һөнәренә гомер буена тугрылыклы булып кала. 40 ел гомерен шушы хезмәткә багышлый.

1965 нче елда Тәхәветдин абый Көек авылының иң уңган, иң эшчән, иң чибәр кызы Резедә белән тормыш корып җибәрә. Тормыш иптәше дә үзләренә охшап килә. Резеда апаны кайнанасы да , авыл халкы да бик яратып кабул итәләр. Алар зур итеп, бөтен кешене сокландырып, кирпечтән өй салалар.



Тормышның кадерен белеп, татулыктан ямь табып, күңелле яши алар. 4 кыз һәм 1 малай тәрбияләп үстерәләр.

1995 нче елда Миңкамал апаны кадерләп – хөрмәтләп соңгы юлга озаталар.

Тәхәветдин абый колхозның иң алдынгы механизаторлар рәтендә була. Аны эшендә бар кеше дә ярата, хөрмәт итә. Ул үзенә йөкләнгән һәр эшне дә намус белән башкара. Аны бар көчен куеп, тырышып эшләгәне өчен бик күп мактау грамоталары, дипломнар, медальләр белән бүләклиләр. Ә 1996 нчы елда „Татарстан Республикасының Атказанган Авыл хуҗалыгы механизаторы” дигән мактаулы исем бирелә.

2011 нче елда аның пар канаты , тормыш иптәше бу якты дөнья белән хушлаша. Ул бу ачы хәсрәтне бик авыр кичерә. Гел искә төшереп, хатирәләр белән яши.

Бүгенгесе көндә Тәхәветдин абый кызы Алсу тәрбиясендә кадер – хөрмәттә, бәхетле гомер кичерә. Ул үткәндәге дәһшәтле елларны , кайгылы көннәрне берәм – берәм исенә төшереп: „Дөньялар гына тыныч була күрсен “,- дип балаларына һәм оныкларына еш кабатлый.

**Заһиров Рифгать Заһир улы 1941 нче елның 23 нче декабрендә Саба районы Иләбәр авылында дөньяга килә**.

Ләкин аны паспортка 1942 нче елның 11 нче гыйнварендa туган дип язалар. Ул 7 тулы классны тәмамлый һәм 3 ай 8 нче классны укый. Ул елларда мәктәпләр 7 класслы гына була.

Сугыш беткәндә аңа нибары 4 кенә яшь була...

Рифгъат абый 1961 нче елда армиягә китә, 3 ел Ракета гаскәрләрендә , Сырдәрья якларында хезмәт итә. Юрий Гагарин очкан ракета да практика үтә. Әнис, Рифгать абый армиягә киткәннән соң ,бер үзе генә тора. ,,Ярый әле ашарыбызга бәрәңге булды инде. Җәйгә чыккач нинди үлән бар шуны ашадык. Басуда черек бәрәңге җыеп шуның белән тукландык”,- дип искә ала ул авыр елларны.

Әтисе Заһир, сугышка чыгып киткән җиреннән, кире кайтмый. Суслонгерга барганда, поездда бомба шартлый, шуннан соң ул юкка чыга. Рифгать абый әтисен бөтенләй хәтерләми.

Ул, армия сафларында хезмәт иткән вакытта, электрикка укыган була һәм кайткач житен комбинатында эшли , аннары “Ирек” колхозында хезмәт юлын дәвам итә. Үзлегеннән укып мелиорациядә тракторист булып эшли. ПМКда тырыш хезмәте өчен мактау кәгазе белән бүләкләнә.

1967 нче елда ул тормыш корып җибәрә. Алар җәмәгате белән житен заводында танышалар. 1 малай һәм 2 кыз тәрбияләп үстерәләр. Тормыш иптәше генә бик иртә гүр иясе була. Хәзер балалары үз гаиләләре белән яшиләр. Бүгенге көндә ул лаеклы ялда. Рифгать абый малае гаиләсе янәшәсендә бәхетле тормыш кичерә.

**Мансурова Тәнзилә Нәҗбедтин кызы 1940 нчы елның 1 нче июлендә Пүкәл авылында Фәрвәз белән Нәҗметдин гаиләсендә туа.**

Ул 5 класс белем ала. Ашау- эчүләре, киенүләре бик начар була . Тәнзилә апа 1979 нчы елның 7 июнендә кияүгә чыга. 1 малай тәрбияләп үстерә . Гомер буе фермада эшли. Бүгенге көндә Тәнзилә апа малае Рамил һәм килене Роза тәрбиясендә гомер итә.



**Галиева Фәлиянур Абдулла кызы 1938 нче елның 25 нче мартында Саба районы Сәрдә авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Сугыш башлануга әтисе фронтка китә. Әнисенә бер айлык сеңлесе, үзе, анын сукыр әбисе кала. Тормышлары бик авыр була. Ачлык, ялангачлык...

Әтиләренең хәбәрсез югалуы турында хәбәр алалар. Анын нибары ике хаты килеп өлгерә. Беренчесендә:“Без әле сугышка кермәдек”, дип язылган булса, икенчесендә:”Сугышка керәбез, чыгулар булмас инде”, - дип язылган була. Шуннан соң аннан башка хәбәр ала алмыйлар.

,,Сугыштан соңгы еллар бик авыр иде. Авылда ачлык, салкын өйләр, ялангачлык үзәкләремә утеп калды”,- дип искә ала Фәлиянур апа.

Җиде сыйныф тәмамлагач, чын колхоз тормышы башлана. Лаешка барып урман кисә, кайткач фермага эшкә килә. Сигез ел буе фермада сыер савучы булып эшли. 1962 нче елда әнисе дә үлеп китә. Фәлиянур апа Свердловск каласына эшкә китә. Ул анда җир казучы булып эшли. 1963 нче елда Казанга кайта, итек фабрикасына эшкә керә. Ул Сәрдәгә ялга кайтканда, үзенең классташын(булачак ирен) очрата. Фәлиянур апа Гыйльмулла абый белән, 1967 нче елның июнь аенда өйләнешәләр. Бер - бер артлы 3 уллары туа. 1968 нче елда алар Иләбәр авылына күченәләр һәм шул авылда яшиләр.



**Галиев Гыйльмулла Газизулла улы 1939 елның 28 нче декабрендә Саба районы Сәрдә авылында туган.**

Гыйльмулла абый сөйләгәннәрдән:

Җиде класс белем алдым. Сугыш чоры хатирәләренә килсәк, Бөек Ватан сугышы башлангач әтием фронтка китә. Бер әнигә өч бала калдык . Тормышыбыз бик авыр булды. Ачлык, хәерчелек... Без балалар бәхетенәдер инде, әтиебез сугыштан исән – сау әйләнеп кайтты. Ятимлек ачысын да татырга да туры килде безгә. Өйгә үги әни килде...

Җиде класс белем алгач, колхозда эшли башладым. Урман кистем, төрле эшләрдә эшлдем. 1957 нче елда армия хезмәтенә алындым. 1959 нчы елда армия хезмәтен тәмамлап Сәрдәгә кайттым. УМСта укып, механизатор һөнәрен үзләштердем. 1961 нче елда Казахстанга эшкә киттем. Анда алты ел эшләгәч кире үзебезнең якларга кайттым. Иләбәр авылындагы ПМК - 12 оешмасына тракторчы булып эшкә урнаштым. 1967 нче елда гаилә корып җибәрдем.

Бик матур итеп яшәдек. Өч малай тәрбияләп үстердек. Аларны укытып, үз тормышларын корырга булыштык.

Бүгенге көндә барына да шөкер итеп, тормыштан кәнагать булып Иләбәр авылында гомер кичерәбез.

**Юсупова(Гайфуллина) Рәшидә Тимербай кызы Саба районы Эзмә авылында гаиләдә дүртенче бала булып 1938 елның 7 июлендә дөньяга килгән.**

Әниләре Бибиҗамал әби көне-төне балалары ач-ялангач булмасын дип, колхоз эшен башкарган, үзенең көчен авылны саклап калуга биргән.Аның әтисе сугышка киткәндә кызга 3 кенә яшь булган. Тимербай бабай авылда бик укымышлы кеше булган, авыл советы сәркатибе булып эшләгән.Рәшидә бәләкәй булу сәбәпле, сугыш барганын аңлап бетерә алмаган.

Аның абыйсы Саба районы Арташ авылында яшәгән. Ул шул авылга кунакка кайта торган булган. Шунда булачак тормыш иптәше белән танышкан. Ул Казанда “Спартак” фабрикасында аяк киемнәре теккән. Алар 1975 нче елның гыйнварында өйләнешкәннәр. Шул елның 2 декаберендә кызлары Рәйсә дөньяга килгән. Бүгенге көнгә килгәндә, өлкәннәр бик әйбәт кенә яшәп яталар. Яшьләргә үзләренең киңәшләре белән ярдәм итеп торалар.





**Фатыхова (Мөхетдинова) Нәсимә Шиһап кызы 1934 нче елның 20 нче мартында Татарстан республикасы Саба районының Өтернәс авылында туа.**

Өтернәс башлангыч мәктәбендә 4 сыйныф белем ала.

Бөек Ватан сугышы башланганын мәктәптә вакытта укытучыларыннан ишеткән. Сугыш вакытында, кечерәк булганлыктан, басуда эшләгән: чүп утау, борчак җыю – аларның төп эше булган.

1945 нче елның 9 нчы маенда, “Сугыш беткән!” дигән хәбәрне, шулай ук, мәктәптә ишетә. “Ул көнне укулар булмады, безне мәктәптән кайтарып җибәрделәр”, - дип искә ала бу көннәрне Нәсимә апа.

Сугыш бетткәннән соң, тормышлары бик авыр була, ачлыктан тилмереп яшиләр. “Әти эштән кайтышка, кычыткannar җыеп куя идек”, - дип сөйләде ул.

1954 нче елда, Эзмә авылына Фатыйхов Мәгыйзгә кияүгә чыга. Алар бергә өч бала: ике кыз һәм бер малай тәрбияләп үстерәләр. Нәсимә апа гомере буе фермада эшләгән, сыерлар һәм бозаулар караган. Башта ул тормыш иптәшен югалта, ә аннан соң улын салкын җир куенына иңдерә. Хәзерге көндә ул лаеклы ялда, Эзмә авылында тормыш итә.

Фатыхова Нәсимә Шиһап кызы куп кенә мактау грамоталарына ия.



**Рамазанова (Заһидуллина) Мәрьям Лотфулла кызы 1939 нчы елның 7 нче декабрендә Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә эшче гаиләсендә дөньяга килә.**

Әти- әни канаты астында матур гына башланып киткән балачакка 1941 елның 22 июнь иртәсе нокта куя. Алда сынауның иң ачылары. Ләкин яшь ярымлык сабый әле бу хакта белми... Ул елларны ул әнисе сөйләгәннәрдән хәтерли. Әтисен сугыш башлангач, сборга алалар. Өч ай дәвамында ул әнисе тормыш иптәше белән күрешеп тора, ул аңа ипи киптереп алып бара торган була. Сбордан аның әтисен сугышка алып китәләр. Аерылышканда аның әтисе әнисенә: Я Уфага (ул үзе Башкортстанның Кара Тәкә авылыннан була), я Татарстанга кайтыгыз, исән-сау әйләнеп кайта алсам, мин сезне үзем эзләп табармын- ди. Ләкин аңа кире әйләнеп кайтулар насыйп булмый, ул сугыш кырында ятып кала. Дәү әниемне алып, әнисе үзенең туган авылы Саба районы Олыяз авылына әнисе янына кайта. “Балаңны мин карармын, син эшкә урнашырсың”- дип, ул аларны үзе чакыра. Ләкин бәхетсезлек арттан калмый, алар кайтып урнашып, 20 көн үткәч, аның әбисе гүр иясе була. Аның әнисе бик авыр хәлдә кала, тормышны җайлап җибәрү өчен ул актык көченә кадәр тырыша. Ике елга чамасы алар җиңгәләре белән яшиләр, аннан аптырап кире Үзбәкстанга китәләр. Ташкент шәһәрендә Мәрьямнең әнисенең бертуган апасы яшәгән була. Озакламый алар гаиләсе дә Олыязга кайтып төпләнә. Мәрьям белән әнисе сугыш тәмамланганчы Үзбәкстанда яшиләр. Ләкин әнисе кызын чит җирдә мәктәпкә бирәсе килми, ул вакытта инде иренең дә кайту өмете юк. Дәү әниемә 7 яшь вакытта алар кире туган ягына кайталар, бу юлы бертуган апасының йортына кайтып төпләнәләр. Кыз бер ел соңга калып Олыяз авылында мәктәпкә укырга керә. Ә әнисе Шәмәрдәнгә ашлык эшкәртү пунктына эшкә урнаша. Туйганчы ашамасалар да, яшәүләр бик авыр булса да, сугыш бетү шатлыгы аларга тормыш итәргә көч бирә. Шуны ачык хәтерли дәү әнием: иптәш кызының әтисе сугыш бетүгә үк кайтмаган була. Укырга кергән елны алар шул сугышчыны каршы алалар. Шатлыклы вакыйга булып, ул аның күңеленә уелып

калган. Әтисез тормыш бигрәк авыр шул. Җитмәгәненә, әнисе белән дә бик сирәк күрешә дәү әнием. Аның әнисе тормышларын яхшыртырга теләп, Казанда төзелештә эшли башлый. Әнисен бик сагынып көтеп ала ул: беренчедән, очрашу шатлыгы, икенчедән, әнисе ак күмәчләр алып кайта торган була, сирәгрәк матур яулыклар, киемнәр дә эләгә.  Бер ипине дүрткә бүлеп ашаганнарын исеннән чыгармый ул. Ярый әле сыер асрап торганнар, ул бик зур файда бирә. Дәү әнием үзе дә  5 сыйныфтан соң укуын дәвам итми, ашлык кабул итү пунктына  эшкә урнаша. Соңрак ит комбинатында да хезмәт куя. Ә алга таба ул туган авылында фермада сыер савучы булып эшли башлый. Печән алып кайтулар, болынга утынга барулар, чиләк-көянтә белән керосин ташулар - ул заман балаларының көндәлек эшләре булган. Фермадагы сыерларга да алар печәнне үзләре әзерләгән, басудан бәрәңге, шалкан җыеп, аларны юып, малларга ашатканнар. Акрынлык белән булса да кул хезмәте кими төшкән. Тормыш дәвам иткән. “Ямаулы күлмәкләр киеп йөрсәк тә, яшьлек үзенекен итте, кичке уеннарны калдырмый идек, ул вакытта барыбыз да бертөсле булган шул”, - дип искә ала ул. Кичке уеннарда ике ел очрашып йөргәч, кыз күрше Пүкәл авылы егете Миннәхмәт Бәйрәмгали улына тормышка чыга. Ул да  сугыш чоры баласы. Кечкенәдән барлык авырлыкны үз җилкәләрендә татып үскәч, алар икесе дә бик тырыш булалар. Үз көчләре белән йортлар җиткереп, бик матур гаилә коралар. 5 балага тормыш бүләк итеп, аларны олы тормыш юлына бастыралар. “Герой ана” медале белән дә бүләкләнә дәү әнием. Хуҗалыкта да, колхоз эшендә дә сынатмый ул. Сарык фермасында да эшләргә туры килә аңа, соңрак бозаулар карый. Аның хезмәте күп төрле рәхмәт хатлары, мактау кәгазьләре, медальләр белән бәяләнә. Араларында “Хезмәт ветераны” медале дә бар.

“Безнең буын балачаксыз калды,
Сугыш алды аның рәхәтен,
Ярый әле картлык көнебез матур,
Без шуңа да бик-бик рәхмәтле”- дип, бүгенге көндә 5 баласына, 12 оныгына, 2 оныкчыгына изге догаларын укып, кече улы гаиләсендә гомер кичерә. “Без күргән ачлыкны, ялангачлыкны беркемгә дә күрергә язмасын”- дип, изге теләкләрен теләгәндә, аның  чал чәчләреннән сыйпап, дөньядагы иң-иң матур, ягымлы сүзләр белән юатып, аңа мең-мең рәхмәтләр әйтәсе килә аңа. Күпме җылылык, игелек анда



**Әскәрова Гөлмәдинә Хәбирҗан кызы (Хәбирҗанова) (Иләбәр поселкасы) Шмидт авылында 1937нче елның 1нче августында дөньяга килгән.**

Аңа 4 яшь тулганда сугыш башланган, ул бу чорларны хәтерләми. Әмма сугыш бетү хәбәрен ишетү бик сөендерде дип сөйли. Шул сугыш аркасында, күп кенә этиләр сугыштан кайтмадылар, әниләре тол, балалары ятим калды. Үсә төшкән саен, сугыштан соңгы чорның авырлыгы һәр семьяда да авырайды. Минем эти ирләре сугышка киткәч, тракторда хатын-кызлар белән эшләргә мәҗбүр булды. Әтием шул бригаданы житәклшп сугыш вакытында да, аннан соң да авыл хуҗалыгында күп хезмәтләр куйды. Безнең авыл халкы бик тырыш, бердәм дус яшәве 25 сутый бакчада бәрәңге үстереп, сыер, мал-туар асрап яшәгәнлектән ачлыктан үлүчеләрне хәтерләмим. Без авыл балаларына көчебез житкәнчә эшлисе булды. Бәрәңгене эшкәртү кул көче белән, малга корма шуннан җыясы булды. Әтиләре сугыштан кайтмаганнарнга бик тә авыр булды. Бик күп еллар үтсә дә, ул чактагы авырлап бер дә истән чыкмый. Бер Аллам андый авырлыклар беркем башына да килмәсен, шулы тормыш шөкер итеп, алда тагы да яхшы тормышларда яшәвеше өмет итеп яшәргә язсын –дип теләк тели әбиебез.

Сугыш чорында 1941нче елның сентябрь аенда тагы бер инвалид энем туды. Фермада атлы эштә эшләде. 1947нче елда энем 1952нче елда игезәк сеңлем белән энем туды... Мин үзем 1957нче елда тормышка чыктым. Үзем 10 класс белем алганнан соң, бер еллык бухгалтерлар курсында укыдым, Азин МТСында бухгалтер булып эшләдем. Исеме үзгәрсә дә, эше бетмәде, пенсия яше житкәч, 1994нче елда пенсиягә чыктым. Бабаем гомер буе шофёр булып эшләп,хәзер пенсиядә.

1972нче елда улыбыз туды. Улыбыз семьясы белән безнең янда яшиләр. 2 уллары бар. Без бабаем белән шулар тәрбиясендә булганына шөкер итеп яшибез. Көн саен хәер дога теләп эшкә, укуга озатып, кайтуларын көтеп алабыз! Киләчәктә дә саулык, хәерле гомерләрен телибез. Без хәзер олы яшьтә, алар бәхетле булса, без дә бәхетле дип шөкер итә Гөлмәдинә эби.



**Габизов Миннәхмәт Габизулла улы 1932 нче елның 18 нче гыйнварында Саба районы Олыяз авылында дөньяга килгән.**

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа бары тик 9 яшь кенә була. Әтисе назыннан бик яшьли ятим кала. Мәктәптә ике класс кына белем алса да, башы бик яхшы эшли: бик тиз саный белә. Яшь бала булуына карамастан, балта, пычкы, чүкеч тотып эшләүне - балта остасы һөнәрен үз итә ул, үзлегеннән матур әйберләр ясарга өйрәнә. Шулай итеп , яхшы балта остасына әйләнә. Үз гаиләләре өчен матур-матур диван, шкаф, өстәл, урындыклар ясый. Кеше сокланырлык итеп рәсемнәр кертеп тәрәзә йөзлекләре ясый. Бик күп кешеләрне, авылдашларын ясаган тәрәзә йөзлекләре, матур капкалары белән сөендерә ул. “Ясаган капкасына карап сокланырлык, үзе чәчәкләр белән бизәкләр ясый иде”-дип сөйлиләр, Миннәхмәт абыйны искә алып сөйләгән кешеләр.

Балачагы, үсмер еллары авыр була аның. Өскә киндер күлмәк, аякка чабата киеп йөрергә насыйп була аңа. Рәхәтләнеп, туйганчы ашарларына да булмый.

Армия сафларында 3 ел хезмәт итеп кайта. 1963 нче елда Тимершык кызы Нәсимә белән матур тормыш коралар. Алар бергәләп ике малай, ике кыз тәрбияләп үстерәләр.

Ул үзенең хезмәт юлында колхозда төрле вазыйфалар башкара.. Авыр хезмәт юлы үтеп лаеклы ялга чыга. Тормыш авырлыклары сәламәтлеген какшата, 1998 нче елның 11 нче мартында вафат була ул. Үзенең туган авылы Олыяз авылындагы зияратка җирләнгән. Хәзерге вакытта да Нәсимә апаның өендә аның ясаган матур шкафларын, өстәлләрен күреп, күңелләр йомшара. ”Истәлек итеп саклыйбыз” -ди ул аларны сыпырып.





**Зиатдинова (Биктимерова) Рәзимә Ибраһим кызы 1936 нчы елның 2 ноябрендә Шекше авылында колхозчы гаиләсендә туган .**

Сугыш башланганын эти-энилэрдән ишеттем. 7 класс белем алдым. Мәктәптән кырга башак жыярга йөрдек. Киярга кием юк, әни чабата үрә иде, шуны кидек. Тәтә йоннан фуфайкалар бәйли иде. Без шуны киеп үстек. Без гаиләдә 8 бала идек, 3-се кечкенә вакытта үлгән, 50нче елларда энем үлде, әнигә 4 бала калдык. Әти 1942 нче елның февралендә сугышка китте. 1944нче елда сугышта үлде дигән хәбәре килде. Бик авыр еллар булды.



1965 нче елда октябрь аенда Иләбәргә килен булып төштем,тормыш иптәшем Әмин белән 2 бала үстердек. Гомер буе фермада сыер саудым, малларымны бик яраттым. Гел алдынгы урыннарда булдым, эштән курыкмадым, Аллага шөкер.

Бүгенге көнемдә кызым Рәзифә белән киявем Айдар тәрбиясендә яшим. Хәзерге тормышыбыз бик әйбәт, Аллага шөкер. Дөньялар тыныч булсын, сугыш афәтләре булмасын.

Авыл советы депутаты да булып тордым, медалем, значокларым бар.



**Файзрахманова ( Әхәтова ) Флюра Әхәт кызы 1934 нче елның 18 июлендә Алан-Елга авылында колхозчы гаиләсендә туган.**

Әбием сөйләгәннәрдән: Шекше урта мәктәбендә 7 класс белем алдым. Кулга бер дәфтәр һәм бер каләм тотып беренче тапкыр укырга баруымны бүген дә хәтерлим әле мин. Мәктәпкә укырга кергәндә әтиемне сугышка чакырдылар, сугыш башлануын шуннан белдем. Әтием дә, абыем да сугышка киттеләр. Сугышта икесе очрашу бәхете дә эләккән әле аларга. Сугыш вакытларында амбарда эшләдем. Колхозда бар эш кул көче белән эшләнелә иде. Атлы транспорт- ул вакытта төп транспорт чарасы . Икмәкне капчыкларга тутырып, аларны ат арбасына төяп җибәрә идек. Ат җигеп ике ел ашлык чыгардым, утын кистем, ярдым, печән чаптым, печән җыйдым – барысын да эшләргә туры килде. Ул вакытларда илдә ачлык хөкем сөрде.Ачлык бик авыр халәт. Ачлыктан үлмәс өчен бәрәңге, чөгендер яфрагын, өшегән бәрәңге, кычыткан ашый идек. Җәй көннәрендә Сәрдә басуына барып какы да ашадык әле. Ак чәчәкне дөге дип ашка сала идек. Җиләк җыеп, аны сатып налог түләдек. Безнең өстә киндер күлмәк, аякта чабата иде. Бишмәтнең дә тышы киндердән була иде. Бала-чагаларның кайберләре, өсләренә кием булмау сәбәпле, мәктәпкә укырга йөри алмыйча, мич башында җылынып утыра торган иделәр. Карлы су вакытында күтәртмәле чабата кия идек. Ягъни, чабата астына ике агач шакмак беркетелгән була. Ләкин барыбер, су аның эченә керә дә, чыгып та китә иде. Ничек авырмаганбыздыр,күрәсең бик чыныккан балалар булганбыз инде. 1950 нче елда Пүкәлгә эшкә кергәч кенә аякка галош кия алдым. 1949 нчы елда көлтә суктым,

көнгә 5 сутый урак урдым. Ул вакытта егетен дә, кызын да белмәдем, алай аралашулар булмады, вакыты да юк иде.

Сугыш беткән дигән сүзне каян ишеткәнем бик истә түгел.1945 нче елның август айларында урак урган чакларда сугышка киткән әтием һәм абыем исән-сау кайтып җиттеләр. Әтиемнең үпкәсендә өч мина кыйпылчыгы бар иде, операциягә бармады, курыкты. 1963 нче елның 25 апрелендә үлеп тә китте. Абыем сары белән авыртып кайтты, бер ел өйдә ятты, аннан агроном булып эшләде. 1947 нче елда өйләнгәч Ташкентка китте. Сугыш туктаса да, яшәү бик җиңелдән булмады шул.

1955 елда Өтернәскә килен булып килдем.Тормыш иптәшем белән өч малай ( Рөстәм, Рафаэль, Радик ) һәм бер кыз ( Роза ) тәрбияләп үстердек. Башта Пүкәлдә, аннан Шәмәрдәндә эшләдем, көн саен җәяү йөри идем. 4 ел җитендә , аннан соң унике ел почтада газета-журналлар таратучы булып эшләдем. Хезмәтемне хөрмәтләп, 1986 нчы елда “ 3 нче дәрәҗәдәге хезмәт даны ордены”белән бүләкләндем. Бик күп грамоталарым да бар.

Бүгенге көндә үзем генә яшәп ятам. Ирем, ике малаем гүр иясе булдылар инде. Үзеңнең баларыңны срңгы юлга озатуы бик авыр икән ул.



Киләчәк буынга, балаларыбызга, оныкларыбызга сугыш афәтләре күрергә язмасын иде. Тынычлыкның кадерен белеп, татулыкта, бер-беребезгә юл биреп, ярдәм итешеп яшик.



**Йосыпжанова(Сафиуллина) Тәүхидә Галимулла кызы, 1938 нче елнын 5 сентябрендә Чүриле районы Эзмә авлында туган.**

Тәүхидә апа сөйләгәннәрдән:

Шушы ук авылда 8 класс белем алдым. Сугыш башланганда миңа нибарысы 3 кенә яшь иде. Сугышның бөтен ачысын чынлап торып әтиебез Галимулланы сугышка озаткач белдек . Бу 1942 нче елның язы иде. Тормышыбыз уртача булды. Ашау, киенүләр барлык кешеләрнеке кебек бик авыр иде. Сугышка безнең гаиләдән әйткәнемчә әтиебез Галимулла китте. Әниебез Газилә һәм без, 3бала аны озатып калдык. Сугыш беткәнен әтиебез сугыштан кайткач белдек. Әтиебез сугыштан бер аягын калдырып кайтты. Сугыш беткәч тә тормыш жинел генэ бармады шул әле.Һәркем күргән авырлыкны безнең гаилә дә ул вакытларда бик авыр кичерде.

Хезмәт юлымны 1954 нче елда башладым. Башта фермада бозаулар карадым, ә аннан сон медпунктта санитарка булып эшләдем. Анда 1977 нче елдан 1989 нчы елга кадәр хезмәт куйдым.

1964нче елда Эзмә авылының эшчән, булдыклы егете Галимжан белән тормыш корып җибәрдек. 5 балага гомер бирдек . Бугенге көндә тормыш иптәшем инде вафат. Авыр туфрагы жиңел булсын.

Хәзергесе вакытта Тәүхидә апа төпчек улы Газинур һәм килене Миләүшә белән яши. Ул балаларына зур терәк , киңәшче. Бәйрәм-ялларда аның янына тагын 4 баласы гаиләләре белән җыелалар. Тәүхидә апа оныкларга бик бай. Аның 10 оныгы, 3 оныкчыгы бар. Тәүхидә апаны “Ана даны” медале белән дә бүләклиләр. Балаларының, оныкларының горурлыгы ул. Алар барысы да әниләренә озын гомер, сәламәтлек, аларга терәк һәм кирәк булып, озын гомер кичерүен телиләр.



**Абдуллина Нүрия Фйзрахман кызы (Хаеридтинова)Саба районы Сәрдә авылында 1941 нче елның 20 нче гыйнварында туа.**

Нурия апа сөйләгәннәрдән: 1949 нчы елның 1 сентяберендә Саба районы Сәрдә мәктәбенә 1нче класска укырга кердем. 4 нче классны тәмәмлап, 5нче класста укуны Шекше җидееллык мәктәбендә дәвам иттем. Аякта чабата, өстә апайлардан калган кием . Мәктәп елларында укыганда да тик ятмадык, әнигә ияреп ашлык урырга йөрдек . 1956 нчы елда җиденче классны уңышлы тәмамлап, Сәрдәгә сарык фермасына эшкә кердем.

Сугыш башланганда мин биш айлык бала гына булганмын . Сугышка гаиләдән бердәнбер кеше булып, газиз, кадерле әтиебез генә киткән. Әнием сөйләве буенча, әти военкоматтан повестка алып кайткач, мине кочаклап –үбеп, апайларга исән - сау булыгыз, анагызга булышыгыз, мин озак тормам тиздән эйләнеп кайтырмын дип, үз теләге белән сугышка киткән .Сугышка киткән әтиебез турында хәбәрсез югалган дигән генә хәбәр килгән.

Бөек Ватан сугышы беткән вакытта миңа бары тик 4 яшь кенэ тулып китә әле.Мин ул вакытны бер дә хәтерләмим.

1963нче елның җәйге бер матур көнендә Сәрдә авылының иң чибәр, эшчән Абдуллин Шайхулла дигән егетенә кияүгә чыктым.

1964нче елда беренче балам Лилия туды, ә 1966 нчы елда икенче балам Илгиз дөняга килде. 1969 нчы елда Сәрдә авылыннан Иләбәр авылына күченеп төштек.ПМК-12 гә штукатура - маляр булып эшкә урнаштым .

1972 нче елда тагын бер кызым Гөлия дөньяга аваз салды .

Бүгенге көнем тормышым Аллага шөкер .Улым Илгиз, киленем Венера, оныкларым Ильмира һәм Булат белән матур тормыш кичерәбез. Хәзергесе көндә мин барсысына да шат һәм кәнагать . Балаларым исән – сау,6 оныгым, 2 оныкчыгым бар. Шуларны сөеп, аларга терәк һәм кирәк булып яшәргә язсын. Көн саен дисәк тә була, хәлләремне белеп торалар . Аллаһы Тәгалә елларга тынычлык биреп , исән сау яшәргә язсын.



**Хафизуллина (Корбанова) Асия Гәптелвәли кызы 1941 елның 30 мартында Саба районы Тимершык авылында 3 балалы гаиләдә туа.**

Аңа 3 ай булганда Бөек Ватан сугышы башлана. Әтисен беренче көннәреннән үк сугышка алып китәләр.

Әниләре Миннебикә, апасы Миңнур, абыйсы Хәниф, 3 айлык Асияне күтәреп әтиләрен күздән югалганчы озата баралар. Әтиләре иптәшләреннән аерылып кире килә дә әниләрен иңнәреннән кочып: “Кечкенә Асиямне саклый күр,”-ди. Бу аның соңгы васыяте,балаларын соңгы күрүе була. Аларны Суслонгер урманына хәрби әзерлек үтәргә диеп озаталар. Күпмедер вакыттан соң аннан хат килә. Үзләренең бик авыр шартларда ачка тилмереп, туңып, чирләп ятуларын хәбәр итә. Әниләре бик тә уңган, батыр йөрәкле хатын булган. Ризыкларын, киптергән сохариларын туплап юлга кузгала. Мең газаплар белән барып җитеп, ирен ризыклары белән сыйлап, алып килгән чиста киемнәрен киертеп саубуллашып кире кайтып китә. Юл буе аның күз алдыннан ачка тилмереп, ябыгып, сулып беткән ире китми. Бу аның тормыш иптәше Гәптелвәлине соңгы күрүе була.

Сугыш елларында ирләр яу кырына киткәч,авырлыкның күбесе хатын-кыз җилкәсенә төшкән. Алар алны-ялны белми эшләгән. Трактор руле артына утыручылар да хатын-кыз булган. Җиңү көнен якынайту өчен алар һич кенә дә күңелләрен төшермәгәннәр. Балаларына да күңел җылысын биргән, юаткан. Ул чорда эшләгән, балалар үстергән хатыннар хезмәте батырлыкка тиң. Асиянең әнисе дә, балаларын ачлыктан коткарып калу өчен, көн-төн хезмәт куя. Нинди генә авыр хәлдә калса да иренең васыятен үти, кызамык белән үлем хәлендә авырып яткан Асиясен терелтү өчен ниләр генә эшләми ул.

Басу капкасы төбенә чыгып көннәр буе әтиләрен көтеп тә, көтеп ала алмаган сугыш чоры балаласы ул, Асия. Аның түккән күз яшьләрен җыйсаң елга булыр иде. Әтисенең тезенә утыртып, башыннан сыйпап яратуын, сүзен тыңламаган өчен солдат каешы белән йомшак җиренә эләктерүен төшләрендә күреп, күпме таңнарны елап каршы алганын үзе генә белә ул.

Бу чәчләрең ник агарган?- диләр,
Бер карасы хәтта калмаган.
Сугыш елларының тузаннары
Куып җитеп аны каплаган.

Бу йөзеңәниләр булды диләр,-
Нинди җыерчыклар таплаган?
Яшьлегемнең сары сагышлары
Сыенып җир башка тапмаган
Бу күзләрең нигә төссез диләр,
Ә бит алар кара булганнар!
Гомер буе әтиемне көттем,
Каралыгын яшьләр юганнар,- дип яраткан шигырен көн дә искә төшерә ул.

Иренең хәбәрсез югалганына ышана алмый әниләре, балалар да көн дә басу капкасы төбендә әтиләрен көтә. Ләкин бәхет аларның капкаларын какмый шул. 1947нче елда өметен өзгән әниләре 3 баласын алып туган авылы Алан-Елгага кайтып китә .

1948нче елда Асия Шекше 7 еллык мәктәбенә укырга керә. Әнисе теккән чүпрәк букчага китапларын салып, чабатасын киеп бик тә тырышып укуый башлый ул. Фәннәрне бик җиңел үзләштерә.

1955нче елда мәктәпне тәмамлап, Казанда яшәүче хәлле генә бер гаиләгә бала карауччы булып китә. Рус телен яхшы белгән кыз югалып калмый, үз эшен җиренә җиткереп башкара, аны бик яраталар.

1958нче елда Кукмарага кайтып итек фабрикасында эшли башлый, тегү серләренә дә биредә өйрәнә. Үзенә матур киемнәр тегеп киеп авылга кунакка кайта ул.

1965 нче елда Иләбәр авылына килен булып төшә.Тормыш иптәше Шәйхулла белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Килен булып төшкән көннән бирле, 55 яше тулганчы, фермада 31 ел буе терлекчелектә эшли: сыер да сава, таналар, бозаулар да карый. Кайда гына эшләсә дә эшен җиренә җиткереп башакара ул. Күп сандагы мактау кәгазьләре шул турыда сөйли.



31 ел кайнанасы белән тату гомер итеп, тормыш иптәше белән акыллы, тәртипле балалар үстерәләр.

Бүгенге көндә олы улы Рүзәл, килене Райлә, оныгы Алия белән Иләбәр авылында матур гомер кичерәләр.

70 елдан артык тынычлыкта яшибез дисәк тә, әле һаман да анда –санда сугыш утлары кабынып тора. Бер кемгә дә кирәкмәгән зур корбаннар алып килүче сугышлар бүтән булмасын иде. Толлар, ятимнәр җирдә булмасын иде дигән изге теләктә, булганына шөкер итеп, гомер кичерүче сугыш чоры балаларының берсе ул.



**Кириллова Гөлфирә Хатыйп кызы 1940нчы елның 9нчы сентябре көнне Саба районы Алан - Елга авылында туган.**

Гөлфирә апа сөйләгәннәрдән:

-Без гаиләдә 4 бала үстек. Әти сугышның беренче көннәреннән үк фронтка киткән. Әнием Нотфуллина Гөлбану безне аякка бастыру өчен бөтен көчен куйды.

Ачлык, ялангачлык барлык кешегә дә эләкте инде. Без ашап үскән черек бәрәңге, алабутадан әзерләнгән ризыклар тәмле кебек иде, чөнки ач булганбыз инде. Әтием фронттан башы яралы булып кайтып керде. Ләкин бер елдан, эшкә дип чыгып киткән җирендә үлеп калды. Башындагы ярасы төзәлеп җитмәгән булган анын.

Мин дүрт класс белем дә алып бетерә алмадым, дуңгыз фермасына апалар янына эшкә кердем. Аннан соң Иләбәрдәге житен заводына эшкә чакырдылыр. Безне Казанга укырга җибәрделәр, аннан йон эрләргә өйрәнеп кайттык.

Иләбәр авылы егете Кириллов Анатолий Иванович белән озак кына дуслашып йөргәннән соң тормыш кордык. Дүрт бала тәрбияләп үстердек. Тормыш иптәшем 2001нче елда вафат булды.

2016нчы елда тагын бер ачы хәсрәт кичердем, каты авырудан соң кызым вафат булды.

Бүгенге көндә Иләбәр авылында оныгым Альфред, киленем Гөлнар, аларның ике уллары белән бергә яшим. Без күргән авырлыкларны, юклыкларны балалар, оныклар күрергә язмасын, бәхетле булсыннар.



**Хәбирҗанова (Гарипова) Рәшидә Яхъя кызы 1937 елның 2 гыйнварында Саба районы Иләбәр авылында дүртенче бала булып дөньяга килә.**

Башлангыч белемне Иләбәр мәктәбендә ала. Аннан әбием 5 сыйныфка Эзмә мәктәбенә төшә. Шушы елларда Эзмәдә иң беренче җидееллык мәктәп ачыла.

Сугыш башланган дигән хәбәрне каян, кемнән ишеткәнен әбием хәтерләми. “Сугыш башланганда мин әле кечкенә нибары биш яшьтә генә идем”,-дип искә ала. Әтиләрен сугышка озатканда аны елап калмасын дип уятмыйлар.

Әниләре Гаделбану әби көне-төне балалар ач-ялангач булмасын дип, колхоз эшен башкара. Әбием капчык-капчык яфрак ашауларын, өсләренә ямаулы кием киюләрен күз яшьләрсез сөйли алмый. Хәтта өскә кияргә кием булмыйча мәктәпкә дә бер ел соңрак кердем дип өстәп куя.

Әтисенең Днепр буеннан бары тик бер генә хаты килә. Анысы да үз кулы белән язылмаган була. Сугыш бетү турындагы хәбәрне әнисеннән ишетә.

1956нчы елда 19 яше тулганчы Иләбәр егете Хәбирҗанов Сабирга кияүгә чыга, 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Балалар аякка басканчы ул төрле эштә эшли. Аннан фермада 16 ел хезмәт итеп пенсиягә чыга. Әбиемнең тырыш хезмәте өчен мактау грамоталары да бар:
















тора. Хәзер тормыш Аллага шөкер, кадерен белегез, т Бүгенге көндә әбием килене һәм оныклары тәрбиясендә ырыш һәм әдәпле, сәламәт булыгыз дип безгә изге теләкләрен тели.

*Рүзил Хәбирҗанов, Эзмә урта мәктәбенең 6 сыйныф укучысы.*



**Әхмәтсафин Муллануp Зиннур улы 1942 нче елның 10 нчы апрелендә Саба районы Кызыл-Мишә авылында колхозчы гаиләсендә туган.**

1949 нчы елда Кызыл-Мишә башлангыч мәктәбенә укырга кергән. 1953 нче елда Кызыл-Мишә мәктәбен тәмамлый. 1953-1967 нче елларда Тимершык җидееллык мәктәбендә белем ала. Аннан соң , Саба урта мәктәбендә укуын дәвам итә. 1960 нчы елда Саба урта мәктәбен тәмамлый. 1961 нче елдан Кызыл-Мишә авыл авыл клубы мөдире булып эшли. 1963-1966 нчы елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1967-1968 нче елларда Янил 10 нчы номерлы профучилищесында укып чыга. 1968 нче елда Азин ММС ында тракторчы булып чыга.1968 нче елда читтән торып Тәтеш авыл хуҗалыгының агрономия бүлегенә укырга керә. Шушы елларда Азин ММС ында өлкән белгеч вазыйфасын башкара.1969 нчы елдан мастер итеп күчерелә.1971 нче елда Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый.1985-1987 нче елларда Калуга гидротехникумында укый. Аны Кызыл диплом белән тәмамлый.1988-1992 нче елларда Мәскәү дәүләт университетында читтән торып укып, югары белем ала.1988 нче елга кадәр Саба ПМК сында эшли. Аннан соң, Саба районы „Меллиорация” участогына идарә җитәкчесе итеп билгелиләр. 2000 нче елга кадәр Саба „Меллиорация” се оешмасында идарә җитәкчесе булып эшли. 2000 нче елдан 2003 нче елга кадәр , „Меллиорация” оешмасының баш инженеры һәм прораб булып эшли. Бу оешма республикадагы 14 оешма арасында алдынгылардан була. Муллануp абый 2003 нче елда пенсиягә чыга.

Муллануp абыйның әтисе Зиннур 1942 нче елның февралендә Бөек Ватан сугышына китә һәм шунда һәлак була. Сугыш беткән дигән сүзне өлкәннәр сөйләвеннән ишетә.Сугыш чорындагы тормыш һәм аннан соңгы еллар бик авыр булды ди, Муллануp абый.

1972 нче елның февраль аенда Ралия исемле кыз белән тормыш кора. Муллануp абый белән Ралия апа ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә олы улы гаилә корып, Сабада яши. Кече улы һәм кызы бик матур итеп



эшләп йөриләр. Мулланур абый бүгенге көндә кадерле әти , бабай, ир булып матур итеп әкрен генә йөреп , яшәп ята. „Меллиорация” оешмасында эшләгән елларында дипломнар , грамоталар белән бүләкләнә. Армиядә хезмәт иткәндә фашизмны Җиңүнең 20 еллык хөрмәтенә медаль белән бүләкләнә.

Мулланур абыйның тагын бер сәләте турында язмыйча мөмкин түгел.Ул иҗади һәм шигъриятькә гашыйк кеше. Мулланур абый үзенең беренче шигырьләрен 1950 нче еллар азагында бастыра башлый. Аңа иҗатка юлны татарның күренекле әдипләре Хәсән Туфан , Сибгат Хәким , Нәби Дәүлиләр бирә. „Безнең Мулланурыбыз бар инде,син Нурсаф булырсың.” дип , әдәби псевдонимны да аңа Хәсән Туфан биргән. Туган якка мәхәббәт белән сугарылган шигырьләренә романтик рух , нечкә лиризм,фәлсәфи уйланулар хас. Ул Газиз Нәбиуллин мәктәбен уза,гомер буе шигъриятькә һәм Нурсаф дигән әдәби антына туры калып күпләгән шигырьләр иҗат иткән шагыйрь ул.Ул „Мәдәният эше отличныгы” билгесенә лаек булып, Закир Йосыпов исемендәге әдәби премия лауреаты да. Әңгәмәне Мулланур абый “Әнкәйләр каенлыгы” шигыре белән тәмамлады.

Барам-кайтам Сабаларга,
Юл буенда каеннар
Йөгереп чыгалар каршыма,
Исәнләшеп калалар.
Әнкәйләр утырткан аны
Сугыш беткәч...Истәлек...
Яуда калган әйткәйләрне
Тора алар искәртеп.
Әнкәйләр утырткан урман,
Әнкәйләр каенлыгы.
Каеннарның аклыгында
Әнкәйләрнең саулыгы.
Барам-кайтам Сабаларга,
Юллар үтә шушыннан .
Каеннар,әнкәйләр кебек,
Дога укыйлар сыман.



**Мөбәрәкова (Хәкимуллина) Гөлфирә Хәкимулла кызы, 1940 нчы елның 30 июлендә Саба районы Керәнне авылында колхозчы гаиләсендә туган.**

Сугыш башланганда миңа бер яшь булган. Сугышка безнең гаиләдән әти һәм аның бертуган 18 яшьлек энесе киткән. Әти исән-сау әйләнеп кайтты, ә энесе сугыш кырында һәлак булды. Үзем сугышның нәрсә икәнен аңлар дәрәҗәдә булмаганмын, әни белән 11 яшьлек абыйның сөенечтән елаулары истә калган.

Сугыш беткәч тә тормышлар бик авыр булды. Боларын мин дә хәтерлим: тамакка ашарга, өскә кияргә юньле кием булмады. Әти-әни колхозда таякка эшли, эшләгән өчен түләү юк. Абый үсә төшкәч, трактористлыкка укып, МТС та эшли башлагач, бераз ипигә туендык. Язга мал кормалары бетеп, сыерның күтәрәмгә калганын хәтерлим. Мал-туар асрасак та, үзебезгә сөте, мае, йомыркасы эләкмәде, налог түләргә китеп барды.

1948 нче елны беренче сыйныфка укырга кердем, 42 бала укыдык. Уку әсбаплары җитми, бер карандашны укытучыбыз өчкә бүлеп бирә иде. Карлар эреп балчык чыга башлауга , ялан-аяк йөри идек. Мәктәпкә бик теләп, укыйсы килеп йөрдем.

Мәктәпне тәмамлагач, колхоз мине стипендия түләп бухгалтерлар хәзерләү буенча училищега укырга җибәрде. Ул вакытта безнең колхоз “ Кызыл Партизан” исемен йөртә иде. Районда данлыклы колхозларның берсе булды. Укып кайтып шушы колхозда биш ел эшләгәч, 1961 нче елда тормышка чыгып Эзмә авылына килен булып төштем, ике бала табып үстердем. Ирем яшьтән генә фаҗигале рәвештә вафат булды.

Пенсиягә киткәнче “Игенче” колхозында бухгалтер булып эшләдем. Балаларым да үз юлларын таптылар. Кызым Түбән Кама шәһәрендә яши, югары белемле, мәгариф идарәсендә эшли. Улым махсус урта белемле, Шәмәрдән икмәк кабул итү предприятиясендә эшли.

Бүгенге көндә малаем һәм киленем тәрбиясендә яшим, хуҗалык эшләрендә булышам. Биш оныгым бар.



Эшләгән чорымда колхоз мактау кәгазьләре белән бүләкләндем, “Игенче” колхозының “Атказанган колхозчы” сы исемен йөртәм.

Барчабызның да тормышы тыныч, имин, матур булсын, сугышлар кабатланмасын иде. Килгән көнгә шөкер итеп, тормышның ямен белеп яшәргә язсын!

*Истәлекләрне оныгы Флүзә Мөбәрәкова язып алды.*





Саба районы Эзмә авылында тормыш итүче сугыш чоры балалары Фәрит абый белән Дәрига апа Солтановлар матур итеп яшәп яталар. Сугышның нинди ачы икәнен, шул чорда туган балалар ничек тормыш иткән, нинди авырлыклар кичергәнлекләрен бераз булса да күз алдына китерү, белү өчен, бу турыда аларның үзләреннән сораштырырга булдык.

**Солтанова Дәрига Әхмәт кызы (кыз фамилиясы Нәбиуллина) 1939 нчы елның 15 нче июлендә Саба районының Бакшанды авылы колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.** 1946 нчы елда Бакшанды авылының башлангыч мәктәбенә беренче сыйныфка укырга керә. Анда 4 ел белем алганнан соң, тагын 3 ел Керәнне мәктәбендә укый.

**Солтанов Фәрит Гәрәй улы 1935 нче елның 20 нче мартында, Саба районы Эзмә авылында колхозчы гаиләсендә туа.** Фәрит абый бары тик мәктәптә 3 ел гына белем алса да техниканы яхшы белгән, кечкенә чагыннан инде машиналар йөртергә өйрәнгән.

Сугыш башланган вакытта, Фәрит абый да Дәрига апа да сабый гына булганнар әле. Аларның сөйләүләре буенча, алар ул вакытта “сугыш” сүзенең нәрсә аңлатканын да белмәгәннәр. Сугыш башланганда Дәригә апага 2 яшь, ә Фәрит абыйга 6 яшь булган. Аларның балачаклары, рәхәтләнеп күңел ачып уйный торган чаклары, шушы сугыш чорына туры килгән. “Бик нәни булгангамы, әллә

онытканбызмы инде, сугыш вакытларын алай ук ачыктан-ачык сөйләп бирә алмыйбыз. Төрле чакларыбыз булгандыр инде: ачлыгы да булгандыр, салкыны да тими калмагандыр. Әниләр назы да җитмәгән чаклар күп булгандыр. Нинди генә кыен хәлләрдә калсалар да, әниләребез безне ташламаганнар, безне яшәткәннәр, сау-сәламәт итеп үстергәннәр. Сабый чагыбыз булганлыктан, сугыш чорында бернинди эштә дә эшләмәдек. Өс-башларыбыз да бик булмагандыр инде, ул сугыш чорында яхшы киенгән кешеләр бармак белән генә санарлык иде. ”- дип сөйлиләр Фәрит абый белән Дәригә апа. Гаиләдән сугышка Фәрит абый да, Дәрига апа да әтиләрен озатканнар. Ләкин сугышка киткәннән соң, әтиләрен кабаттан күрү, “әти” дип назлап эндәшү аларга насыйп булмаган. Икесенең дә әтиләре сугыш кырында улеп калганнар.

Сугыш беткәндә Дәрига апа беренче сыйныфка укырга керә, аңа 7 яшь була. Ә Фәрит абыйга тулы 11 яшь була. Ул вакытта инде алар сугышның ни икәнен аңлап, аның бетүе турында ишеткәч, бик сөенәләр. Сугыш беткәннән соң, Фәрит абый кечкенә генә яшьтә булса да, 13 яшендә шофёрлыкка эшкә керә, ә 16-18 яшьләрендә ат белән урман чыгару эшен башкара. Аннары лаеклы ялга кадәр колхозда эшли. Дәрига апа да Фәрит абый сыман ук колхозда эшли.

Бер-берегезне ничек очраттыгыз, кая таныштыгыз дигән сорау биргәч, алар бер-берсенә көлешеп карап куйдылар. “Ничек танышканнар хәзер истә түгел инде, Фәрит бик чибәр егет иде. Шулай насыйп булгандыр инде, бер-беребезне күреп, гашыйк булып, бергә гаилә корырга.”-дип җавап бирделәр. Дәригә апа Эзмә авылына килен булып төшкәндә аңа 21 яшь була, ә Фәрит абыйга 25 яшь. Шулай матур итеп тормыш итә башлыйлар. Аларның бер кызлары ике малайлары туа: Венера, Флорид, Фаяз. Аларны кешелекле итеп, дөрес юл күрсәтеп үстерәләр.

Бүгенге көндә дә Дәрига апа белән Фәрит абый, башкаларга үрнәк булып, бер-берсенең киңәшенә колак салып, хөрмәт итеп, тату гына уллары Флорид тәрбиясендә яшәп яталар. Оныклары: Рафаэль, Дәлия, Ринас, Инсаф. Аларны үз балаларыбыздан да артыграк күреп яратабыз диләр. Киленнәре дә Фәрит абый

белән Дәрига апага карата яхшы мөнәсәбәттә торалар. Һәр еллар саен кайтып, хәлләрен белеп, эшләрен эшләп китәләр.

Киләчәктә дә Дәрига апа белән Фәрит абыйга бергә озын-озак гомер кичерүләрен теләп калабыз. Безгә рәхәт тормыш бүләк иткән, безнең өчен кан койган ветераннарыбызны онытмыйк. Аларны гел искә алып, үзләрен дә рәхәт тормышка яшәтик.




Фәрит абыйның бүләкләре.



## Батыева Вәкилә Сабир кызы, 1942 нче елның 1нче июньдә Таджикстанда туган.

Патша вакытында, Әти- Сабирҗан Сабит улы, мәдрәсә бетереп, авылда Чакмагуш районында урнаша, өйләнә. 2 баласы тугач, муллаларны бетерә башлагач, әтиебез семьясын алып, Урта Азиягә чыгып китә. Поездда 21 көн баралар, юлда 1 яшьлек кызлары үлә.

Әти Таджикстанда читтән торып (2 еллык) институтны бетерә. Аны башлангыч мәктәпкә укытучы итеп билгелиләр. Әни балалар үстерә.

Әтине сугышка 1942нче елның гыйнварында алып китәләр.

Әтиебез бик эшчән, уңган була. Кешедән колын сатып алып, үстереп шуның белән безгә ачлыкны күрсәтмәде. Әниебез атта йөргән. Атта йөрүне бабайдан өйрәнгән. Бабайның 40 аты булган, әни балачакта шул атларны карарга булышкан. Сугышның ахырына хәтле аттайөреп, таудан-тауга менеп ,ризыкларны алыштырып, 4 баланы саклап калган. Ул вакытта ачлыктан үлүчеләр бик күп булган . 1 нче балалары малай булган. Әтине сугышка алгач, абыйны (13 яшьлек) мәктәпкә укытучы итеп куялар.

Әти ат белән чыгып китә, ә өйне биклэп китә. Өйдә 3 кыз бала кала. Мине апалар карыйлар. Йортка терәп бер келәт тә булган. Анда тәрәзә тишеге булган. Апалар шул тишектән өй түбәсенә менгәннәр. Урта Азияда йорт түбәләре тигез ясала: камыш, аның өстенә балчык җәяләр.Апаларым мине дә түбәгә өстерәп чыгаралар. Тагын этебездә чыга. Ничек ул анда чыккан икән?

Җыелгач, барыбыз Аллаһтан сорап елыйбыз: “Әй, Ходаем, Әтиебез кайтсын иде, кайтар инде әтиебезне!”-дибез.

Көн саен әни чыгып киткәч, без 2-3 сәгатьләп шулай елап утырабыз икән. Без туктаганда этебез улый икән.

Авыл халкы елый икән безне җәлләп.



Әтиебез сугыштан кайтты! Менә бит бәхет! Могҗиза!

Районнан 2 кеше генә кайтты. Әтине каршыларга бөтен авыл чыкты. Башта мине җибәрделәр каршыларга. Икесе бер төсле киенгән. Ә мин “әти, әти дип әтигә ташланганмын. Әти, әни тагы 1 малай, 2 кыз таптылар. Әти белән әни 7 бала үстерделәр. Шуларның 6 сы югары белемле. 7 баладан 20 бала: 7 врач, 3 укытучы, Юрист, тәрҗемәче.

Әти 66 яшьтә, Әни- Зәйнә Низаметдин кызы 75 яшьтә вафат булдылар. Әти бик укымышлы кеше иде. Коръәнне яттан укый  иде.

Бүгенге көндә Иләбәр авылында балаларымның ярдәмен, ихтирамын тоеп яшим.



**Латыйпова (Урканова) Сания Якуб кызы 1942 нче елның 1 апрелендә Саба районы Кырбаш авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.**

Анының 1937нче,1939 нчы елларда туган ике апасы була.Ә Сания апа, әтисе сугышка киткәндә,әле тумаган да була.Ә сугыш беткәнне бары тик 3 яшьлек бала булып каршылый. Шуңа күрә ул дәһшәтле сугыш турында берни дә сөйли алмый.

Анының әтисе Бөек Ватан сугышына 1942 нче елда китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Сания исемле кызын күрү- бөтенләй дә насыйп булмый аңа. Әтиле булу бәхете,әти назы күрми үсә Сания апа.Шулай да ул көчле рухлы,эшчән ,акыллы кыз булып үсә.Үз тырышлыгы белән 7 класс белем ала.Әтиләре булмаганлыктан,әниләренә яшәве авырга туры килә,күп вакытларын әби-бабайлары канаты астында уздыралар алар.Бабайлары һөнәре буенча-чабатачы була.Шәмәрдән станциясенә апалары белән бергәләп барып, бабайлары үргән чабатаны саталар алар.

1960 нчы елда Эзмә авылы егете Илһам белән гаилә корып җибәрәләр.
Ул бу авылга килен булып килгәч,Азин җитен заводына эшкә керә. 1967 нче елда анының хезмәт юлы колхозда терлекчелектә дәвам итә.Киров исемендәге колхозның дәүләткә ит сату планын елдан-елга арттырып үтәвенә зур өлеш кертә ул. Тырыш хезмәтенең нәтиҗәсе булып, “ Хезмәт ударнигы”исеме, тагын бик күп мактау кәгазьләре әле дә саклана анының сандык төбендә.

Илһам абый белән бергә, ике малай, өч кыз тәрбияләп үстерәләр алар. Картлык көннәрендә тигезлек белән яшәргә насыйп булмый аларга,каты авырудан соң ире Илһам абый вафат була.

Бүгенге көндә Сания апа дүртенче баласы гаиләсендә - улы, килене, 2 оныгы белән тату гына гомер кичерә . Анының балалары, оныклары кайтып хәлләрен белә,төп йортның эшләрендә ярдәм итә.



**Сафин Ринаф Сафа улы, (Газизжанов) элек Чуриле районы булган, хәзер Байлар Сабасы районы Эзмә авылында дуртенче бала булып, 1940 елнын 7 апрелендә колхозчы гаиләсендә туган.**

Бабаем Эзмә авылы мәктәбендә 7 класс белем алган. Соңыннан 11 еллык мәктәптә кичке 11 нче классны тәмамлаган. Бабайга сугыш башланганда нибары бер яшь була. Ул сугыш вакытларын эти - эниләреннән ишетеп белә. Ә менә анын этисе Вәлиәхмәт улы Әхмәтсафа сугышка киткән һәм исән - сау әйләнеп кайткан. Сугыш вакытында тормыш бар кешегәдә авыр булган ашарга, кияргә булмаган, ди бабаем. Һәрнәрсәгә мохтаҗлык башланган. Сугыш тәмамланган. Бабай җизнәсенең малае Миннәфәрт белән тау башына менеп, сугыштан кайтучыларны каршы алганнар. Сугыштан соң да тормыш бик жиңел булмаган. Баздан бәрәңге чыгарган көн бәйрәм булган. Бәрәңге тозлы суга манчып ашаганнар. Аны “үрдәк мае “ әйткәннәр. 1968нче елда бабаем Мәйсәрә белән гаилә корып, тату гаиләдә 2 бала тәрби яләп үстерәләр. Бабай гомер буе 45 ел механизатор булып ПМК-12 дигән оешмада эшләгән. Ул хезмәттә гел алдынгы булган. Аның хезмәтләре өчен бирелгән мактау кәгазьләре һәм медальләре бикү. Аңа “Россияның атказанган механизаторы “дигән исем дә бирелгән. Әле алай гына да түгел, Тәлгать Нәжмиев язган “Яшә Саба-Йорт! дигән китапка да кертелгән.Хәзерге көндә бабай Иләбәр авылында әби белән тигезлектә яшиләр. Бабай дин юлына кереп китеп намазын калдырмыйча мәчеткә йөри. Мин аларга көн саен кереп, хәлләрен беләм, вак-төяк эшләрен эшләргә тырышам. Алар миңа тәмле итеп чәй эчертәләр, рәхмәт әйтәләр. Без аларны хөрмәт итәбез, сәламәтлек, озын гомер телибез. Исән чакларында кадерләрен, үлгәч каберләрен онытмыйк.

*Эзмә урта мәктәбенең 5 сыйныф укучысы Азат Сафин.*



**Хабибуллина (Якупова) Мәдинә, 1941 нче елның 11 нче июлендә Эзмә авылында колхозчы гаиләсендәтуган.**

Әтием вакытлыча армиядән калып килеп, бераздан армиягә алынган. Шуннан соң сугыш башланып киткән. Ә мин бер тапкыр да әтине белмичә һәм күрмичә әнием карынында калганмын. Әтинең: “ Ике тапкыр сугышка кердек, өченчесенә керергә торабыз, исән – сау чыксам хат язармын. Әгәр дә кыз бала тапсаң “Мәдинә” – дип исем кушарсың.( Әниемнең исеме Әминә иде)”- дигән хаты килгән. Шуннан соң бер хәбәре дә булмаган. Әниләр өметләнеп сугыш беткәнен көтәләр.

Ниһаят сугыш тәмам.....

Инде без дә урамда уйнап йөри торган балалар. Берзаман (хәтердә шулай калган) күрше кызы белән чирәмдә аунап уйнап ятканда, яшел киемле бер кеше килеп, ул кызны күтәреп алып, бик нык кочаклап сөйде. Ул кызның әтисенең сугыштан кайтып килеше булган. Ә мин карап торам, миңа 4-5 яшьләр чамасы. Шуннан соң бу бала да нәүмиз булмасын дигәндер инде, тезләренә утыртып мине дә сөйде. Һәм синең дә әтиең кайтыр, менә шушы Корбан бабаңнар тавында көт диде. Мин ул тауга иртән дә, көндез дә, кич тә бардым. Бик күп тапкырлар барып күренмәгәч, өмет тә өзелгәндер инде. Әнием дә ул тауга кайтып җитсә монда да кайта инде ул дигәч туктадым кебек. Үсә төшкәч кенә кемнәр сугышка яраксыз булып калганнарын белдем. Аларның балалары бик бәхетле иде...

Сугыш беткән елны булса кирәк. Бер апа кереп әнигә бер кәгазь бирде. Менә шуннан соң әни бик каты еларга тотынды. Ул елагач мин дә елыйм, аның нәрсәгә елаганын белмим. Ул әтинең хәбәрсез югалганына “кара кәгазь» булган икән бераз үсә төшкәч кенә аңладым., почталеон киткәч әни сәкегә кереп ауды да бик озак елады. Ә мин аяк очында елыйм. Елап арыгач бакчага бәрәңге эшкәртергә чыктык. Менә шулай мин әтисез,әниләр япь-яшь
килеш ирсез калдылар. Әле без ул вакытта мәңгелеккә бәхетсез калганыбызны аңламый идек. Гөмер ничек булса да үтә тора, без укырга да кердек һәм әниләрнең кул арасына да керә башладык. Әниләр таңнан төнгә кадәр эштә, йортта вак – төяк эшләр безгә тапшырылды. Мәктәптә укытучылар әллә хәлгә

кереп, бик әйбәтләр иде. Иптәшләр ягъни классташлар барыбыз бер. Өс-баш: ямаулы бишмәт, аякта чабата, китаплар чүпрәк букчаларда. Беркем кыерсытмый, синең әтиең юк дигәнне укып чыкканчы бер кемнән дә ишетмәдем.

Бераз үсә төшкәч басуга черек бәрәңгегә йөрибез, тапсак билгеле, аның күмәчен мәктәпкә алып барабыз, түземсезлек белән тәнәфесне көтеп шуның белән тамак ялгыйбыз. Без күбесенчә икече сменада укыдык. Лампа яктысында класслар җитми иде. Бер класста ул вакытта 27 бала. Класстсшларым барсы да йөз аклагы булдылар. Ник берсе бер әйбер урласын. Рәхмәт сезгә яшьтәшләрем, классташларым, укытучыларым, газиз әниләребез! Менә шулай итеп мин 7 классны “4”ле-“5”ле билгеләренә тәмамладым.

Алга таба белем алу мөмкинлегем булмау сәбәпле, зурлар кебек алар белән бергә эшлибез.Әниләрнең бик зур ярдәмчеләре. Инде төпле эш кирәк һәм мин 1957 нче елда дуңгыз фермасына эшкә килдем һәм тормышка чыкканчы шунда эшләдем.

Ә яшьлеккә килгәндә безнең яшьлегебез бик күңелле үтте. Кием күрсәтергә генә чыгу түгел. Концерт театрлар өйрәнәбез, башта авыл клубында куеп, аннан күрше авылларга китәбез. Ә җәй көннәрендә су буйлары безнеке.Гармунчылар бар, алар ялындырып тормыйлар безне туйганчы биетәләр. Көндезләрен арылса да аларның гармун тавышларын ишетүгә арыганнар онытыла. Без тагын уенлыкта. Сөйгән ярларыбызны да шунда таптык. Дүрт ел очрашып йөргәч, тормыш кордык. 42 ел бик тату яшәп, ике ул үстердек. Улларыбыз да сайлаган һөнәрләренә тугырылыклы булып хезмәт итәләр. Ә үземнең хезмәткә килгәндә 13 ел колхозда, 27 ел бетон эшкәртмәләр заводында эшләп 40 ел стаж белән лаеклы ялга чыктым.Тормыш иптәшем дә бик уңган, акыллы кеше иде. Инде ул бакыйлыкта сүзләрем дога булып барсын. Әнием 60 ел тол яшәп,сугышка рәнҗеп, безне мәңгелеккә бәхетсез итте дип, сез мәңге сугыш афәтләре күрмәгез, - дип бакыйлыкка күчте.

Дәүләт бүләкләрем түбәндәгеләр:” Яхшы күрсәткечләргә ирешкән өчен”- 1971,72,73, 77,79,80, 91,93, 96 елларда бирелде.

1962 елда Иләбәр авылына кияүгә чыгып, менә 55 нче елымны улларым, киленнәрем тәрбиясендә булганына шөкер итеп, чиратсыз ипи алу бәхетенә ирешеп, кулдан килгәнчә аларга ярдәм итеп яшәп ятам. Сүземне Хәсән Туфан сүзләре белән тәтамлыйсым килә:

Бирде дөнья кирәкне
Еламаска өйрәтте
Кайсыгызның кулы җылы?
Бәйлисе бар йөрәкне.

Бу шигырьгә барлык кимсетелгән, нахакка рәнҗетелгән, ятимнәрнең күз яше, йөрәкләре яраланган тол хатыннарның йөрәк авазлары сыйган.



**Гыйлаҗиева (Исхакова) Фирая Исхак кызы 1938 нче елның 12 августында Эзмә авылында колхозчы гаиләсендә 4 нче бала булып туган.**

Бер абыем, ике апам булган.

Җиде яшемдә 1 сыйныфка Эзмә мәктәбенә укырга кереп 7 класс белем алдым, 8 классны Шәмәрдән мәктәбендә тәмамладым. 9-10-11 классларны Эзмәнең кичке мәктәбендә укып кулга өлгергәнлек аттестаты алдым.

Сугыш башланганда миңа нибары 3 яшь булган. 1940 нчы елда әнием Мәликә, 1943нче елда әтием Исхак вафат булган. Әти – әнисез калгач мине Бәдретдин җизни белән Асылбикә тәтә үз тәрбияләренә алганнар. Үз балалары булмаганлыктан ата - ана назын кызганмый миңа ныклы тәрбия биргәннәр. Кием-салымны сугыш чоры баласы буларак искене яңартып, үзләре тегеп кидерттеләр. Минем абый белән ике апам үги әни тәрбиясендә яшәделәр. Алар басудан черек бәрәңге, алабута, кычыткан җыеп туклана иделәр. Хәтта абыемның алабута ашап шешенгәне хәзерге көнгәчә хәтеремдә. Җизни белән тәтәнең тормышлары яхшырак булу сәбәпле аларда яшәү миңа күпкә җиңелерәк иде. Тамагым тук, өстем бөтен булды, хәтта туганнарыма да өлеш чыгаралар иде. Әти – әни ягыннан сугышка китүче һәм хәбәрсез югалганнарны ишетеп кенә беләм.

Сугыш беткәндә миңа 7 яшь иде. Ул хәбәр авылыбызга бик тиз килеп җитте. Сугыш бетү хәбәрен кемдер шатлыклы күз яше, кемдер кайгылы күз яше белән каршылады. Сугыш беткәч тә авырлыклар күп елларга кадәр сузылды, түләүләр күп булды, ут юк, суны ерактан ташыйсы, мичкә утын ягасы, утынны әзерлисе...

Ирләре сугыштан кайтмаганнарның, әтисез калганнарның тормышлары җиңелдән булмады, авырлык хатын – кыз җилкәсенә төште.

12 яшемдә җизни вафат булганнан соң, тәтә белән икәү генә калдык. Сыер сарык асрап көн күрдек. 8 сыйныфны тәмамлагач Эзмә колхоз конторасында Шайхетдинов Фәрит абый кул астында табельщица булып 5 ел эшләдем. Конторада хезмәт хакы азрак булу сәбәпле, дус кызлар янына фермага эшкә бардым. 20 ел фермада эшләгәннән соң , сәламәтлегем какшау сәбәпле эзмә урта мәктәбенә китапханәче булып урнаштым. Анда 10 ел хезмәт куеп лаеклы ялга чыктым.

Эшләү дәверендә “III – дәрәҗә Хезмәт Даны” ордены, “ Победитель социалистического соревнования 1974 года”, “ Победитель социалистического соревнования 1975 года” медале һәм күп кенә мактау кәгазьләре белән бүләкләндем.

1960 нчыелда 22 яшемдә тормышка чыктым. Әле ул елларда да тормышлар авыр иде. Өйләнешкәч иптәшем Вакыйф печән турагычында уң кулын өздерде. Ул вакыттагы авырлыкларны сөйләп язып бететерлек түгел. Без 1 ул һәм 4 кыз тәрбияләп үстердек. Тормыш иптәшем бик әйбәт кеше булды. Бөтен кешегә ярдәмчел, изге күңелле, сабыр холыклы иде. Әткәй – әнкәйне тәрбияләп соңгы юлга озатып, хәер – фатыйхаларын алып калдык. Иптәшем белән генә тигез гомер итү насыйп булмады.

Бугенге көндә Эзмә авылында улым Хәниф киленем Сәрия тәрбиясендә җылы карашларын тоеп, биш вакыт намазымны укып, Аллахы тәгаләгә хәерле дога кылып бик рәхәттә яшим. Балаларым, унбер оныгым, ун оныкчыгым гел хәлемне белеп торалар.



**Багаутдинова Кафия Кәрим кызы 1937 елның 28 октябрендә Амур өлкәсенең пр Комсомольскида дөньяга килгән.**

Алар семьяда 4 бала булалар.

- Балалалык чорыбыз сугыш вакытларына туры килде. Әниләр алтын прискасында эшләгәнгә күрә, безне тиешле нормада булган паек белән тәэмин итеп тордылар. Әти үтә тырыш булу нәтиҗәсендә, өстәмә эшләрдә дә эшләп, семьябызны кирәгенчә тәэмин итеп торды. Чөнки анда кибетләрдә әйберләр бар иде. Шулай булса да 1950 нче елда әти семьяны Татарстанга алып кайтып урнаштырды.
- 1957елда Казан медицина училищесын тәмамладым. Саба районына фельдшер – акушерлык пунктына эшкә җибәрделәр. Бу вазыйфамда 1995нче елга кадәр эшләдем. Эшемне яратып башкардым. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Эзмә авылында тормыш иптәшем Харис белән, балалар, оныклар игелеген күреп матур гомер итәбез



**Гайсина Маһинур Шәми кызы,1936нчы елның 17нче гыйнварында Саба районы Олыяз авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Маһинурдан кала гаиләдә аннан олырак 2 ир балада була.Абыйлары Фәсхетдин һәм Фәметдин. Маһинур апа сугыш башланганын мәктәптә дәрес укыганда ишетә. Бу шомлы хәбәргә ышаныргамы юкмы дип уйлый ул. Дәресләрен укып бетермичә һәр кеше өенә йөгерә. Ә өйдә борчулы карашы белән әти-әнисе каршы ала, абыйларының сугышка алыначакларын әйтәләр аңа. Шулай итеп 2 абыйсы Бөек Ватан сугышында . Маһинур апа сугыш беткәнен дә мәктәптә ишетә. Бу хәбәр алар өчен аңлатып булмаслык сөенеч була. Кызганыч әмма Фәсхетдин абыйсына сугыштан исән-сау әйләнеп кайтырга язмый. Ул сугыш кырында ятып кала. Бу Фәмиевлар гаиләсе өчен бик зур югалту була. Әти-әнисе дә, Маһинур да Фәсхетдинне бик юксыналар.  Әле ярый икенче абыйсы Фәметдин сугыштан исән килеш кайта. Ләкин ул бик нык яраланган була. Яралары гел сызлап сугыш афәте турында көндә исенә төшереп торалар. Маһинур мәктәптә 7 сыйныф белем ала. Мәктәптә укуны бик ярата, һәр чараларда да актив катнаша. Мәктәп елларын хәзердә сагынып искә ала. Яз җитткәч ул укуын тәмамлый. 1951нче елның көзендә помещик булып эшкә урнаша. 2 елдан соң бухгалтер ярдәмчесе вазыйфасында хезмәт куя. 1958нче елда кияүгә чыга. Колхозда төрле эшләрдә эшли. 1972нче елдан фермада эшли башлый Тырышып хезмәт куйганы өчен аны “Атказанган колхозчы” исеме белән бүләклиләр. 1996 нчы елда пенсияга чыга. Ул заманнарда фермада эшләүе авыр булсада Маһинур апа әле тагын 5 ел сыер савучы булып эшли. Озак еллар ватанга намуслы хезмәт иткәне өчен аңа “Хезмәт ветераны”исеме бирелә. Маһинур апа ире белән бергә 3 бала , 1 кыз һәм 2 малай тәрбияләп үстерәләр.Бүгенге көндә лаеклы ялда. Маһинур апаны улы,килене һәм оныклары карый. Маһинур апаның абыйлары безнең рәхәт тормышыбыз өчен  тырышканнар.





**Фәйзрахманов Нәҗип Газизҗан улы, 1938 елның 26 нчы октябрендә Саба районының матур табигатле Пүкәл авылында туган.**

Нәҗипнең Хәким, Әмин,Сабир,Камил исемле дүрт өлкән абыйлары булган. Гаилә ишле булгач, әти-әниләренә авырга туры килгән.Алар көндә колхоз эшендә эшләгәннәр.Олырак балалар да аларга булышканнар.Авыр булса да Газизҗан ага улларын белемле итәргә тырышкан.Нәҗип 7 классны тәмамлаганда илгә зур кайгы килә. Бөек Ватан сугышы башлана. Бу күңелсез хәбәрне ишеткән вакытта Нәҗип абыйлары белән бакчада тирес түккәннәр.Бу вакытта аңа бары 10 яшь булган.

Нәҗипнең дүрт абыйсы да сугышка алына. Тормышлар авырая. Ашарга да булмый. Су буйларыннан кычытканнар җыеп ашаганнар. Кияргә киемнәр дә булмаган.Капчыктан тегелгән чалбар киеп йөргәннәр. Сугыш бетү турында Нәҗип радиодан ишетә. Ләкин аяусыз сугыш кырыннан 3 абыйсы исән килеш әйләнеп кайтмый. Алар ватаныбыз өчен көрәштә үзләрен корбан итәләр. Абыйларының үлем хәбәрләрен ишетү Нәҗип һәм аның әти-әнисе өчен бик авыр була. Камил абыйсы гына исән-сау әйләнеп кайта.

Хәзерге вакытта Нәҗип абый Пүкәл авылында үзе генә гомер кичерә.



**Шәяхмәтова Флера Хәлил кызы, 1939 нчы елның 14 апрелендә Байлар Сабасында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә.**

Сугыш башланганда аңа 2 яшь була. Сугыш башланып озак та үтми әтисе сугышка китә. Ә 1943нче елда Хаҗип абыйсын да сугышка алалар. Атышлар вакытында әтисе уң кулының ике бармагын өздерә һәм 1943 елда инвалид булып өйләренә кайта. Әтисенең ккайтышы абыйсының барган вакытлары булып ничектер икесе хәрби частьта тиз генә очрашып та алалар. Хаҗип абыйсының башта сирәк кенә булса да хатлары килгәли һәм һәлак булуы турында хәбәре килә.

Флера апа Саба мәктәбендә 7 класс белем ала. Алга таба белем алу түләүле булгач укуын дәвам итү мөмкинчелеге булмый. Олы бала булгач йорттагы авыр эшләрнең дә күберәге аңа туры килә. Әти – әниләре эшкә бик иртә таңнан караңгыга хәтле эшләгәч көтү куу, каршылау, ерак чишмәләрдән су ташу һәм башка йорт эшләрен кечкенәдән эшләп үсәргә туры килә. Әтисе урман бригадиры булып эшли. Аның белән күп тапкырлар атка утырып урманга барганнары, урман эчендә бик оста орентлаша алуларын искә алып сөйләде.



1956нчы елның сентябрь аеннан Сабада пекарняда хезмәт юлын башлый. Ул вакытларда барлык эшләр дә кул хезмәте белән була. Бер юлы бер мичтә 140 ар ипи пешерәләр. Анда 3,5 ел эшли.

1950нче елдан Эзмә авылы егете Муса абый белән тормыш коралар. Эзмәгә килгәч тә фермада таналар карый. 1961нче елдан мәктәптә техник хезмәткәр булып эшли башлый. Иртәнге сәгать 2 дә барып мичене ягалар. Утынны да үзләре я урманнан әзерләп алып кайталар, я Шәмәрдәнгә килгән вагоннардан тракторларга төяп алып кайтып , кисеп, ярып әзерлиләр. Яңа мәктәп салу эшләрендә дә тырыш хезмәт куя. 35 ел мәктәптә эшләп лаеклы ялга чыга. Алар 3 кыз тәрбияләп үстерәләр. Әниләре Мәүлиха әбине тәрбияләп соңгы юлга озаталар. 20 елдан артык гомер иткән, яраткан тормыш иптәшен югалту ачысын кичерә. Бүгенге көндә Эзмә авылында балаларының, оныкларының күңел җылысын, ярдәмен тоеп яши.





**Галиәхмәтова (Тимерханова) Гөлчирә Тимерхан кызы,1936 нчы елның 2 октябрендә хәзерге Татарстан Республикасы Саба районы Олыяз авылында колхозчы гаиләсендә туа**

Әтисе үлгәндә ул бер айлык бала булып калган.Әниләре дүрт бала белән калган.Балачактан ук төрле михнәтләр,мохтаҗлыклар күреп үсә ул.Олы апасына 12 яшь,уртанчасына 3 яшь булган.Иң олы абыйсы Дәүләтхан 15 яшендә салкын тиюдән терелә алмыйча,якты дөньядан китеп барган.7 класс белем Гөлчирә апа сүзеннән язылa:”Ул елларда ачлык еллары,тормышыбыз бик авыр булды. Әни колхозда эшләде. 1941 нче елның 22 нче июнендә,әни эштән елап кайтып керде.Балалар сугыш башланган диде. Өйдә ашарга бер кашык он да юк иде. Киемнәрдән иске-москы,бер телогрейка,бер шәл.Аяк киемнәре бөтенләй юк иде.

Укырга барганда апа телогрейка, ә мин шәлгә төренеп бара идек.Барып җиткәч, телогрейканы кочаклап кире өйгә йөгерә идем.Әнигә биреп тагын мәктәпкә барам.Әни киенеп эшкә китә.Барыбызга бер кием иде бит.Әнине атлы эшкә куйгач,аның урынына агамны сарык карарга алдылар.Җәй көне агаларга ияреп җиләккә йөргәнемне хәтерлим.Җиләкне юкә яфрагына төреп ашый идек.Ә калганын Шәмәрдәнгә алып менеп саталар.Әни кайтканчы кычыткан җыеп чабып куя идек.Язга чыккач ялан аяк басуга черек бәрәңге җыярга барасы иде.Ул черек бәрәңгедән күмәч шундый тәмле иде!Чабатаны әни үзе ясады,аңа бик сөендек.Кыш көне урамнан кергәч әни аякларны салидол белән уып төреп куя иде.Җәй көне әрекмән яфрагы белән төрә иде.

Безнең йорттан армиягә китүче булмады.Безгә бик авыр булды,солдат

семьясыннан түләү(налог) 500 сум,ә бездән 1000 сум алалар иде.

7 нче классны бетергәндә җәй Чүрилегә кортчылыкка укырга җибәрделәр. 15 яшемне Лаеш районы Атабай авылында тутырдым. Агач баса язгач, яшь урманчы дип кайтарып җибәрделәр. Авылда председатель фермага дуңгыз карарга куйды. Ул вакытта 15м тирәнлектәге (25м) коедан 100 чигән су ташыйсы, бәрәңге пешереп төясе. Җилкәгә ике көянтә куеп 4 чиләкләп ташый идек.

Шулай да, көч калмаса да, кичке уеннан калмадык. Аякка чабата киеп чыктык. Соңыннан еврей галошы чыкты, ул йомшак иде. Шәяхмәт белән кичке уенда таныштык. Ул гәүдәле, озын, матур егет иде. 4 ел танышып йөргәч кавыштык. Декрет ялында 40 көнлек бала белән Пермский крайга ботак чабарга киттек. 1970нче елда шушы Азин ПМКсына ашханәгә эшкә кайттым. Шәяхмәт белән тигез гомер иттек ,дүрт бала үстердек. Ашхандә эшләгәндә Мактау кәгазе белән бүләкләделәр. Аннан кибеткә куйдылар. Шуннан лаеклы ялга киттем.



Хәзерге көнемнән бик канәгать! Аллага шөкер!Без күргәннәрне бер үк балалалрга Ходай күрсәтмәсен!Илләребез тыныч булсын! Балаларымның, оныкларымның, кияү-киленнәремнең хөрмәтендә яшим, Ходай шуннан аермасын!

*Лилия Габдрахманова, Эзмә урта мәктәбенең 7 класс укучысы*



**Мифтахов Зиннур Мифтахетдин улы, 1942 нче елның 12нче гыйнварында Саба районы Өтернәс авылында туган.**

“Мин - сугыш чоры баласы, үземне беләә башлаганнан бирле, тулы гаиләле кешеләргә кызыгып үстем, чөнки беркайчан да «әти» дип дәшәргә, алай гына да түгел, гомер бүләк иткән газиз кешемне бер тапкыр да күрергә насыйп булмады, - дип сөйли бабаем. - Мин 1942нче елда - сугышның иң авыр чорында дөньяга килгәнмен. Әтием Мифтахетдин, аның олы улы - абыем Мисбах яу кырыннан әйләнеп кайтмады, икесе дә хәбәрсез югалды. Әнием Миңзифа, абыйларым Әнәс, Габбас, Ранур сугыш елларының иң авыр газабын бергәләп күтәрде. Ачлыгын да, өс киемнәре юклыгын да йөрәкләре аша кичерделәр. Минем дә сабый чагым сугыш вакытына һәм аннан соңгы авыр елларга туры килде. Кыскасы, бәхетле балачак күрмәдек без”.

Әйе, фронтовик Мифтахетдин улына, бабаем Зиннурга, яхшырак тормышлы кешеләрнең балалары белән урта белем алырга да насыйп булмый. Яшьтән колхозда эшли башлый ул. Аттестатны да Эзмә авылының кичке мәктәбендә укып ала. Аннары урман техникумы, Башкортстан якларында эшләү, хәрби хезмәт, Арча урман пунктында техник эшләр буенча җитәкчелек... Шулай бервакыт, әнисе янына ялга кайткач, бабайны клубка чакыртып алалар. Аны Азин исемендәге механикалаштырылган мелиорация станциясенең дәрәҗәле директоры Миңнәхмәт Халит улы Сабитов көтеп тора икән. «Энем, «чут»та сала беләсеңме?» - дип сорый ул егеттән һәм баш икътисадчы булып эшкә кайтырга тәкъдим ясый. Бу 1968 ел була. Шулай итеп, 26 яшьлек Зиннур Мифтахов туган авылы Өтернәс янәшәсендәге абруйлы мелиорация оешмасында яңа хезмәт юлын башлап җибәрә һәм лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли, читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Киев, Омск кебек зур шәһәрләрдә белемен күтәрә. Тугыз ел икътисадчы вазифасын үти, ә инде 1977 елда баш инженер итеп куела. 1986 елда легендар җитәкче, РСФСРның атказанган мелиораторы Миңнәхмәт ага Сабитов лаеклы ялга киткәндә үз урынына Зиннур Мифтаховны калдыра. Ул бу коллективны нәкъ ун ел җитәкли. “Дөрестән дә, бердәм һәм эшчән иде безнең ПМК эшчеләре, - дип сүзен дәвам итә бабам. - Уртак тырышлык белән чын мәгънәсендә таулар

күчердек. Хуҗаларыбыз турыдан-туры ярдәм иттеләр. Бигрәк тә генераль директорыбыз Анатолий Константин улы Самфенкинны хөрмәт белән искә төшерәм. Гомумән, туган коллективыма, үземнән соң эшләгән җитәкчеләргә, аеруча хәзерге директорыбыз Илдус Ислам улы Талиповка бик зур рәхмәтлемен. Ул мине, пенсиягә чыккач та, ике ел чакырып, прораб итеп эшләтте. Кыскасы, Илдус Ислам улы Саба ПМК «Мелиорация» ачык акционерлык җәмгыяте коллективын бүгенге шартларда яңа биеклекләргә күтәрде. Билгеле инде, район хакимияте башлыгы Рәис Нургали улы Миңнеханов, «Татмелиорация» трест кампаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Әнвәр Мәхмүт улы Залаков ярдәменнән башка түгел. Тагын бер мәртәбә рәхмәт аңа”.

...Менә шулай, узган эшләргә анализ ясап, мелиораторларыбызның бүгенге уңышларына сөенеп гомер итә минем бабам - Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы Зиннур Мифтахетдин улы. Иң мөһиме - күңеле тыныч аның. Гаиләсе бөтен, гомер иткән тормыш иптәше – әбиебез Сания исән-сау, уллары Рөстәм белән Рушан да үз тормышларын булдырганнар, хәзер инде алар без – оныкларының уңышларына куанып гомер кичерәләр. Әле тагын озак еллар тигезлектә, исән-сау яшәргә язсын.



*Азалия Мифтахова, Ээмә урта мәктәбенең 3 сыйныф укучысы*



**Шаһабиев Самат Шәмсетдин улы, 1939 нчы елның 3 июлендә Саба районы Олыяз авылында колхозчылар Шаһабиев Шәмсетдин белән Бибинур гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килгәнмен.**

Сугыш башланганда миңа әле ике яшь тә тулмаган булган. Сугышның беренче көннәреннән үк әти һәм аның бертуган абыйсы Хәкимулла, илебезне саклау өчен сугышка киткәннәр. Шул китүдән алар өебезгә башка әйләнеп кайтмаганнар, бары тик хәбәрсез югалды дигән хәбәрләре генә килгән. Кыскасы, миңа әти дигән назлы сүзне бер генә тапкыр да әйтеп карау, әтинең җылы кочагында иркәләнүләр насыйп булмады.

Әти сугышта вакытта сеңлем Рушания туган. Кызганыч, ул да яшьтән үлеп киткән. Ул чорларда һәркемнең үзәгенә үткән ачлык- ялангачлык безне дә читләтеп узмады.

Сугыш тәмамлангач, 1947 нче елны Олыяз башлангыч мәктәбенә укырга кердем. 1954 нче елда Эзмә җидееллык мәктәбен тәмамладым. 13 яшьтән колхозда төрле эшләрдә эшләдем. Шәмәрдән ашлык хәзерләү пунктында ат белән ашлык ташыдым.

1973 нче елда гаилә корып, тормыш иптәшем Илгизә белән бер малай, ике кыз үстердем. Олы кызым Свердловскида, малаем белән кече кызым Олыяз авылында үз гаиләләре белән яшиләр. Бүгенге көндә алты оныгым бар. Тормыш иптәшем Илгизә белән тигез гомер кичерәбез.



**Халиуллин Рафил Мотыйк улы, 1941 нче елның 20 маенда Саба районы Иләбәр авылында Мотыйк һәм Бибиниса апалар гаиләсендә 2нче бала булып дөньяга килә.**

Сугыш башланганда Рафил абыйга бары тик 1 ай гына була.Ә инде сугыш беткәндә 5 яшь була.

Башлангыч белемне Иләбәр башлангыч мәктәбендә Сабитова Мәрзия апа классында укый.Эзмә сигезьеллык мәктәбендә Сабитова Бәнәнә апа классында 8 класс белемне ала.

Колхозда төрле эшләрдә,тракторист приципчигы ,борчак чабуда,яшь егетнен көченнән килгән бар эштә дә эшли.1 сутый борчак чапкан өчен бер хезмәт көне өчен 5 тиен акча түләгәннәр.

Кукмарага шофёр булу теләге белән курсларга укырга керә,аны тәмамлап кайткач, Азин җитен комбинатында шофёр булып эшли.

Сугышка әтисе Мотыйк абый1941нче елның октябрендә киткән.1942нче елда аягы каты яраланып госпитальгә эләгеп анда аның уң аягын кисәләр һәм терелер-терелмәс Мотыйк абыйны туган авылына кайтаралар.

Сугышлар тәмамланып тыныч тормышта яши башлагач, күктә очкан сомолетларны күреп әтиләре сугыштан кайтмаган малайлар “Әтине кайтарыгыз” дип елый-елый урам буенча кычкырып йөгерә иделәр дип искә ала Рафил абый бу аның иң исендә калган хәтирәсе күңел түрендә саклый ,чөнки аның әтисе сугышта бер аягын калдырып булса да исән кайткан бит.

22 яшь тулгач Совет Армиясенә Ватан алдында хәрби бурычын утәргә китә. Элекеге Свердловск хәзерге Екатеринбург шәһәрендә 3 ел солдат хезмәтендә дә машина йөртүче булып хезмәт итеп , туган авылына исән имин кайта.

Армиядән кайткач, Саба сельхоз-техника оешмасында өр-яңа ЗИЛ машинасында эшли башлый.2 ел эшләгәннән соң, ПМК-12 оешмасында шофёр булып төрле техникада хезмәт куя.1980 елда “Киров” исемендәге колхозга шофёр булып эшкә урнаша.Лаеклы ялга чыкканчы, үзенең шофер һөнәренә тугры калып колхозда эшли.Гомуми шофёр стажы 42 ел тәшкил итә.2001нче елда пенсия ала башлый.1970нче елда Рафил абый Иләбәр авылы кызы Мәдинә апа белән тормыш корып яши башлыйлар.

1971нче елда кызлары Резида, 1976нчы елда уллары Рафис, 1984 нчеелда Ирэк туа.

Әтисе Мотыйк абый 1985 нче елда,әниләре Бибиниса апа 1987нче елда вафат булалар.

Бугенге көндә төпчек уллары Ирек гаиләсе белән яшиләр. 1977 нче елның 1нче июнь – ПМК-12 оешмасында югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен мелиораторлар көне уңаеннан Мактау кәгазе белән бүләкләнә. 2001нче елның “Хезмәт ветераны” таныклыгы тапшырыла.



**Шәрипов Фәрит Шәрип улы, 1941нче елның 4 нче декабере көнне Саба районы Эзмә авылында туган.**

Ул туганда инде 6 ай элек үк әтисе сугышка киткән булган. Фәрит әнисе һәм әбисе тәрбиясендә яшәгән.

Фәрит абый үзенең тормыш юлы турында менә ниләр сөйли:
-Авыр еллар булгач, ике гаилә бер йортта тору гадәте бар иде, без дә әтинең энесе Миннемулла абыйларның гаиләләре белән бергә аларның өендә яшәп тордык. Сугыш беткәндә мин 3-4 яшьлек бала булганмын. Миннемулла абый сугыштан бер сыңар аяк белән кайткан иде. Минем аркамнан сөеп алып, “сугыш бетте энем, әтиең генә кайта алмады”,- дигәне бик нык хәтергә уелып клды. Кечкенә булсам да, әтиемнең кайта алмавын бик авыр кичердем, бик озак еладым. Миннемулла абый безнең үз нигезебездәге бик нык тузган, кечкенә генә өебезне рәтләштергәләп безне шунда урнаштырды. Без авырлык белән булса да үз өебездә яшәвебезне дәвам иттердек. Әтисез тормыш үзен бик нык сиздерде. Балачак әнә шулай әтиле балаларга кызыгып үтте. Эзмә сигезьеллык мәктәбендә 8 класс белем алдым. Хәрби хезмәткә китәсе елны Кукмарада шоферлар курсында укыдым. Акча җитмәү сәбәпле, анда велосипед белән йөреп укыдым.

1962-1964нче елларда хәрби хезмәттә булдым. Аннан кайткач, “Киров” исемендәге колхозга шофер булып эшкә урнаштым. Иләбәр авылы кызы Флера белән тормыш корып, 1 кыз, 2 ул тәрбияләп үстердек. Хезмәтемә тугры калып, гомер буе шул ук колхозда шофер булып эшләп лаеклы ялга чыктым. Хезмәтемне дә күрә белделәр: колхоз һәм район тарафаннан күп тапкырлар Мактау грамоталары һәм Дипломнар алдым. Хәзерге көндә Эзмә авылында тормыш иптәшем белән бергә балалар, оныклар игелеге күреп бәхетле гомер кичерәбез. Сугыш афәтләре сәбәпле бер тапкыр да “әти” сүзен әйтә алмавым гына йөрәкне әрнетеп тора.



Март, 2016 ел.




**Хажиәхмәтова Мәгъшия Гобәйдулла кызы, 1939нчы елның 3нче апрелендә Саба районының Түбән Шытсу авылында беренче бала булып дөньяга килгән.**

Мәгъшия апа сөйләгәннәрдән:

-Миннән соң туган 1941нче елгы Рәхимҗан исемле энем бар. Мин сугыш башланганда кечкенә булганлыктан, аның бөтен нечкәлекләрен хәтерләмим. Бабаемның: “әнә, сугыш безгә дә килеп җитә, бомба шартлаганнары ишетелә”,-диеп әйтүе истә. Безнең әтине сугышка алмадылар, сугыш башланганда ул авыл советы председателе булып эшләгән. Ул шахтага китеп анда күмер чапкан, әзрәк укый-яза, русча белгән. Аны сугышка җибәрмәгәннәр, бронь белән калдырып, җимерелгән колхозга Шайтан Елга дигән авылга хуҗалык җитәкчесе итеп җибәргәннәр(хәзерге Урта Саба авылы) , сугыш беткәнче шунда эшләгән.Ул Сталин колхозы дип аталган, соңыннан сөйләгәнәрдән ишеттем. Әлеге колхоз Татарстанда ук алдынгы урынга чыккан, әтием дини булган, аңа Аллаһы тәгалә ярдәм иткәндер инде, бер белемсез колхоз җитәкләргә. Миннән кечкенә сеңлем туды һәм үлеп китте, ул аны да күрмәде һәм күмәргә дә кайта алмаган. Әниебез колхоз эшендә йөрде, безнең карт бабай бар иде, бик кырыс булды.

Без энем белән кечкенә булсак та, колхоз эшенә, чүп утарга, башак җыярга йөрдек.

1946нчы елда 1нче класска укырга кердем, берәр карандаш бирделәр, ниндидер кәгазьдән дәфтәр шикелле нәрсә тектек. Шуларны чүпрәккә төреп мәктәпкә барган хәтердә. Кар бетә башлауга, бакчадан черек бәрәңге җыя идек, ул хәзерге кебек черми, крахмалланып тора иде. Әни аннан күмәч пешерә иде. 5нче класста

укыганда Сталинец дигән трактор өстерәп йөри торган комбайн бункерыннан ашлык алып тордык. Бункерның агыза торган тишеге бар иде, шуннан бер кыз белән капчыкка ашлык агызып, капчык авызын бау белән бәйләп, җиргә төшереп калдыра идек.

1953нче елда 7нче классны бетергәч, Саба урта мәктәбенә 8нче класска укырга бардык. 15ләп бала барган идек, 10 нчы классны бер үзем генә бетердем. 8-9нчы классларда укыганда җәйге каникулда звеновод булып эшләдем, әниләрнең көлтә бәйләгән җирләрен үлчәп йөрисе иде.

Мәктәпне бетергәч медучилищега укырга кердем, яхшы билгеләргә генә тәмамладым. Олыяз авылына эшкә җибәрделәр, шунда Әхмәт дигән егеткә кияүгә чыктым. 2 бала тәрбияләп үстердек. 34 ел эшләп лаеклы ялга чыктым, Мактау кәгазьләре алып эшләдем. Тик гомер буе тырышып эшләп тә, Хезмәт ветераны исемен дә бирмәделәр.



Бүгенге көнемә Аллага шөкер диеп яшәп ятам. Күрәсен күрдек, инде башка андый хәлләрне күрергә язмасын беркемгә дә.

*Язманы кызы Лилия Әхмәтҗанова әзерләде.*



**Хаҗиәхмәтов Әхмәт Хаҗиәхмәт улы, 1938 нче елның 3нче августында Саба районы Олыяз авылында туа.**

Әтисе сугышка киткәндә әниләре белән 3 малай ярым җимерек өйдә торып калалар. Кыш чыгу өчен әнисенең туганнарына Шәмәрдәнгә менеп торалар, чөнки өйләрендә кыш көне яшәрлек булмый. Кыш көне тимер юлда эшлиләр- әнисе дә, үзе дә. Җәй җитүгә тагын авылга төшәләр, колхозда эшлиләр. Шулай ике арада йөри торгач 2 малай чирләп үләләр, әтием үзе генә кала.

4 класс укыганнан соң тимер юлда төрле эштә эшли башлый. Әтисе сугыш беткәч тә кайта алмый, әсирлеккә төшкән була. Кайткач, “без йөргән җирдә үлән дә үсмәс, ачлыкка чыдый алмыйча үләннең тамырларын да казып алып ашадык, бакалар ашадык”,- диеп сөйләгән. Кайткач атлар карый.1947нче елда атларга басудан ашлык чүбе алып кайткач, 1чиләк өенә дә алып кайта. Шуны каравылчы колхоз рәисенә әләкли, милиция чакыралар, үлчәгәч, 5кило чүп була. Менә шуның өчен аны төрмәгә утырталар. Әтисе киткәч, бер кыз туа. Әсирлектә булганнарны Себергә сөрәләр, ул шунда үлә.Хәерчелек чигендә яшәгәннәр. Әнисенә дә, балаларына да бер ярдәм дә булмаган, гомер буе әтиләре булган кешегә кызыгып яшәде.

1958нче елда армиягә китеп, хезмәт итеп кайта.Тракторчылыкка укый, 1ел Казахстанда эшли. Матур гаилә корып , 1ул, 1кыз үстерделәр. Гомер буе үз көчләре белән тырышып яшәделәр.

Пенсиягә чыкканчы колхозда механизатор булып эшли.

2002нче елның 8 июлендә вафат булды, Олыяз авыл зиратында җирләнде.

*Кызы Лилия Әхмәтҗанова истәлекләреннән.*





**Хәмидуллина Фәния Нуретдин кызы(Габдрахманова), 1941нче елның 1нче августында Саба районының Мичәнбаш авылында туа.**

Фәния апа сөйләгәннәрдән:

-Әтием Нуретдин тимерче, әнием Мәрфуга колхозчы иде. 1936нчы елгы абыем Мөдәрис, 1938нче елгы апаем Мәсхүдә. Әтием сугышка киткәндә мин 2 айлык булып калганмын. Ул хәбәрсез югалды. Мин әнине бик аптыратканмын, әти нинди була икән, диеп. Ачлык - хәерчелек. Басудан черек бәрәңге җыеп ашадык, борчак ашарга басуга барсаң куалар иде, кычыткан ашы - кычыткан алып калды инде безне. Ач булдык, ипи нинди була икән,- дия идек. Күтәртмәле чабаталар белән йөрдек, 8 класс укыдым Шәмәрдәнгә йөреп, капчыктан сумка тегеп бирде әни. Сугыш вакытында да сыерны бетермәдек, шул да саклагандыр инде ач үлемнән. Мичкә салам якканыбыз истә.

17 яшемдә колхозда фермада эшли башладым, дуңгыз да , бозау да карадым.

1967нче елда Пүкәлгә килен булып килдем, монда да колхозда эшләдем, сыерын да саудым, тегермәндә эшләдем. Соңыннан пенсиягә чыкканчы амбарда төрле эштә булдым.



Бер улым булды, бүгенге көндә улым Марсель һәм киленем Миләүшә тәрбиясендә яшим. Ирем Мөхәммәтнур инде вафат.

Бүтән сугышлар, ачлыклар булмасын.Балалар безнең кебек бер тапкыр “әти” дияргә тилмереп үсмәсеннәр. Күрдек инде барысын да, бүгенге көнемә шөкер итеп, шатланып яшим.

Язманы Лилия Әхмәтҗанова әзерләде.



**Хәмзин Шәукәт Хәмзә улы 1942 нче елның 1нче мартында Саба районы Пүкәл авылында колхозчылар гаиләсендә туа.**

Әтисе - Хәмзә (1915), әнисе Маһидилбәр (1918). Әтисен сугышка алалар, ул НКВД да кече сержант була. Ул вакытта кеше күргәннең барысын да күргәннәр, ашарларына булмаганнарын елый - елый сөйли иде, кайчан туйганчы ипи ашарбыз, өстәлебездә ипи торыр дип сөйләшкәнәрен. Бала вакытта төрле эшләрдә эшләгән, атлы эштә дә йөргән.

7 класс бетергәннән соң, комбайнчы ярдәмчесе булып колхозда эшли башлый. Армиядә Пермьдә хезмәт итә һәм шунда яшәргә калып, гаилә кора. Ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасында шофер булып эшләде. 2 малай тәрбияләп үстерделәр.





2012 нче елның 5нче февралендә вафат булды, Пүкәл авыл зиратында җирләнде.

*Сеңлесе Әлфинур Джураева сөйләгәннәрдән язып алынды.*



**Файзуллина (Завылова) Җәүһәр Фазлыйәхмәт кызы, 1934нче елның 10нчы мартында Саба районы Иләбәр авылында туган.**

Сугыш башланганда әтисенә 50яшь тулып китү сәбәпле, сугышка алмыйлар. Җүһәргә 7 яшь була. Алар ике кыз үсәләр. Өлкәннәрнең кул арасына кереп, көч җиткән барлык эшләрне дә башкаралар. Аның яшьлеге сугыштан соңгы авыр елларга туры килә. 14-15 яшьләр тирәсендә инде урман кисәргә йөриләр.

1958нче елда Эзмә авылы егете Гыйльмулла белән тормыш коралалар. 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Лаеклы ялга чыкканчы “Киров” колхозында төрле эшләрдә эшли. Бүгенге көндә Эзмә авылында балаларының игелеген күреп, улы Фердинант тәрбиясендә яши.



*Язманы кызы Минсәрия Мәүлитова әзерләде.*



**Сафиуллин Мәгънәви Гозәер улы,**

**1931нче елның 1нче октябрендә Саба районы Пүкәл авылында туган.**

Әтисе Гозәер – оста тегүче була, Пүкәл артилендә эшли. Әнисе Хәдичә – колхозчы булган. Гаиләдә 6 бала, дәү әти дүртенчесе була. Авылда аларның гаиләләре бик тырыш һәм үрнәк гаиләләрдән саналган. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа бары тик 10 яшь кенә була. Авыл мәктәбендә 7 класс белем ала. Сугыш чорында колхоздагы барлык авыр эшләрдә катнаша. 18 яше тулгач, Совет Армиясе сафларына алына, 3 ел Камчаткада хезмәт итә. Армиядән кайткач, Арча районы Үрнәк авылында механизатор һөнәрен үзләштерә. Шуннан соң гомере буе, 1972нче елга кадәр Киров исемендәге колхозда, тракторда эшли. Ул һәрвакыт үзенең тырыш хезмәте белән алдынгылар рәтендә була. 1959нчы елда дәү әнием Рузания белән тормыш коралар, 4 малай әтисе була, тик аларны үстереп, аякка бастыру аңа насыйп булмый. 1975 нче елның 1 нче сентябрендә каты авырудан соң дәү әти вафат була.

Март,2017

*Язманы оныгы - Касыйм Сафиуллин әзерләде*

*Эзмә урта мәктәбе 9 нчы сыйныф укучысы.*



**Саматов Барис Салих улы, 1941 нче елның 24 нче августында Саба районы Өтернәс авылында туган.**

Хәтердә калганнардан: ишле гаиләдә үстек, ашарга юк иде инде. Яз көне басуда трактор сукалаган артыннан черек бәрәнге жыюлар, шуны әнигә алып кайтып биреп, әни шул черек бәрәңгедән күмәч пешереп ашата торган иде. Өйләргә ягарга утын да юк иде, саламнарга хәтле ягып жылыттык өйне. Әти Бөек Ватан сугышыннан бер күзсез, бер кулсыз булып кайтты. Малларны, кош - кортларны санаулы гына асрарга ярый, артыгын асрасаң, алып чыгып китәләр. Мин 2нче класстан алып 7нче классны бетергәнче сарык көтүе көттем ялан аяк чөнки элек гаиләдә бит без ишле устек: 7 бала, әти - әни белән 9 кеше. аякка кию юк иде, салкында чабата кидек. Әтиебез 1956нчы елда каты авырудан соң үлеп китте. 7нче класстан сон “Игенче” колхозында ат жигеп төрле эштә эшләдем, шуннан 1964нче елның көзендә Янилгә механизаторлар курсына укырга киттем. 1965нче елнын ноябрендә тәмамлап, армиягә киттем. Анда 3 ел Казахстаннын Дружба шәһәрендә хезмәт иттем. 1968нче елнын ноябрендә армиядән кайткач, Азин МТСына тракторчы булып эшкә кердем һәм пенсиягә чыкканчы шунда хезмәт куйдым.
1969нчы елнын 14нче июлендә Сәрдә авылында туып - үскән Хөсенова Әлфия Хажиәхмәт кызы белән гаилә кордык. Биш бала тәрбияләп үстердек. Бүгенге көндә балаларыбызның, оныкларыбызның куанычын, игелеген күреп Иләбәр авылылында кече улыбыз Зөлфәт гаиләсе белән яшибез.
Хезмәтемнең нәтиҗәсе булып түбәндәге грамоталарым саклана.
-Почётная юбилейная грамота за самоотверженный труд выполнение плана 2-х лет 12-ой пятилетки к 70-летию - 06.11.1987год.
Почётная грамота награждается машинист трубоукладчик за высокое производственные показатели в социолистическом соревновании и в честь дня Мелиорации - 05.06.1987год.
*Язманы улы Зөлфәт Саматов әзерләде.*



**Сәләхиев Ринат Абдулла улы,1944нче елның 24нче ноябрендә Саба районы Эзмә авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Эзмә мәктәбендә 8 класс белемен ала, кичке укуга күчеп, 11 класс укып бетерә.

Әтисе, Сәләхиев Абдулла Сәләхетдин улы, 1942нче елда сугышка китә. 1943 елда яраланып госпитальгә озатыла һәм каты яралану сәбәпле, туган ягы Эзмәгә кайта.

1962 -1963нче елда Кукмара районы Янил авылындагы училищеда тракторист белеме алып, Киров колхозына 1964нче елда тракторчы булып эшкә кайта, 2004нче елга кадәр эшләп лаеклы ялга чыга. Яхшы эшләгән өчен дипломнар, грамоталар белән бүләкләнә.

1966 нчы елда Сәмигуллина Ләлә белән гаилә коралар. 2 бала тәрбияләп үстерәләр һәм тормыш юлына аяк бастылар.

Бүгенге көндә хатыны Ләлә белән бәхетле гомер итәләр.







**Нурмиева (Билалова) Зәбидә Нурислам кызы, 1939 нчы елның 30 нчы мартында Саба районы Олыяз авылында туган.**

1941нче елда әти Бөек Ватан сугышына китә. Ул киткәндә миңа 2 яшь, апага - 5, абыйга 9 яшь була. Тумый калган 4 нче бала 1941нче елның гыйнварында туа. Бер әнигә дүрт бала. Кечкенә баланы да әни эштә булгач, абыйга карарга туры килә. Абый болыннан атлык, әнис, кычыткан җыеп алып кайта, әни кычытканны ваклап йомарлап куя. Вак кына бәрәңгене чабып, кычыткан салып абый әнинең кайтуына аш пешерә. Буе җитмәгәч казан янына урындык куеп, шунда басып ашны бушата иде. Әни алабута, өшегән бәрәңге җыеп шуннан күмәч пешерә иде. Өйне салам көлтәсе, агач ботаклары җыеп җылыталар иде.

Әти сугыштан 1945 нче елның август аенда госпитальдән кайта. 2 тапкыр яралана ул. Капка төбенә машина килеп туктагач урамга чыккан идек, әтине ике солдат озата кайткан иде. Ул вакытта апай чишмәгә суга киткән иде, мин аңа әти кайтканын әйтергә йөгердем. Ул йөгереп кайтып суын түгеп бетерә язды.

Авылдашлар килде, әти өстәл янында мине алдына алып сөеп утырганын хәтерлим. Күп кенә шәһәрләрне азат итүдә катнашканы өчен Сталин приказы белән бирелгән рәхмәт кәгазьләре бик күп иде әтинең.

Сугыштан соң тагын бер бала туып без бишәү үстек. Әти авылда артельдә эшләде. Аннан соң колхоз рәисе, авыл советы рәисе булып эшәп пенсиягә чыкты.

Мин 1958 нче елда Саба урта мәктәбен тәмамлап, Явлаштау, Миңгәр авылларында клуб мөдире булып эшләгәннән соң, 1961нче елда Пүкәл авылына китапханә мөдире итеп билгеләделәр.

1962 нче елда тормышка чыктым, ике бала тәрбияләп үстердек. 1965-67 нче елларда читтән торып укып Алабуга мәдәният агарту училищесының китапханә бүлеген тәмамладым.

Эш дәверендә җәмәгать эшләрендә актив катнашкан өчен В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан медаль белән бүләкләндем. 1974нче елда “Иң яхшы эшләүче китапханә” исеме бирелде. 1977нче елда Казанда уздырылган мәдәният хезмәткәрләре съездында катнаштым. 1986нчы елда “Хезмәт ветераны” исеменә лаек булдым. Хезмәтем өчен РСФСРның, Татарстан мәдәният министрлыгының, район мәдәният бүлегенең күп кенә диплом һәм мактау кәгазьләре белән бүләкләндем. 1991нче елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” исеме бирелде. Пенсиягә киткәнче Пүкәл авыл китапханәсендә эшләдем.

Бүгенге көндә Олыяз авылында Шәүкәт белән тигезлектә, улыбыз Ришат тәрбиясендә яшибез.



## Нурмиев Шәүкәт Фазли улы, 1939нчы елның 25нче июнендә Саба районы Эзмә авылында туган.

Миңа ике яшь вакытта әти сугышка киткән. Бала вакыт ачлык белән истә калган. Басудан өшегән бәрәңге эзләп, кычыткан, атлык белән тамак ялгап үстек. Ягарга утын булмагач, Мәүлиха апаларга кереп бергә тордык. Мин әнигә үзем генә булсам да, Мәүлих апаның өч баласы бар иде.

Әти сугыштан яраланып кайтты. Аны Казанга госпитальгә җибәрделәр. Аннан кайтып озак яши алмады, савыкмады, үлеп китте. Әтине күмәргә барганда мине арбага утыртып алып барганнарын хәтерлим.

1950нче елда Олыяз авылына күченеп мендек әни белән. 12 яшьтән ат җигеп эшли башладым, көлтә ташыдым, ындырда эшләдем. Олыязда кичке мәктәптә 7нче классны тәмамладым.

1958нче елда армиягә барып, 3 ел хезмәт итеп кайттым.

1962нче елда өйләндем. 1963-1964нче елларда Арчада профтех училищеда укып, тракторист – машинист белгечлеге алдым. Пенсиягә чыкканчы колхозда механизатор булып эшләдем.

Зәбидә белән ике бала: бер кыз, бер ул тәрбияләп үстердек. Рәмзия кызыбыз Казан медицина училищесын тәмамлап, медсестра булып эшли. Ришат улыбыз Казан ветеринария институтын тәмамлап, мал табибы булып эшли. 1988нче, 1990 нчы елларда “Колхозның иң яхшы механизаторы” дигән Диплом белән бүләкләндем. Бүгенге көндә Олыяз авылында Зәбидә белән улыбыз Ришат тәрбиясендә рәхәт гомер итәбез.



**Мавлетова (Кадыйрова) Закирә Хөсәен кызы, 1940нчы елның 15нче августында Саба районы Пүкәл авылында колхозчы гаиләсендә туа.**

Әтисе Хөсәен(1907), әнисе Заһидә(1913).

Закирә апа сөйләгәннәрдән:

-Әтием сугыш башлануга китте, 1945нче елны кайтты. “Әти кайта!” - диеп сөенче алганнарын бүгенгедәй хәтерлим .

Әнием 2 ат белән сука сукалады, берсен ял иттерә иде. Мин балалар белән анның янына баргач, мине ат талады, чәчләрем дә калмаган иде.Әнием мине елый-елый кулына күтәреп кайткан, үлсә, атасына ничек җавап бирермен, диеп. Ачлык истә калды бик нык. Яз житсә, сугыша-сугыша, черек бәрәңге җыя идек, чабаталар бата иде, ялан аяк та күп йөрелде.



15яшьтә 7нче сыйныфны бетергәч, 1955нче елны Пүкәлдә тегү әртилендә эшли башладым.

1960нчы елда кияүгә чыгып, Казахстанга чыгып киттек. Чирәм җирләрдә булдык инде. Совхозда, интернатта няня булып эшләдем. 38ел торганнан соң, 1998елда Пүкәлгә кайттык. Тырышып эшләсәк тә, наградаларыбыз да булмады. 2 кыз үстердек ирем Шамил белән, ул авылга кайтып өй салгач, вафат булды, тигезлектә яшәп булмады.

Дөньялар бик рәхәт хәзер, тик сәламәтлек кенә юк.

*Язманы Лилия Әхмәтҗанова әзерләде.*



**Гарифуллина (Ахметова) Фәния Габдерахман кызы 1939нчы елда Свердловск өлкәсе Ревда шәһәрендә икенче кыз булып дөньяга килә.**

Алар гаиләдә ике бала, 1935нче елда дөньяга килгән Фатыйма апасы була. Әбиемнең әтисе бик укымышлы хәрби кеше була. Сугыш башлануга ул сугышка китә. Бабаем анда элемтәчеләр командиры булып хезмәт итә. Күп тапкырлар яраланып, яңадан сугышка керә. Сугыш бетәргә 1 ел калгач, 1944нче елда яраланып вафат була.

Әнисе Фатыйха - Фатыйма белән Фәнияне алып туган ягы Шмидтка кайтып төпләнәләр. Алар “әти” диеп әйтә алмыйча, әтиле балаларга кызыгып авыр тормыш итәләр. 14 яшендә кохозга эшкә керә.

1958нче елда Өтернәс авылы егете Гарифуллин Касимулла белән очрашып, 1961нче елда тормыш корып җибәрәләр. Алар 8 балага гомер бирәләр. Ләкин ике игезәк балаларының гомерләре бик кыска була.


Шушы авырлыкларны кичереп, алар 6 баланы тәрбияләп устерәләр. Әбием 12 ел ипи пешерүче булып эшли. Аннан соң күп еллар “ПМК-12” һәм ЖБИ да эшләп “Хезмәт ветераны” исеме алып, лаеклы ялга чыга.

Алар бабам белән икесе бик күп мактау грамоталары алалар. Шулар арсыннан әбием өчен иң кадерлесе - “Ана Даны медале”.

Бугенгесе көндә дә Саба районы Иләбәр авылында, 8нче Март урамының 42 нче йортында бабаем белән бергә тигез картлык кичерәләр.

*Февраль, 2017*

*Язманы Эзмә урта мәктәбе укучысы Айнур Гарифуллин әзерләде.*



**Гарифуллин Касыймулла Гарифулла улы 1941нче елның мартында Саба рйоны Өтернәс авылында 7 балалы гаиләдә 6нчы бала булып дөньяга килә.**

Әтисе Гайфуллин Гарифулла һәм әнисе Гайфуллина Хәтирә була. Иң олы абыйлары булып 1925нче елда Миннихан, 1927нче елда Минзифа,1935нче елда Марзыя, 1936нчы елда Разыя, 1938нче елда Асия, 1945нче елда Зиннур энесе туа.

Аларның бала чаклары бик авыр елларга туры килә: алар ачлыкны, хәерчелекне - бар авырлыкны күреп үсәләр. Шушы авырлыкларны артта калдырып, 15 яшенән колхозда хезмәт юлын башлый. 1963нче елда ПМК-12 гә тракторчы булып эшкә керә. Ул тырыш, намуслы хезмәте өчен күп кенә мактау грамоталарына ия була. Бабаем 42 ел хезмәт юлын үзенең тракторына багышлап лаеклы ялга чыга.

Бүгенге көндә Иләбәр авылында әбием белән балалар, оныклар куанычы күреп тигез матур гомер кичерәләр.

Февраль, 2017

*Язманы Эзмә урта мәктәбенең 8 сыйныф укучысы Гарифуллин Айнур әзерләде.*



## Галиуллин Миннәхмәт Гыйлмулла улы

## 1943нче елның

## 14нче июнендә Саба районы Олыяз авылында туа.

Сугыш беткәндә 2 яшьтә була. Гаиләдә олы бала. Сугыштан соң 5 бала туа. Әтиләре Гыйлмулла инвалид булып сугыштан кайта. 1977нче елда вафат була.

Галиуллин Миннәхмәт 1949нчы елда укырга керә. 1956нчы елда 7нче классны тәмамлап, почтальон булып эшли башлый. 2 ел эшләгәч, колхозда ат җигеп эшли башлый. Конюшни төзү өчен ат белән таш ташый, пар ат белән бәрәңге, фермага салам, силос ташый. 1967нче елда Янильдә тракторчылыкка укый. 1978нче елга кадәр колхозда механизатор булып эшли. Аннан соң колхозда профсоюз председателе булып эшли. Күңелдә калган иң матур истәлек - ат җигеп эшләгән еллар.

Аннан соң 5 ел Росгосстрахта агент булып эши һәм 2003нче елда лаеклы ялга чыга. Мактау грамоталары булган, ләкин сакланмаган.1976нче елда Галиуллина Хөмәйрә белән гаилә кора. 2 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә Олыяз авылында яши.











**Валиева (Әхмәтханова) Гөлҗофар Мөхәммәтхан кызы 1934нче елның 6нчы гыйнварында Саба районының Олыяз авылында туа.**

Әтисе Бәдертдин (1905), әнисе Гөлҗәүһәр(1910)-колхозчылар. Гаиләдә 4 бала була - Кәнәфи (1932), Фәлван(1930),Гөлҗофар(1934), Әмин(1938) елгы.

Гөлҗофар апа сөйләгәнәрдән:

-Әтиебезне сугыш башлануга ук, сугышка алып киттеләр, 1946нчы елда кайтты дип хәтерлим. Авырлыкларны бик күп күрдек, аны сөйләп кенә бетерә торган түгел инде.

4нче сыйныфны бетергәннән соң укырга мөмкинчелегем булмады, колхоз эшенә чыктым, төрле эшләрдә эшләдем, басудан кайтмадык инде. Ачлыкка бик тилмердек, “ипи нинди була икән ул?”- дия идек. 1953нче елда Пүкәлдәге тегү әртиленә эшкә кердем, тегү тектек.

1956нчы елда Пүкәл авылына килен булып килдем, вербовка белән Иркутск ягына киттек, товар поездында бардык бик озак. Кайда гына булсак та , тырышып эшләп көн күрдек. Аннан Казахстанга китеп 22 ел шунда тордык, заводта да, балалар бакчасында да эшләдем.



1992нче елда Пүкәлгә әйләнеп кайттык. Ирем Фәрит белән 2 малай үстердек, ул инде вафат булды.

Хәзерге тормышым Аллага шөкер, без күргәннәрне балаларыбызга күрергә язмасын.

*Язманы Лилия Әхмәтҗанова әзерләде.*



**Әхмәтҗанов Зөлфәкәр Ахунҗан улы 1942нче елның 1нче гыйнварында Саба районы Кызыл Мишә авылында дөньяга аваз салган.**

Ул гаиләдә бер бала була. Әтисе Әхмәтҗанов Ахунҗан 1941нче елны сугышка китә, ә бабаем әтисе сугышка киткәч туа. Әтисе сугыш кырларында ятып кала. Аның 1944нче елда үлү турында хәбәре килә. Бабаем авыр сугыш елларында үсә. Ул үзенең авылында хезмәт куя. 1962нче елда армия сафларына алына. 1965нче елда хезмәтен тутырып авылына әйләнеп кайта. Аннан шоферлыкка укый. Кызыл Мишә авылында колхозда хезмәт куя. 1977нче елда Иләбәр авылына күченеп, ПМК-12 дә механизатор булып эшли. Аңа күп кенә “Хезмәт алдынгысы” дигән грамоталар бирәләр һәм Саба районында күп еллар Мактау тактасында рәсеме торган. Бабаем 1992нче елда лаеклы ялга чыга. Ул 2015нче елның 22нче мартында вафат булды, Иләбәр авылы зиратында җирләнде.
Февраль, 2017

*Язманы Эзмә урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы Яруллин Ильназ әзерләде*



**Әхмәтҗәнова Фәридә Гәбделхәевна (Сиражиева), 1940 нчы елны Кукмара районы Ядегәр авылында, урта хәлле эшчеләр гаиләсендә дөньяга аваз салган**

Авыр чорларда яшәргә туры килсәдә 1948 нче елның сентябрьендә мәктәпкә белем алырга керү момкинлеге була, 7 класс белем алып мәктәпне әйбәт билгеләр белән тәмамлый. Илебезгә кайгы килүен ягьни сугыш башлануын әбием этисеннән ишеткән. Сугыш чорларындагы тормышлар кыен булуга карамастан әбием Ядегәр колхозын да тырышлык иткән, хезмәт куйган.Ул вакытлар да ризыкны кадерләп, тигез итеп кенә бүлеп бер-беребезгә житкереп кенә көн кургәннәр, киенү ягыннан да абыйлар энелэренә, апайлар сеңлеләренә калдырып киенгәннәр. Яшьләрнең аралашуы да кичләрен бик сирәк көннәр дә генә капка төбендә җыелганнар, белән торле уеннар уйнаганнар. Шулай иттереп көннәр авыр булса да берсе артыннан берсе үткән, һәм Май аенын бер матур коннәрендә илебезгә, авылыбызга шатлыклы сөенечле, зарыгып көткән жиңу хәбәре килә, Әбием бу хәбәрне урамда вакытта ишетеп ала. Инде бу дәһшәтле еллар утсәдә кешеләр әле сугыштан соң да бик озак авыр хәлдә яшиләр, барлык авыллар да әкеренләп тозелеш, янарту эшләре алып барыла. Әбием 1965 елны Саба районы Иләбәр авылына Әхмәтжанов Зөлфәкаргә кияугә чыга. Гомерләр әкеренгә утә һәм бер-бер артлы 1 малай һәм 2 кызлары туа. Кияугә чыккачта әбием авыр хезмәттә эретеп-ябыштыру һөнәре буенча эшләгән. Хәзергесе вакытта әбием Иләбәр авылында кызы-кияуе хэм оныклары белән шатлыклы, рәхәт тормыш белән гомер кичерә. Әбиемнен хезмәт олкәсендә зур тырышлык куйган очен куп кенә Грамоталары хэм Медальләре бар. Менә шушындый ачы тормыш юлларын үткәнен әбием мина сойләп бирде һәм мин бик гажәпләндем ул елларнын шулай кешелек өчен бер зур сынау булуына, мин әбиемне биктә яратам һәм горурланып яшим!

*Язманы Эзмә урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы Яруллин Ильназ әзерләде*



**Габдулхакова Һәнүзә Әхмәтхан кызы 1935нче елның 3нче ноябрендә гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә.**

Әтисе Мөхәммәди ,әнисе Шәмсенур колхозчылар була.

Матур гына яшәп ятканда, этиләре каты авырудан үлеп китә. Ул вакытта аңа нибары 3 яшь була. Ул этисен хәтерләми. Әнисе Шәмсенур ике кыз бала белән тол кала.

Әниебезгә 5 яшь ярым вакытта сугыш башлана.Сугыш башланган дигән сүзне, этисенең энесен военкоматка чакыртып алгач ишетәләр.”Әхмәтҗан абыйны военкоматка чакыртып алдылар.Өйгә дә кереп чыга алмады.Бераз ашарга хәстәрләп таш юлга чыгып озатып калдык. Бер машина солдатлар төялгән иде. Кулларын болгап Шәмәрдән ягына китеп бардылар. Шуннан кайтмадылар. Әнинең абыйсы Шәрәфетдин сугышта булып ,кул-аякларын имгәтеп кайтты”-дип сөйли әниебез.

Энесе Бәдегыдтин Кузбасс шахтасында эшкә киткән була.Авылга кайтам дип җыенып йөргәндә сугышка алып китәләр. Хәстәрләп куйган сумакалары да шунда калган. Сугышта үлеп калды. Габдерәүф исемле энесе бик яшьли сугышка китеп, кире кайтмады.

Әнине окоп казырга алып чыгып киттеләр. Әби, апай белән икебезне кочаклап елап калды. Башка хатыннар ирле булсалар да китмәде.”Минем аркада әниегез тилмереп йөри”- дип гел елый торган иде.

Нинди авыр булса да, сыер, ике сарык, тавыклар асрадык. Кул белән йолкып печән хәзерләдек. Уфалла арбасы белән ташый торган идек. Мичкә ягарга имәнлектән ботак ташыдык. Имәнлек дигәнем 3-4 км ераклыктагы урман инде ул. Хөкүмәткә мәҗбүри ясак түлисе иде. Елга кырык кг ит, ике йөз л сөт, йөз йомырка.Үзеңә каламы-юкмы, алып чыгып китәләр иде.

Әниләр көрәк белән бәрәңге казыйлар иде.Без алар артыннан шул бәрәңгене чүпли идек. Кул белән борчак йолыктык. Калган борчакны берәмтекләп кружкага

җыя идек.Аның өчен бер телем ипигә бал ягып бирерләр иде. Ул ипи, бал тәме бүген дә авызда әле.

Сугыш беткәнне без мәктәптә ишеттек. Линейкага чыгарып тезделәр."Сугыш бетте!Сугыш бетте!"-дип, быргылар кычкыртып,барабаннар сугып, сугыш бетүен тантана иттек дип, сөйли ул.

Балачак еллары авыр сугыш чорына туры килсә дә, әни мәктәптә белем ала. Эзмә башлангыч мәктәбендә 4 класс белем алгач, Шекше авылына йөреп 7 классын бетерә. Бик яхшы укучы була. 7 класс белем алганнан соң, Кукмарага китеп итек фабрикасына эшкә ураншa. Фабриканың иң авыр цехында эшли.

"Басу цехында эшләдек. Кислота белән куллар ашалып,ярылып бетә , кеше белән күрешергә дә ояла торган идек, "- дип искә ала ул.

"Товар поезды артына асылынып йөрдек. Билет бирмиләр иде. Чират җиткәч кенә, билет бетте дип, кассир тәрәзәне ябып куя иде. Эшкә мәҗбүри барырга кирәк. Бервакыт әни станциягә озатата менде. Безнең шулай йөргәнне белгәч,"Бүтән кайтма!"- дип кычкырып елап калды"- ди.

9 ел эшли ул анда. Әнисенә ярдәм итеп тора.Үзенең өс-башларын карый.

1958 елны Өтернәс авылына килен булып төшә. Расчет алып колхозга кайта. Әтиебез Фәрит белән 5 бала үстерәләр. Ике малай, өч кыз. Малайлар икесе дә армия сафларында хезмәт итте. Һәрберебез тормышта үз урыныбызны табып, гаилә корып, балалар үстердек. Яшьтән эштә булдык. Әти-әни йөзенә кызыллык китермәдек.

Әти белән әни гомер буе колхозда эшләделәр. Әти комбайнда, ә әни төрле эштә хезмәт куйды.

Кызганычка каршы, инде әтиебез күптәннән вафат булды. Ә әниебез, безне сөендереп, Аллаһы Тәгалә биргән һәр көнгә рәхмәт укып, без - балаларына изге теләк теләп гомер кичерә.

*Язманы кызы Нурфия Шиһапова әзерләде.*



Аскаров Рафис Галиәхмәт улы 1939нчы елның 1нче январенда Чүриле районы(хәзерге Саба районы) Эзмә авылында колхозчы семьясында туган.

Әтием Галиәхмәт Галиәскәр улы 1907нче елгы, әнием Гафифәбану 1906 нчы елгы, абыем Галиев Рафик 1936нчы елгы. Хәзерге вакытта алар өчесе дә мәрхүмнәр.Урыннары оҗмахта булсын.

Әтием 1941нче елда сугыш башлангач та, сугышка алына. Әтидән киткәннән соң бер генә хат та килми. Сугыш беткәч ирләр кайта башлады, шул вакытларда безгә бик читен булды. Әни әтине бик көтте – әтиегез барыбер кайта дип, безне сөендерә иде. 1949нчы елда әтидән хат килеп төште. 1950нче елның 1нче апреле көнне әтиебез кайтты. Мин әтине танымадым, ә Рафыйк абый әтине күргәч бик каты елады, чөнки ул аны таный. Әти кайту белән колхозда ферма мөдире, ат караучы булып эшли. Шул елны икмәк бик нык уңа.Ул лабогрейка белән ашлык ура. Шул елны аңа бодай ашлыгы бирәләр. Һәм мин беренче тапкыр 1950нче елда бодай күмәче ашадым. Безнең нәселдән 3 туган сугышка китәләр. Шулардан Аскаров Хәкимулла һәм Гиниятулла туган йортларына әйләнеп кайталар. Ә менә Аскаров Шәймулла сугыш кырында ятып кала.

1946 нчы елда Эзмә җидееллык мәктәбенә укырга кердем һәм 1953 нче елда тәмамладым.1956нчы елда Эзмәдә кичке мәктәпне бетердем. Шушы елларда колхозда төрле эшләрдә эшләдем, ат көтүе көттем.

1958нче елда Саба РТСында тракторчылар курсында укыдым. Бер ел тракторчы ярдәмчесе булып эшләдем. 1960нчы елда Чистай техник училещесында электриклар курсында укыдым. 1965-1982нче елллардаСаба МСОда шофер булып

эшләдем. Эш барышында шактый гына яхшы күрсәткечләргә ирешеп мактау кәгазьләре алдым.

1. 5еллык ударнигы;
2. 1970 елда Хезмәт ветераны;
3. 3 коммунистик хезмәт ударнигы;
4. Мактау тактасында фотом торды.

1980 нче елдан башлап 2000нче елга кадәр Эзмә урта мәктәбендә завхоз булып эшләп лаеклы ялга чыктым.

1967нче елда тормыш кордым. 3 кыз тәрбияләп үстердек. Бүгенге көндә өчесе дә югары белем алып Казанда яшиләр. Ә мин тормыш иптәшем Сания белән Эзмә авылында балаларның игелеген күреп, матур гына яшибез.





**Җиһаншина (Шәяхмәтова) Гөлфәрия Галиәхмәт кызы 1933нче елның 22нче ноябрендә Эзмә авылында гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.**

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа сигез, энеләре Муса белән Миннәхмәткә биш һәм өч яшь булган. Галиәхмәт бабайны сугышның беренче көннәреннән үк фронтка алалар. Ул еллар турында әни сөйләгәннән истә калган хатирәләр:

“Балалык акылыбыз белән “сугыш” дигән сүзнең мәгънәсен аңлап җиткермәдек. Чөнки безнең әти белән бергә авылдагы барлык ирләр диярлек сугышка алынды. Фронтка китми калганнар турында: “Ул картайган, сугышка барудан яше чыккан” яки “Гарип булганга калды” дигән сүзләр әйтелде. Авылның яшәеше хатын-кызларга һәм безнең кебек буыннары ныгып җитәргә дә өлгермәгән балаларга калды. Фронт кырыннан “өчпочмаклап” төрелгән хатлар килә башлады. Әнинең (Мәулиха әбиемнең) күз яшен сөрткәнен күрсәм, нигә елаганын сорый идем. Ул: “Әтиең сугыштан кайтмаса, ничек яшәрбез, кызым? Сезне ничек үстерермен?” – дия иде. Әнинең йөрәге сизенгән булган күрәсең, 1942 елда әтидән “Батырларча һәлак булды!” дигән кара язулы хат килде. Ул көннәрдә безнең тормыш шул урында туктап калгандай тоелды. Әнинең өчебезне берьюлы кочагына алып: “Сезне ачтан үтермәс өчен булышыгыз миңа!”- дигән сүзе, безгә үзебезнең бала икәнебезне онытырга мәҗбүр итте. Көз көне һәм иртә язда колхоз басуына барып, энеләрем белән өшегән бәрәңге җыеп кайтабыз. Безне мактый-мактый, әни шуннан бәрәңге кәлҗәмәсе пешерә. Өшегән бәрәңгегә бераз он салып болгата да, шуны көлчә кебек ясап мич төбенә сала. Безне ачлыктан алабута күмәче белән кычыткан ашы да коткарды. Эзмәнең югары очтагы авыл башындагы тиреслектән җыя идек. Ашый торган нинди үлән бар, барысын да җыйдык”.

Мәулиха әбигә өч баласын ялгыз үстерү җиңел булмаган. Ул тормыш кырыслыгын җиңәр өчен балаларына таянган. Әнием уналты яшендә авылдашы Әлфия Әхәтова белән Арча районы Үрнәк поселогында урнашкан механизаторлар әзерли торган алты айлык курска укырга керәләр. Сугыштан соңгы елларда иң дәрәҗәле хезмәт була ул тракторда эшләү. Әни, гаиләләрен икмәк белән тәэмин итү өчен шушы һөнәрне сайлый. Кулына механизатор таныклыгы алгач, “МТС”ка эшкә урнаша.

Язгы кыр эшләре башлангач, безнең булачак әтиебез, Өтернәс авылы егете Наил Җиһаншинга тракторчы ярдәмчесе итеп әнине билгелиләр. Яңа гына армия сафында хезмәт итеп кайткан егет белән “плугар” кыз арасында яшерен мәхәббәт күпере сузыла. Наил йөрәк хисен Гөлфәриягә башта өздереп кенә әйтә дә алмый. “Әниегез артык чибәр иде. Күк йөзе кебек зәңгәр күзен сөрмәле керфекләре арасыннан бер сирпеп карап алса, йөрәгем дулкынланудан табаныма кадәр төшеп китте”, - дип, әнигә гашыйк булган чакларын матур итеп сөйли иде. Әниебез этинең сүзеннән соң көлеп куя да, үзенең әти белән кичке очрашуга чыгарга ничек әзерләнгәнен сөйли. Бердәнбер күлмәген мунчада юа һәм шул кипкәннән соң гына чыга.Чөнки алмашка кия торганы юк. Кайвакыт сул ягын гына әйләндереп киеп чыккан көннәре дә булганын сөйләп безне көләргә мәҗбүр итә иде. “Тракторда эшләп, бер күлмәк алып киярлек тә акча түләмиләр идеме?” – дип сорый идек. Дөрестән дә, хезмәт хакы түләнмәгән ул елларда, ашлык өчен генә эшләнелгән. Сугыштан соңгы авыр еллар безнең әти-әниләрнең яшьлек чорына туры килгәнлеген күрсәтә торган ачык дәлил бу. Алай гына да түгел, мәктәпкә киеп барырга өстенә кияргә киеме булмаганлыктан, әни дүртенче сыйныфны тәмамлагач, укуын дәвам итә алмый. Белеме дүрт еллык кына булса да, әнинең язуы матур, хәрефләре төзек иде. Свердловск шәһәрендә яшәүче энесе Миннәхмәт абыйга өчәр дәфтәр бите хат язып утырганы күз алдымда саклана. Ул китап укырга яратты, Һади Такташ, Муса Җәлилнең бик күп шигырьләрен яттан сөйли иде. Видеотасмага да яздырып калдык.

Тракторчы егет белән кыз 1956нчы елның октябрь аенда өйләнешәләр. Әниебез Өтернәс авылына Җиһаншиннар гаиләсенә килен булып төшә. Туганнары арасында әти өлкән бала булган. Аннан соң өйдә ике сеңлесе, дүрт энесе була. Әти тракторда эшләгәнлектән,ишле гаилә икмәккә тук яшиләр.

1957 елның ноябрь аенда мин, 1959 елда энем Салават туган. “Унбер кеше дүрт почмаклы йортта бергә яшәп булмас”, - ди әти. Мәфрүзә әби белән киңәшеп, Эзмә авылыннан иске йорт сатып алып, күрше авылга күченәләр. Шул йортта яшәп, үзләре алты почмаклы яңа йорт җиткереп чыгалар.Гаиләдә бер-бер артлы Рамил, Рафил, Рәсимә туа. Биш балалы гаиләне тәэмин итү өчен әти белән әнинең нинди олы тырышлык белән яшәүләрен без күреп үстек. Әни пенсиягә чыкканчы, Киров исемендәге колхозда сугарылып үстерелә торган культуралы көтүлектә эшләде. Шул елларда көтүлек җитәкчесе булып эшләгән Нурый абый Низамиев терлек азыгы культураларыннан иң югары уңышка ирешеп, Мәскәүдә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашты.

Әни эшкә киткәнче, олы мичкә ягып, дүрт түгәрәк ипи пешерә иде. Шактый мәшәкатьле эш иде ул. Утын янып беткәч, күмерен кече мичкә төшерә дә, мич

төбендәге көлне мунчала себерке белән чистартып, ипине агач көрәк белән мичкә салганын бүгенгедәй хәтерлим. Замана белән бергә көнкүреш тә үсә барды. Әйтик, без җиденче сыйныфларда укыганда әни ипине табага салып пешерә башлады. Өстәлдә шикәрнең санаулы вакытлары булса да, әни камыр ризыклары пешерергә гаҗәеп оста иде. Әтиебез игенче-механизатор булганлыктан да, без ач та, ялангач та булмадык. Әнинең кулы күрше-күләнгә дә, туган-тумачага да юмарт булды. Аның күңел яктысы, йөрәк җылысы әйләнә-тирәсендәге һәркемгә дә җитте.



Әти белән әни кырык җиде ел парлы гомер кичерделәр. 2003нче елның 20нче июнендә әти мәңгелек йортка күчте. Әтинең үлемен әни авыр кичерде. Ана йөрәге аша газиз баласын югалту олы хәсрәте дә узды. Утыз сигез яшендә вафат булган энебез Рамилне дә сагынып гомер итте. Әни сагышын эчкә йотып яшәде. 2010 елның 26 сентябрь киче безнең гаиләгә авыр кайгы алып килде. Динле-иманлы кадерле әниебез Казаннан Коръән ашыннан кайтышлый, юл һәлакәтенә очрап вафат булды. Авыр туфрагы җиңел булсын. Әти белән әнинең төп нигезендә хәзер энем Рафил гаиләсе гомер итә.



*Язманы кызы Гөлсинә Галимуллина әзерләде.*



**Мифтахова Нажия Мөҗип кызы 1934 нче елның 3 нче апрелендәСаба районы Иләбәр авылында 4 нче бала булып дөньяга килә.**

Ул үзенең балалык еллары турында сагынып искә ала. “Әти-әнием колхозда эшләделәр, сугыш башланганда этием Алабугада юл төзелешендә иде. Сугыш башлануга, төнлә юл төзелешеннән кайтты, ә иртә белән без йокыдан торганчы, сугышка киткән. Шулай итеп, әни белән биш бала торып калдык. Беребездән-беребез кечкенә кызлар, әнигә сыенып елый идек. 1942 нче елны абыйны сугышка озату өчен хәрби өйрәнүләргә алалар, шул вакытта абыйга бик каты салкын тия һәм абый үлеп китә. Абыйның үлгәнен әни этигә язмады.Әтиегезгә болай да бик авыр,ди иде. 1943 нче елда этинең дә үлгән хәбәре килде. Сугыш беткәндә, мин Иләбәр мәктәбенең дүртенче классында укый идем. Сугыш бетте, дип сөенеч алуга, әни безне кочаклап:” Кешенең этиләре кайта, сезнеке кайтмый бит!”- дип бик озак елады. Башлангычта укыганда колхоз басуына чиләк белән калган башакны җыярга чыга идек. Амбарга тапшыргач, 1 кг башакка 100 гр ипи бирәләр .Әнигә иптәшләре: “ Бу ипигә рәхәтләнеп чәй эчәсез инде,”-дип әйтәләр иде. Шулай итеп, әнигә кул арасына керә башладык. Безне әни укытырга тырышты.

5 нче класска Шекше мәктәбенә укырга бардым. 7 нче классны тәмамлагач, июнь башында әниебез дә үлеп китте. 4 кыз этисез дә, әнисез дә, абыйсыз да дөм ятим калдык. Олы апабыз Сәвиягә 17, ә кечебезгә 7 яшь иде. Безне балалар йортына җибәрергә теләделәр. Без дүрт кыз туган,бер-беребездән аерылышмыйбыз дип еладык. Сәвия апаебыз безгә әни булып калды.

1949-1950 нче елларда Сәвия апа белән тракторларга чиләк-көянтәләп су ташыдык. 17 яшь тулгач, Ключка урман кисәргә җибәрделәр. Өскә кияргә кием, ашарга ризык юк иде. Лаешка елга чистартырга бардым. Балта белән агачларны чабып өябез, тамаклар ач, кияргә кием юк, барысыннан да бигрәк өйгә кайтасы килү теләге көчле иде. Шул чор балалары күргән бөтен авырлыкны күрдем, ятимлек ачысын татыдым. Аннан соң Иләбәр фермасында сыер саудым. 1957 нче елны Өтернәс авылына Мифтаховлар гаиләсенә килен булып төштем. Кохозда төрле эшләрдә эшләдем. Ферма ашханәсендә озак еллар терлекчеләргә ашарга пешердем. Лаеклы ялга чыкканчы гомеремнең бөтен көнен намуслы хезмәт белән

үткәрдем. Өч балама: ике улыма  һәм бер кызыма якты гомер бүләк итеп, аларга югары белем алырга булыштым. Бүгенгесе көндә Өтернәс авылында балаларым, оныкларым тәрбиясендә,оныкчыклар сөеп тормыш иптәшем Әнәс белән 59 ел тигез, матур гомер итәбез, һәр туачак яңа көнгә шөкер итеп яшибез. Сугыш чорының авырлыкларын башка беркемгә дә күрергә язмасын иде.



*Язманы килене Вәсилә Мифтахова әзерләде.*





**Мавлютова (Гарифуллина) Рафия Тимербай кызы 1935нче елның 17нче июле көнне Саба районы Эзмә авылында туган.**

Гомеренең иң матур булырга тиешле балачагы, яшьлек вакыты бик авыр елларга туры килгән. Сугыш елларында гаиләдә 4 бала: 2 малай, 2 кыз булганнар. Әтиләре сугышка китә һәм кире әйләнеп кайтмый, вафат була. Әбием күп кенә җирләрдә эшли һәм туган авылына әйләнеп кайта. Авылыбызның мәдәният йортында эшли. Бабаем Шәйхулла белән тормыш корып, дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр, матур гомер кичергәннәр . Инде бабаем вафат булды. Әбием Эзмә авылында кече улы Дилүс гаиләсе белән балаларының игелеген күреп, оныкларының куанычын тоеп яши.

*Язманы Эзмә урта мәктәбенең 4нче сыйныф укучысы Дилә Мавлютова әзерләде.*



**Хафизова (Минһаҗева)Мөслимә Зәйнак кызы 1941нче елның 15нче январенда Саба районы Пүкәл авылында туган.**

Сугыш ул – бик куркыныч нәрсә,
Кан ул, ут ул, үлем яралар.
Күз яшьләре, кайгы, ачлык,
Тол аналар, ятим балалар.

Туган илебезгә Җиңү якынлаша. 1941-1945нче елларда туган җиребезнең якты киләчәге өчен барган канкойгыч Бөек Ватан сугышында бик күпләрнең гомерләре өзелә, күз яшьләре түгелә. Җиңү язын якынайту өчен һәркем үз көченнән килгәнчә өлеш кертә. Бу көрәштә олылар белән беррәттән балалар да катнаша. Сугыш аларның сабый башларына ачлык, ялангачлык, ятимлек югалган балачак булып ишелеп төшә. Бүген инде сугыш чоры балалары чәчләренә чал төшкән әби-бабайлар. Ләкин узган сугыш вакыйгалары алар хәтерендә бүген дә төзәлмәслек яра булып саклана. Үзенең сугыш чоры балачагы хатирәләре белән сугыш чоры баласы-әнием Хафизова (Минһаҗева) Мөслимә Зәйнак кызы уртаклашты. Ул 1941нче елның 15нче январендә Саба районы Пүкәл авылында дөньяга килә. Үзеннән ике яшькә генә зуррак апасы да була. Менә шулай матур гына тормыш итеп яткан чакта илнең күген кара болыт каплый. Сугыш... Сугыш башланган беренче көннәреннән үк әтине сугышка алганнар дип искә ала әниебез. Чөнки ул үзе дә бишек баласы булганлыктан, әнисе сөйләгәннәрдән генә белә. Апаны кулга күтәреп, мине бишектә калдырып, әни әтиемне сугышка озаткан.

Кем уйлаган бу аларның соңгы күрешүләре булыр дип. Менә шулай әни ике бала белән ялгыз калган ул. Әле ярый бик карт булса да, әтинең әнисе - әбием исән була. Шушы көннән башлап инде әни көне – төне колхозда эшләде, урман кискәннәр, хәтта окоп казырга да барганнар әле. Әтиләребез сугышка китеп беткәч бар авырлык алар җилкәсенә төшкән бит. Ә безнең инде үзебезне белә башлаганнан алып, ачлык-ялангачлык белән бала чакның хатирәләре күңел түрендә иң тирән җәрәхәтләр белән истә калган. Ничек кенә авыр булса да, әни безгә үзенең күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышты. Нинди генә авыр минутларда да ул сынмады, сыгылмады. Әниебезнең тырышлыгы белән ачлыктан исән - сау калдык. Чөнки әни сугышның иң авыр чорында да сыер асрады. “Балалар, сыердан калмыйк, сыер исән - сау булса, үлмәбез”- дия торган иде. Шуңа күрәдер инде, безнең балачак булмады да диярлек. Язын җир кардан әрчелүгә черек бәрәңге эзләп басудан кайтып кермәдек. Әле сугыш беткәндә дә бик кечкенә сабый гына булганбыз бит.

Сугыш бетте. Тик сугыштан соңгы еллар да җиңелләрдән булмады. Бигрәк тә безнең шикелле әтиләре сугышта үлеп калган балалар өчен икеләтә авыр булды ул. Бик озак көттем әле мин әтинең сугыштан кайтканын. Ләкин әтием кайтмады шул. “Әти” дип әйтергә тилмереп, башкаларга кызыгып үсәргә туры килде. Чөнки иптәш кызларымның әтиләре яраланып булса да сугыштан кайттылар, алар әтиле булып, тамаклары безнең шикелле үк ач булмады. Укырга да мин иптәшләремнән бер елга калышып кердем. Авылда балалар бакчасы бар иде. Укырга килгәч укытучы апа: “Балакаем, бер ел булса да тамагың тук булыр, киләсе елга килерсең”,- дип мине кайтарып җибәргәнне хәтерлим. Кияргә кием юк, әти кайтып мина да бишмәт алып бирсен иде дип кызыгуларым. Шуларны искә төшерсәм, әле дә күзләрдән ирексездән яшь килә. Әтиебез сугышның башлангыч чорларында ук Ленинград өлкәсендә үлгән. Ләкин әтинең үлеме турындагы хәбәрне әни безгә соң гына җиткеде. Без балаларның күңелен китәсе килмәгәндер инде. Әниебез безнең рухыбызны сындырмый, үзенең көченнән килгәнне һәм килмәгәнне дә эшләде. Чөнки ул үзе дә гомер буе бик тапкыр, тырыш булды.

Әтиебезнең рухын керләмичә һәрвакыт бары якты истәлекләр белән генә искә алды. Шулай авырлыкларны җиңеп, бала чактан яшүсмер чорга аяк бастык. Әле бит тормышлар тиз генә җиңеләймәде. Шуңадыр, без үзебез дә яшьтән эштән курыкмыйча чыныгып үстек. Җиденче сыйныфны тәмамлауга фермага эшкә төштем. Вакыт авырлыкларга карамыйча алга бара икән шул ул. Шулай итеп яшьлек чорына да кереп киткәнбез. Ә яшьлек үзенекен итә инде ул. Үз вакыты җиткәч Олыязның иң уңган, чибәр егете Хафизов Рәшит белән тормыш кордык. Заманына туры китереп, матур итеп атлар бизәп туйлар уздырып әтиле кешегә тормышка чыктым. Бала чактан кызыгып үскән “әти” сүзен әйтү насыйп булды. Менә шул көннән алып лаеклы ялга чыкканчы мин фермада терлекләр карадам. Эшемне яратып, чын күнелдән башкаргач күп тапкырлар мактау грамоталары, күп бүләкләр белән бүләкләделәр. Һәр елны диярлек хезмәтемне хөрмәтләп алдынгылар слетыннан калдырмадылар. Тигезлегебез белән дүрт бала тәрбияләп үстердек, аллага шөкер. Бар да гаиләле, матур тормыш кичерәләр. Сигез оныгыбыз, дүрт оныкчыгыбыз бар инде хәзер. Рәшитем дип тормыш иттем, ул да бик уңган-булган, кулыннан килмәгән эше юк, бик тә тырыш булды. “Алтын куллы”, диләр андый кешеләр турында. Менә ул да алтын куллы булды. Аның кулы тимәгән йорт сирәк булгандыр. Әле хәзер дә көченнән килгәнчә кул эшләрен эшләүне дәвам итә. Балачак авыр булса да, бүгенге көнебездән бик канәгать без. Төпчек улым Алмаз, киленебез Фирүзә, оныкларыбыз белән бик матур яшибез. Киләчәк буынга бары тыныч тормыш теләр идем. Балалар беркайчан да сугыш афәтен күрмәсеннәр иде.



*Апрель, 2017 нче ел.*

*Әниемнең истәлекләрен язып алучы кызы Резида Сөнгатова.*



**Хафизов Рәшит Мансур улы 1941нче елның 9нчы март көнне Саба районы Олыяз авылында туган.**

Мин Саба районы, Олыяз авылында туганмын. Сугыш башланганда миңа әле нибары өч ай булган. Шуңа да мин сугыш башланган вакытны бары үземнән өлкәннәрдән генә ишетеп беләм. Ә гаиләдә миннән өлкән тагын өч туганым - апам һәм ике абыем булган. Алар өлкәнрәк булгач, сугышның беренче көннәреннән үк, бала гына булуга карамастан бар эшкә җигелеп, олылар белән бер рәткә эшләргә туры килгән. Әти сугышка 1942нче елның 4нче апрелендә алынган. Шулай итеп дүрт бала белән әнием йорт башы булып кала. Әтинең бер күзе сукыр булганлыктан, ул турыдан –туры сугышка кермәгән, ләкин сугыш беткәч тә хезмәт куеп, бары 1947нче елда гына кайтып төшә алган. Ләкин сугыш кагылмаган, аның ачлыгын һәм ялангачлыгын тоймаган бер генә кеше һәм бала калмагандыр. Минем дә үземне белгәннән алып, аның ачлыгы, тормышның авырлыгы бик тирән эзләр салып, күңел түрендә калган. Инде күп кенә балаларның әтиләре сугыш кырында ятып калганда миңа, аллага шөкер, әтиле булып үсү насыйп булды. Шулай да балачакның иң үзәккә үткән ачлыгы, тормышның авырлыгы, әлбәттә, безне дә урап узмады. Язның эреп беткән карларын да көтеп тормыйча яланаяк салкын балчыкта йөреп, аякларның чебиләп, аннан соң аның ярылып үзәккә үтеп эрнүләре хәзер дә искә төшә. Сугыштан соң тагын ике сеңлем туды. Ләкин аның берсенә 2, икенчесенә 4, миңа 12 яшь булганда, әниебез безне мәңгелеккә калдырып үлеп китте. Тормыш нинди генә авыр булса да, әни янында булганда сулыш җылысы, аның карашы белән булса да без әле бәхетле булганбыз икән. Сугыш беткәнгә карап тормыш бит алай гына җайга салынмады, авырлыклар да әле бик озак безне озата барды. Инде гаиләдә әни булмагач, сеңелләрем тулаем минем өстә калды. Әнине сагынып елаган чаклар хәзер дә истән чыкмый. Әти көне буе эштә, аларны карау гына түгел, ашатырга да кирәк иде. Ә апа - абыйлар ул вакытта инде ФЗУга һәм армия сафларына алындылар. Йортыбызга үги әни килгәч бераз күңелгә җылылык өргәндәй булды. Вакыт җитеп беренче класска кереп, инде 1955нче елда җиде классны тәмамладым, эшли башладым. Бераз тамакка ипи дә керә башлады. Башта ат җигеп, аннары плугарь булып 2 ел

эшләдем. Механизатор булу теләге белән Усадка укырга киттем. Анда механизатор белгечлеге алып уңышлы гына аны тәмамладым. Ул елларда механизаторларны чирәм җирләрне эшкәртү өчен Казахстан җирләренә җибәрү бар иде. Без дә дустым Хәйдәр белән Казахстан җирләренә барып, шушы чирәм җирләрне эшкәртүдә ике ел хезмәтебезне куйдык. Анда да бик тырышып эшләдек, алдынгылыкны бирмәдек. Инде җитлеккән егетләр булып авылга кайтып төштек. Әйе, механизаторлар ул чорда бик кирәкле профессия булды. Менә шулай башланган хезмәт юлын мин инде лаеклы ялга чыкканчы ташламадым. Аннан кайткач бик тә чибәр, сабыр, уңан Пүкәл кызы Мөслимә белән тормыш юлыбызны бәйләдек. Эш дәверендә югары үрләргә дә менү насыйп булды. 1974нче елда “Кыр батыры” дигән исемгә лаек булдым. Ул вакытта иң зур саналган “Урал” мотоциклы белән бүләкләнгән идем. Калган елларда да авыл хуҗалыгы слетларында призлы урыннар һәм күп кенә грамоталар белән бүләкләндем. Бугенге көндә тормыш иптәшем Мөслимә белән тигезлектә бик матур, бәрәкәтле тормыш кичерәбез. Бер кыз һәм өч малай үстердек. Алар бар да итагәтьле һәм тәртипле балалар булдылар. Хәзер һәрберсенең үз тормышлары, сигез оныгыбыз, дүрт оныкчыгыбыз бар. Шуларга сөенеп, бүгенге көнгә канәгать без. Ә инде киләчәк буынга бу сугыш авырлыклары кабатланмый, бары тик бәхетле киләчәк кенә теләр идем.





*Апрель, 2017 нче ел.*

*Әтиемнең истәлекләрен язып алучы кызлары Резида Сөнгатова.*



**Гимадиева (Гайнетдинова) Әнисә Гыйльман кызы 1944нче елның 1нче апреле көнне Саба районы Оет авылында туа.**

Сугыш елларын мин хәтерләмим, чөнки сугыш беткәндә миңа бары 1 яшь кенә булган. Әти – әниләр сөйләве буенча, сугыштан соңгы еллар бик авыр булган. Миңа 4-5 яшь вакытларны хәтерләвемчә, олырак туганнарым белән бергә алабута, кычыткан, кузгалак ише үләннәр җыеп кайта идек тә, әни шуннан аш пешереп ашата иде.

Без гаиләдә 11 бала туганбыз, икесе вафат булган, 9 бала үстек. Әтиебезне сугышка алмаганнар. Ул – Гайнетдинов Гыйльман Гайнетдинович, 1902нче елның 9нчы январендә туган. Аңа “бронь” биргәннәр. Әтиемдә оештыру сәләте бик көчле булган. Сугыш вакытында тылда да бик авыр булган һәм ул репрессиягә эләккән. Район прокуроры аны партиягә каршы сүз әйткән дип, бик нык тикшергән һәм үлем карары чыгарган, соңыннан әлеге карар 25 ел төрмәгә утырту белән алыштырылган. Районның югары органнары бу карар белән килешмәгән һәм эшне югары судка җибәргәннәр. Ә югары суд әтине аклаган. Ул конюх булып эшләгән. Аның эшен яхшы дип бәяләп, Мәскәүгә Коммунистлар партиясе съездына җибәргәннәр.

Сугыштан соңгы елларда әтием колхоз председателе булып эшләгән. Ул эшләгән колхозда тулы тәртип оештырылгач, аны икенчесенә билгеләгәннәр. Шулай итеп ул 33 ел шушы вазыйфаны башкарган.

Сугыш вакытында Мәскәүдән кешеләр эвакуациялиләр. Безнең Олыяздагы өйгә дә бер гаилә урнаштыралар. Мичкә ягарга утын булмаганлыктан, безнең каралты-кураларны сүтеп якканнар, өй генә утырып калган. Әтием пенсиягә чыккач, без шул йортка әйләнеп кайтып, янадан төзелеш эшләре алып бардык.

Мин үзем гомер буе Саба район росгосстрах эшләп лаеклы ялга чыктым. Хезмәтемне бәяләп Мактау грамоталары бирделәр. Бүгенге көндә Олыяз авылында балаларымның ярдәмен, күңел җылысын тоеп гомер итәм.



**Гимадиев Марданша Батыршович 1941нче елның 3нче августында Саба районы Олыяз авылында туган.**

Марданша абыйга өч ай вакытта әтисе сугышка китә һәм шул китүдән ул кире әйләнеп кайтмый. Аңа бер тапкыр да “әти” сүзен әйтергә насыйп булмый. Алар гаиләдә 4 бала үсәләр. Кул арасына керә башлагач, сугыштан соңгы елларда барлык авыр хезмәтләрне дә башкарырга туры килә. Оет кызы Әнисә белән тормыш корып, өч бала тәрбияләп үстерәләр. Гомер буе колхозда эшләп лаеклы ялга чыга.

2012нче елның 20нче нояберендә вафат була. Олыяз авылы зиратына җирләнә.



**Низамиева Гөлчирә Шиһабетдин кызы 1937нче елның 3нче апрелендә Эзмә авылында гаиләдә җиденче бала булып туа.**

Әтисе сугышка киткәндә аңа бары 4 яшь була. Балачагы бик авыр елларга туры килә. Басудан яланаяк черек бәрәңге җыеп, кычыткан, алабутадан пешергән күмәч ашап үсә ул. 1943нче елда әтиләре чукракланып сугыштан кайта.

7 класс белем алгач, Кукмара итек фабрикасына барып эшкә урнаша. 15 яшьлек кызга итек фабрикасында эшләргә, әлбәттә, җиңел булмый. Анда 6 ел хезмәт куя.

1958нче елда тормышка чыгып, Үзбәкстан якларына китеп бара. Анда өч ел яшәгәннән соң, тормыш җилләре аны яңадан туган нигезенә - Эзмә авылына кайтара.

Ул Киров исемендәге колхозда эшкә урнаша. Төрле авыр эшләрдә хезмәт куя. Җәй көннәре яшелчә басуында чүгендер, бәрәңге эшкәртү, болында печәнлеккә су сиптерү булса, кыш көне эскерт тирәләрен көри, ферма яннарын җыештыруда, бәрәңге подвалында эшли. Барлык эшләр дә кул көче белән башкарылган. Яз көннәре иртәнге 3 тә торып басуга ашлама сибәргә чыкканнар. Кар өстендә аякларын туңдыра – туңдыра ашлама сипкәннәр. “Ул вакытлардагы без күргән авырлыкларны яшь буынга күрергә язмасын”,- ди Гөлчирә Шиһабетдин кызы.

Хәзерге вакытта Гөлчирә апа кызы Нурия, кияве Салават, оныклары Динар һәм Рөстәм гаиләләренә сөенеп, үзенең төпле киңәшләрен биреп Эзмә авылында бәхетле гомер итә.



**Тимерханова Бибихода Хабибулла кызы 1938нче елда Саба районы Иләбәр авылында туган.**

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 3 яшь була. Алар гаиләдә 4 бала булалар. Бибихода апа икенче бала. Әтисе сугышка китә. Сугыш беткәнче үк әтиләре сугыштан әйләнеп кайта. “Сугыш вакытындагы авырлыклар барлык кешеләргә дә эләкте инде. Кияргә кием, ашарга ризык булмады. Хәтта кычытканы да житәрлек булмады инде. Безнең читән буеннан күрше кызлары кычыткан жыйганны күргәч, йөгереп кереп әнигә: “Безнең кычытканны жыялар”,- дигәнмен дип, истәлекләре белән уртаклашты Бибихода апа.

Ул Иләбәр башлангыч мәктәбендә 4 класс, аннары Эзмә мәктәбендә 7 класс белем ала. Укып бетергәч колхозда торле эшләрдә эшли башлый. Аннан соң 2 ел фермада сыер сава.

1959нчы елда Өтернәс авылы егете Гильман белән тормыш коралар. Дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Гомере буе колхозда төрле эшләрдә эшләп, 1993нче елда лаеклы ялга чыга. Бүгенге көндә балаларының ярдәмен, күңел жылысын тоеп Өтернәс авылында гомер кичерә.



## Хажиева Мәнзүмә Салих кызы 1935нче елның 11нче январе көнне Саба районы Өтернәс авылында туган.

Сугыш башланганда аңа 6 яшь булган. Сугышның беренче көннәреннән үк әтисе Салих сугышка китә. Әнисенең итәгендә берсеннән – берсе кечкенә 5 бала кала. Тормыш авырлыклары көннән – көн күбрәк җилкәгә баса. “Ач тамак белән атлык, кычыткан җыю өчен ПМК болынына кадәр төшә идек. Без җыеп алып кайткач, шулардан әни аш пешереп бирә торган иде. Анда да бөтен кеше җыя торгач бетте”, - дип сөйли яшь аралаш Мәнзүмә апа. Әтиләре сугыш кырында үлеп кала, хәбәрсез югалганнар исемлегенә керә. Ә шулай да алар башта күңелләре белән әтиләрен кайтыр дип көтәләр.

Мәнзүмә Хажиева Өтернәс башлангыч мәктәбендә укып 4 класс белем ала. Алга таба уку өчен якын - тирәдә мәктәп булмый, Шекше мәктәбенә йөрергә ерак була. Аны Өтернәс конторасына табельщица итеп чакыралар. Буе да кечкенә булгач, башта анда эшли башларга ояла. Беренче тапкыр әнисе илтеп куя. Язуы матур була, шуңа күрә аңа иң беренче эш итеп сайлау исемлеге төзергә кушалар. Шулай эшли башлый ул. Өтернәстә контора ябылгач, Эзмәгә төшеп эшли башлый. Менә шул елларда Эзмәдә җидееллык мәктәп ачыла. Ул укуын дәвам итә һәм 7 класс белем ала. Мәктәп бетергәч колхозда төрле эштә эшли башлый. Аннан соң куяннар карарга керә.

1958нче елда Мәҗит исемле Өтернәс авылы егете белән гаилә корып матур гына яши башлыйлар. Гаиләләрен тулыландырып уллары Илшат һәм кызлары Гөлнәзирә туа. Әмма Мәнзүмә апага ир канаты астында, тигезлектә яшәргә язмаган икән шул. Үзе дә әтисез үскән кызның балалары да әтисез кала. Аның тормыш иптәше 1968нче елда каты авырудан соң үлеп китә.

Ул хезмәт юлын дәвам итеп, 6-7 ел тирәсе хуҗалыкта сөт җыючы булып, 20 ел колхоз ашханәсендә пешекче булып эшли. 1990нчы елда лаеклы ялга чыга. Аннан соң да 1995нче елга кадәр хезмәтен ашханәдә дәвам итә. Хезмәтен хөрмәтләп күп кенә Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

Язмыш аны тагын бер тапкыр сыный. Газиз баласы - улы Илшат та кисәк кенә авырып китә дә мәңгелеккә күзләрен йома. Бүгенге көндә тормышына шөкер итеп, Мәскәүдә гаиләсе белән яшәүче кызы Гөлнәзирә белән көн саен телефон аша аралашып яши.



**Тухватуллина (Хакимзянова) Хәлимә Ислам кызы 1939 нчы елның 24 нче январе көнне саба районы Олыяз авылында туган.**

Хәлимә апа сөйләгәннәрдән:

-Без гаиләдә 4 бала , ике апа һәм бер энем үстек. Миңа 2 яшь вакытта Бөек Ватан сугышы башлангана һәм әтием сугышка киткән. Шул китүдән ул башкача әйләнеп кайтмый. Мин әтине бөтенләй белмим. Гомере буе әтиле кешеләргә кызыгып яшәдем. Әтиле балалар безне кыерсыталар иде, “Безнең әти нигә юк соң?”- дип, елап кайтып әнинең йөрәген ничек яралаганыбызны үсә төшкәч кенә аңладым. Әни әйтүе буенча гына әтинең хәбәрсез югалганын беләм .

Олыяз мәктәбендә башлангыч белем алдым. Анда безне Зөлхәбирә апа укытты. Аннан соң Эзмәдә 6 класс бетердем. Минем класс житәкчем Мәрхәбә апа иде , безне Фәүзия апа Вахитова да укытты. Бала күңелен бик яхшы аңлый белүче укытучылар иде алар.

Сугыш еллары бик авыр булды. Ятим булгач, бик авырлык белән генә яшәдек. Житмәүчелек үзәккә үтте.

Үзем бала гына булсам да, Казанга бала карарга алып киттеләр, ике айны көчкә бик сагынып уздырдым да, әни хәл белергә килгәч, ияреп кайтып киттем.

Паспорт алгач Шәмәрдәнгә әртилгә эшкә кердем һәм анда 12 ел бик тырышып эшләдем.Фотосүрәтем гел Мактау тактасында гына торды. Энем армиягә, апаларым кияүгә киткәч, мин колхозга эшкә кайттым. 13 ел буе хужалыктан сөт жыючы булып эшләдем. Тормышка чыгып, 1 ул тәрбияләп үстердем. Әнине дә бик тәрбияләп карап соңгы юлга мин озаттым. Пенсиягә чыкканчы Киров исемендәге колхозда эшләдем.

Яшьлегемдә генә түгел, олыгайгач та авырлыклар читләтеп узмады мине. Ирем Лотфулла ике аягын да кистереп 6 ел яшәде. Аны да бер дә авырыксынмыйча карадым. Ул үлгәч, өч елдан бертуган энем Хәнәфи дә үлеп китте. Бу кайгыларны бик авыр кичердем. Хәзер инде үземнең дә сәламәтлегем мактанырлык түгел. Ярый әле улым Радик белән киленем Гөлсинә бар. Бүгенге көндә тормышлар бик әйбәт, йорт – жирләр яхшы, барысына шөкер итеп, хәер - дога кылып яшим.



**Шагинуров Рәфкать Шәймәрдан улы 1927нче елның 4нче декабрендә, элеккеге Яңа Чүриле районы Мөрәле авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килгән.**

Гаиләдәге биш баланың ул иң олысы була. Әтисе – Шагинуров Шәймәрданны Бөек Ватан сугышы башлангач та, 1941 нче елда ук сугышка алалар. Әниләре 5 баланы кочаклап елап кала. Йортта иң олы бала буларак, әнисенең төп терәге Рәфкать абый була. Барлык авыр эшләр дә аның җилкәсенә төшә.

Сеҗе урта мәктәбен тәмамлагач, Рәфкать абый Арча районының Үрнәк поселогында урнашкан педагогия училищесына укырга керә. Бу чорда педагогия училищесында укулар да бик авыр була. Сугыш чоры, ишле гаилә, ачлык, кияргә кием булмау үзен нык сиздерә. Шушы авырлыкларга да карамыйча педучилищены бары яхшы билгеләргә генә тәмамлый һәм 1944нче елны Арча районы Гөберчәк авылында башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли башлый. Анда 8 ел укыткач, иске Масра башлангыч мәктәбендә, аннан соң Иске Му мәктәбендә балалар укыта, шул ук вакытта мәктәп мөдире вазыйфасын да башкара.



Әтисе 1945нче елда сугыш беткәч, бик күп яралар белән контузия алып, авырып авылга кайта. Бераз тернәкләнгәннән соң колхозда эшли, тегү тегә. 1960нчы елның ноябрендә үлеп китә.

Шагинуров Рәфкать 1970нче елны гаиләсе белән Саба районы Эзмә авылына килеп урнаша. Башта Олыяз башлангыч мәктәбендә балаларга белем бирә. Соңрак Эзмә урта мәктәбендә лаеклы ялга чыкканчы балаларга хезмәт һәм физкультура дәресләрен укыта. Тормыш иптәше Гөлсем белән ике бала тәрбияләп үстерәләр.

2006нчы елның 9нчы апреле көнне вафат була. Эзмә авылы зиратына җирләнә.



**Хафизова Гөлсем Хафиз кызы 1935нче елның 21нче ноябрендә Арча районы Чөмә - Елга авылында гаиләдә 3нче бала булып дөньяга килә.**

Әтисе Сабиров Хафиз Сабирович 1908нче елгы. 1928нче елны Казан Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлый. 1928-1942нче елга кадәр Чөмә - Елга башлангыч мәктәбендә балаларга белем һәм тәрбия бирә. 1942нче елда Арча военкоматыннан №1057(257) номер тагып, Бөек Ватан сугышына китә. Сугыштан әйләнеп кайтмый. 1945нче елның 5нче январендә Венгрия республикасы Будапешт шәһәренән 5 км ераклыктагы Кабанье дигән авылда җирләнә.

Әнисе Сабирова Мәрьямбикә Чөмә - Елга авылында почта тарата. Дүрт баласына да югары белем бирә.

Гөлсем Хафизовна 1943нче елны 1нче класска укырга керә. 1950нче елда Сикертән җидееллык мәктәбен тәмамлый. Шул ук елны Арча педагогия училищесына укырга керә. 1953 нче елда педагогия училищесын тәмамлап, Саба районы Симет мәктәбендә укытучы булып хезмәт юлын башлый. Түлешкә, Шыңар,Курсабаш мәктәпләрендә дә балаларга белем бирә.



1970нче елда Рәфкать Шагинуров белән тормыш коралар һәм Эзмә авылына гаиләләре белән килеп урнашалар. Ике бала тәбияләп үстерәләр. Эзмә урта мәктәбендә лаеклы ялга чыкканчы балаларга тарих фәне укыта.

2015нче елның 15нче маенда вафат була. Эзмә авылы зиратына җирләнә.



**Шәяхмәтов Муса Галиәхмәт улы 1936нчы елның 22нче феврале көнне Саба районы Эзмә авылында семьяда икенче бала булып дөньяга килә.**

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа биш, апасы Гөлфәриягә сигез, ә энесе Миннәхмәткә өч яшь булган. Әтиләре Галиәхмәтне сугышның беренче көннәреннән үк фронтка алалар. Менә шулай тормыш йөген сабый вакытыннан ук тарта башлый ул.1942нче елда әтиләреннән "Батырларча һәлак булды" дигән кара пичәтле хат килгәч тормыш тагын да авырайган кебек була. Ачтан үлмәс өчен туганнары белән бергә өшегән бәрәңге, кычыткан, алабута, ашарга яраклы үләннәр җыеп алып кайталар да әниләре шуннан аш, күмәч пешерә торган була.

1943нче елда Муса абый беренче сыйныфка укырга керә. Әмма ул, көннәр суыткач, аяк киеме булмаганлыктан, дәресләргә йөри алмый башлый. Шулай итеп, аңа беренче класста ике ел укырга туры килә. Аның уку теләге шундый көчле була, ул урта белем алганчы укый. Соңрак читтән торып Минзәлә совхоз техникумына да керә, әмма яшьтән өйрәнгән хезмәте булгангадыр, тимерчелектән аерылмый. Алтмыш яшенә кадәр колхозда тимерчелектә хезмәт куя.

1958 нче елда Саба кызы Флера белән тормыш корып җибәрәләр. Өч кыз бала тәрбияләп үстерәләр. Алар төп йортта әниләре Мәүлиха әбине зурлап, туганнарны хөрмәтләп матур парлар булып яшиләр.



Муса абый пенсиягә чыккач та үзенә файдалы шөгыль таба. Теләсә кайда аунап яткан тимер чыбыклар җыеп, шулардан чылбырлар ясап якын - тирә колхозларга тапшыра.

Һәрвакыт яшәүнең ямен, тормышның кадерен белеп яши. Вакытын бушка уздырмый, бакчачылык белән шөгыльләнеп туганнарга, күрше – тирәләргә дә җитәрлек яшелчә, чәчәк орлыклары әзерли, тагын бер яраткан шөгыле балыкчылык. Парлап матур итеп концерт – театрларга йөрергә яраталар. Менә шулай матур гына яшәп ятканда кисәк авырту аны мәңгелек йортка алып китә .

Муса Шәяхмәтов 2008нче елның 22 нче январе көнне вафат була, Эзмә авылы зиратына җирләнә.





**Нурисламова(Маликова) Флера Гомәр кызы - Арча районы Курса авылында 1939нчы елның 8нче сентябрендә гаиләдә 5 нче бала булып дөньяга килә.**

Әтисе Гомәр,әнисе Фәсәхәт, тагын 6 туганы белән, табигатьнең иң матур төбәге Курсада 1946нчы елга кадәр тырыш, күршеләренә ярдәмчел гаилә булып яшиләр.

Бөек Ватан сугышы башланганда минем әбиемә 2 яшь була. Әбиемнең гаиләсеннән сугышта катнашучы булмаса да, илгә килгән афәт,авыр томыш авылдашларының, туганнарының әйтеп бетермәслек хәсрәте аларның да күңелләрендә авыр кичерешләр,тирән яралар калдырган.

1946нчы ел.Сугыштан соңгы авыр еллар. Әбиемнең хәтерендә бу еллар тирән уелып калган.Аларның әтиләре Гомәр Маликовны туган авылларыннан аерып, Саба районы Эзмә авылына колхоз рәисе итеп җибәрәләр. Алар Арча районы Курса авылыннан бирегә берсеннән-берсе яшь 7 бала белән күченеп киләләр.Чит җир,таныш түгел кешеләр,яңа тормыш...

- Курсада без, ничектер, әйбәтрәк яши идек. Йорт-җиребез дә начар түгел иде. Эзмә авылының ул еллардагы ярлылыгын, тормыш шартларының авырлыгын сөйләп аңлатырга сүзләр җитми. Ул вакытта, минем 8 яшьлек бала башына, ачтан үлмәсәк ярар иде дигән уйлар килде ,-дип искә ала әбием сабый чакларын.

Еллар уза.Шул елларга үрелеп гомер уза. Әбием һәм аның гаиләсе өчен Эзмә туган авылларына әйләнә.Әбиемнең 6 туганы язмышларын чит җирләр белән бәйлиләр, ә аның башына һичбер вакыт шәһәргә китәм дигән уй кереп карамый.

-Мин дә китеп барсам,сезне кем каршы алып кунак итәр,-ди ул туганнарына. Чыннан да, аның бу сүзләре фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килә. Ул үзенә үзе кебек уңган, иң булган, иң чибәр егет, минем бабаем Мәсгүтне яр итеп сайлый. Әби белән бабай өч бала үстерәләр. Аларның уңышына,тормышта үз урыннарын тапканнарына сөенеп, парлы тормыш кичерәләр.

Әбиемнең хезмәт кенәгәсе төрле эшләр белән чуарланмаган. Мәктәпне яхшы билгеләренә тәмамлаганнан соң, 20 ел хат ташучы булып эшли. Ул чын

мәгънәсендә авылдашлары арасында акыл,тәртип белән яшәп бәхетле тормыш алып бара. Эш сәгатендә хезмәт дисциплинасын саклау-аның өчен яшәү нормасының иң мөһим таләбе булып тора. Гомумән, минем әбием чын-чынлап үз эшенә гашыйк кеше.1979 елда ул моның шулай икәнлегенә тәмам ышана.Ул, мөмкинлек булгач, мәктәп ашханәсенә эшкә күчә.Хезмәт хакы да артыграк, эш сәгате дә кыскарак.Әмма нинди генә өстенлекләре булса да, аның күңеле бу эшкә ятмый. Бер ел эшләгәннән соң, башкача йөрәген җаны сөймәгән хезмәтне башкарырга буйсындыра алмый. Кире элемтә бүлегенә кайта.Газета-журналлар, хатлар белән тулган сумкасын асып таныш урамнар буйлап атлый. Нинди генә каршылыклар белән очрашса да, ул хакыйкатьне исеннән чыгармый.

Кешеләр белән уртак тел табып эшләвен, үз эшенә бик җаваплы каравын, вакыт белән исәпләшмәвен истә тотып 1980нче елны аны элемтә бүлеге җитәкчесе итеп билгелиләр. Элемтә күп төрле вак эшләрдән тора. Һәм бу хезмәтләрнең барысы да кешеләр белән бәйле. Әбием тулы бер хезмәт юлын кешеләр белән көн саен аралашып, аларның элемтә бүлегенә кагылышлы проблемаларын хәл итәргә ярдәм итеп 15 ел Эзмә элемтә бүлеге җитәкчесе вазыйфасын башкарган. Аны авылдашлары, пенсиягә чыккач та, һәрвакыт үз итеп “почта Флера”дип сөйләшәләр. Башкарган хезмәтенең нәтиҗәсе булып дистәләгән “Мактау кәгазләре, “Почет грамоталары”, ”Хезмәт ветераны” таныклыгы , Рәхмәт хатлары саклана.



Бүгенге көндә әбием бик бәхетле,чөнки янәшәсендә 55 ел иңне - иңгә куеп тормыш арбасын аудармыйча, шатлыкларны, борчу-хәсрәтләрне бергә кичергән бабам бар. Яшәү яме-балалары исән-сау, без-оныкларының уңышларына сөенеп, тормышыбызның муллыгына, илебезнең тынычлыгына шөкер итеп яши.

*Апрель, 2017*

*Язманы оныгы Мирзина Зәлия Генар кызы әзерләде.*



**Гыйльманова Гөлчирә Гасим кызы 1940нчы елның 22нче декаберендә Теләче районы Түбән Саурыш авылында туган.**

Гөлчирә апа сөйләгәннәрдән: Әтием Гасыйм 1941нче елда ук сугышка киткән. Мин алты айлык бала бишектә калганмын. Әнием һәм әбием тәрбиясендә үстем. “Әти” сүзен әйтүләр миңа насыйп булмады. Чөнки ул сугышта үлеп калган. Кечкенә чакта күктә самолет очканы күренсә: “Әтине алып кайт, минем әтиемә сәлам әйт”, – дип кул болгап кычкырып калганнарым хәтеремдә хәзер дә саклана.

Үзебезнең авыл мәктәбендә 4 класс белем алдым да, укуымны күрше Төбәк авылында дәвам итеп, җиде класс белем алдым. Укыганда ук җәйге чорларда өлкәннәр белән төрле эшләргә йөри идек. Амбарда да эшләдек. Ә укып чыккач сарык фермасында эшләдем. Көннәр шулай бер – бер артлы үтә торды.

1961нче елда Саба районы Иләбәр авылы егете Гыйльманов Сәетнур белән тормыш кордык. Бик акыллы, тәртипле тормыш юлдашым белән 53 ел бергә гомер иттек. Биш бала – 1 кыз, 4 ул тәрбияләп үстердек. Улларыбыз дүртесе дә Ватан алдындагы изге бурычларын үтәп кайттылар. Механизатор булып эшлиләр. Үзем 1962нче елдан лаеклы ялга чыкканчы сыер савучы булып эшләдем. Без эшләгәндә күп эш кул хезмәте белән башкарыла иде. Эшне бик яратып башкардым. Хезмәтемне югары бәяләделәр, Мактау кәгазьләре, дипломнар белән бүләкләндем. Хезмәт ветераны исеменә лаек булдым. Ирем 45 ел шофер булып эшләде, ерак юлларга йөрде. Әнкәй белән 28 ел бергә дус-тату яшәдек. Без гел эштә булдык, тормышта ул төп терәк булды, балаларны бик әйбәтләп карап үстереште.

Алтын туйны да күрергә насыйп булды . Әмма тигезлектә яшәп бетерергә язмаган шул безгә. Тормыш иптәшем 2014нче елның 5нче августында бакыйлыкка күчте. Урыны оҗмахта булсын.

Моннан соң сугышлар булмасын, балалар ятимлектә үсмәсен. Барлык халыкка да тыныч, мул тормышта яшәргә язсын.

*Апрель, 2017*

Һәр яз безгә Бөек Җиңү бәйрәмен алып килә. Кызганычка каршы, бәйрәмне каршылаучы сугыш һәм тыл ветераннары елдан-ел кими, инде сугыш чоры балаларының да күбесе арабызда юк...

Безнең газизләребез – **әниебез Гафифә Гайнетдин кызы, әтиебез Вәгыйз Мөбарәк улы Мөбәрәковлар** да, үзләре хакында иң матур хатирәләр генә калдырып, туган як халкына күп игелекләр кылып, бакыйлыкка күчкән сугыш чоры балалары.



Алар икесе дә Саба районының Өтернәс авылында туып-үсеп, гомерләрен шушы төбәктә уздырган кешеләр.

Әниебез 1937 елның 1нче октябрендә дөньяга килгән. Ул – гаиләдәге икенче бала. 1935нче елда туган Нурулла абыйсына сеңел, 1941нче елда туган энесе Исламга – апа. Бабалары Баһаветдин, әбиләре Мәгърифә, әтиләре Гайнетдин, әниләре Миңзифа, әтиләре Гайнетдиннең бертуган сеңелесе Назыйфа һәм өч бала. Менә шундый тулы, матур, бик тырыш гаиләдә туган әниебез. Кызганычка каршы, башланып киткән Бөек Ватан сугышы, аларның тормышына бик зур авырлыклар, хәсрәтләр алып килә. Гайнетдин бабай сугышның беренче көннәреннән үк фронтка алына һәм, озак та үтми, Ленинград фронтында хәбәрсез югала. Әниебез Гафифәгә сугыш башланганда әле 4 яшь тә тулмаган булган. Ул исән вакытында “Мин әтине бөтенләй дә хәтерәмим”, дип әйтә иде. Сугыш чорының авырлыкларын, иписез, ягарга утынсыз тормышны, кичергән михнәтләрен әниебез йөрәк ачысы белән безгә сөйли иде:

“Яз җиту белән Шекше болынына үлән җыярга йөгерә идек. Чөнки үзебезнең авылда инде бер генә кычыткан, бер генә ашарга яраклы үлән дә калмаган, өлгергән кеше инде аларны җыеп бетергән, ә ерактагы болында әле үләннәргә кагылган кеше юк. Анда күп итеп үлән җыябыз да, кайткач алардан йомарлыклар ясап, базга төшереп куябыз. Алардан безгә әни аш пешереп ашата. Җәй буе, сыер җигеп Олыяз урманыннан бабай белән печән ташыйбыз.”

Әниләре Миңзифа көннәр буе колхоз эшендә. Бервакыт, язгы ташу чорында, Клара исемле иптәш кызы белән яр буенда уйнап йөргәндә, ул ташу суына агып киткән. 6 яшь чамасы булган аңа ул вакытта. “Агып барган чагымда, тизрәк үлсәм ярар иде, дигән уй килде башыма”. Ләкин иптәш кызы бик чая булып чыккан, ул абыйсын чакырып китереп, әниебезне елганың бер борылышында багор белән тартып алганнар. “Аннан соң җылы мич башында ятканымны гына хәтерлим”, дип сөйли иде әни. Үзенең нинди хикмәт белән исән калганлыгына шакката иде. Әлбәттә, аның исәнлеге өчен өйдәгеләр бик борчылышканнар. Чөнки, шушы вакыйга алдыннан гына, әтисенең апасы Назыйфа, окоп казырга җибәрелеп, аннан бик каты салкын тидереп кайтып, егерме бер яшендә вафат булган.

Беренче класска укырга барганда, ул инде укый-яза белә, сыйныфташларына да булыша. Өтернәс башлангыч мәктәбен бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый. “Минем тырышлыгымны бәяләп, укытучым миңа мәктәп формасы тегәргә тукыма бүләк итте. Ул вакыттагы сөенечемне сөйләп-аңлатып кына бирерлек тә түгел.”

Язарга дәфтәр, кәгазь таба алмыйча интегүләрен дә сөйли иде әни. Күршеләрендә генә бер буш йортта шәһәрдән эвакуацияләнеп кайткан рус гаиләсе яшәгән. Шулар Яңа ел алдыннан тәрәзә төпләрен ялтыравык кәгазьләр белән бизәгәннәр. Мондый әйберне гомерендә дә күрмәгән авыл баласы – әниебез – бу хикмәтне күреп шаккаткан.

... Ул 1952 нче елны Эзмә җидееллык мәктәбен бишле билгеләренә генә тәмамлый. Әниебез рус теле һәм әдәбияты укытучысы Рәйсә апа Камалованы бик хөрмәт итә. Һәм үзе дә укытучы булу теләге белән, шул ук елны Арча педагогия көллиятенә укырга керә. Монда да бик тырышып укып, уку йортын кызыл диплом белән тәмамлый.

Без бит инде әниебезнең биографиясен генә язмыйбыз, ә сугыш чоры балалары кичергән авырлыкларны да чагылдырабыз. Шуңа күрә, әниебезнең Арчада укыган чорлары турында да кыскача гына булса да, аның үз сүзләре белән әйтеп үтәсебез килә: “Монда да ачлык, ялангачлык, ягылмаган салкын квартира. Өсләребездә телогрейка, бер-ике кызның гына пальтосы бар. Мунча, чәчне юарга йомырка табу – зур проблема. Өйгә кайту бик сирәк эләгә, чөнки пассажир поездлары юк. Товар вагонына утырып, Шәмәрдән станциясендә поезддан сикереп төшеп калабыз. Аяклар ничек чыдагандыр, егылып, оеклар ертылып, тезләр канап бетә иде.”

Аннан соң әниебез читтән торып, педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Үтә сабыр холыклы, шул ук вакытта таләпчән әниебезнең балаларга багышланган гомере Эзмә мәктәбендә узды. Балаларга рус теленнән белем бирүдә сәләтен һәм вакытын кызганмады ул. Тырышлыгы, фидакарь хезмәте өчен "Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы”, “Укытучы-методист” дигән мактаулы исемнәргә, РСФСР Мәгариф министрлыгы грамоталарына лаек булды. Рус теле кабинетын даими яңартып, һәрвакыт призлы урыннар яулады.



Мәктәптә үрнәк укытучы булса, ул безнең өчен искиткеч әни булды. Кул эшләренә, аш-суга, бакча эшләренә бик оста, гомумән, бик уңган хуҗабикә булды ул. Әби-бабаебызны кадерләп тәрбияләп, соңгы юлга озатты. Без аның бер генә минутын да бушка уздырганын хәтерләмибез. Хәтта, көтүгә чыккан җиреннән дә, ул бер-ике пар оекбаш бәйләп кайта иде.

Әниебезне аны белгән барлык кеше дә хөрмәт итә иде. Аны хәзер дә авылдашлар, туганнар, хезмәттәшләре сагынып искә алалар, аның рухына догалар кылалар...

Әтиебез Вәгыйз 1934нче елның 19нчы августында туган. Ул да сугыш чоры авырлыкларын үз җилкәсендә татыган кеше. Әтиебез сөйләгәннәрдән: “Ашарга җитмәгәнлектәндер инде, минем буем бик кечкенә иде. Озынрак булып күренер өчен, аяк киеме эченә агач шакмаклар куеп, киеп йөрим. Әти сугышта. Әни кайчакларда, бераз акча юнәтү өчен, каяндыр он табып, кабартма пешерә дә, мине Шәмәрдәнгә шуларны сатарга җибәрә. Ничек оялмыйча саттым икән, кеп-кечена килеш, шул кабартмаларны?! Үзебезгә ашарга елгадан балык тотып кайта идек Солтан (бертуган абыйсы) белән.”

Әтиләр гаиләдә дүрт малай үскәннәр. Әти - иң төпчеге. Ул 1942нче елда Өтернәс башлангыч мәктәбенә укырга кереп, анда белем ала. Соңыннан 1953нче елда Саба урта мәктәбен тәмамлый. 1954-1957нче елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Әтиебез яшь вакытында гади шофёр булып та, клубта художество җитәкчесе булып та эшләгән. Аның да уку теләге бик көчле булган һәм ул 1958нче елда Казан авиация институтына укырга керә, аны 1965нче елда уңышлы тәмамлап, диплом ала.

1967 елдан ул Эзмә мәктәбендә физика фәнен укыта башлый.



1969нчы елның августында аны шушы мәктәпнең директоры итеп билгелиләр. Әтиебез мәктәп өчен бик тырышты. Ягулык системасын үзгәртү, сыйныфларда ремонт, яңа җиһазлар кайтару, чөгендер игү звеносы булдыру һәм чөгендердән зур уңыш алып, мәктәпкә трактор кайтарту, мәктәп территориясен гел чисталыкта тоту, күп итеп чәчәкләр үстерү – болар барысы да аның башлангычында башкарылган эшләр. Иң мөһиме – дус, көчле укытучылар коллективы туплау.

Кирәк вакытта уен-көлке белән, кайвакыт кырыслыгы белән, ул үзенең фикерен укытучыларга да, укучыларына да җиткерә белде. Укытучылар коллективының һәм укучыларының зур ихтирамын казанды.

Әтиебез безне көчле булырга, авырлыклар алдында бирешмәскә, намуслы булырга, үз мисалында хезмәтне сөяргә өйрәтте. Без аның да өебездә вакытын бушка уздырганын күрмәдек. Ул умарталар тотты, бал кортларын бик ярата иде. “Пчеловодство” журналы алдырып, андагы һәр яңалыкны үзендә булдырырга тырыша иде. Алмагачларны бик яратты, аларга һәр көн күпләп су сибә иде...

Менә шундый алар – сугыш чоры балалары, безнең кадерле әти-әниләребез. Рәхмәт сезгә, күпме авырлыклар күреп тә, олы йөрәкле һәм чын Кешеләр булып калганыгыз өчен! Өтернәстә тугансыз, мәңгелек йортыгыз да туган авылыгызда. Тыныч йоклагыз, урыннарыгыз җәннәттә булсын!

*Сезне бер генә көн дә истән чыгармаучы балаларыгыз: кызларыгыз Наилә, Земфира, улыгыз Илгиз.* *Апрель, 2017 ел*



**Гайнетдинова (Закирова) Флюра Галиевна 1938нче елның 3нче июлендә Әгерҗе районы Түбән Кучуково авылында туган.**

Алар гаиләдә ике бала булалар. Сеңлесе - Флүсә 1940нчы елда туган. Сугыш башлану белән әтиләрен фронтка алалар. Балалар бәхетеннәндер инде, ул фронттан исән – сау әйләнеп кайта.

Флюра апа мәктәпне тәмамлагач, 1956-1969нчы елларда Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында укый.

1965нче елда В.И.Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетын тәмамлый.

1959-1963нче елларда Саба районы “Игенче” колхозында зоотехник булып эшли.

1963-1976нчы елларда Эзмә сигезьеллык мәктәбендә башлангыч сыйныф укучыларының рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

1967-1974нче елларда Тимершык сигезьеллык мәктәбендә укытучы булып эшли.

1974-1977 нче елларда Олыяз башлангыч мәктәбендә укытучы булып эшли.

1977-1993нче елларда Эзмә урта мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли.

1993нче елда лаеклы ялга чыга. “Хезмәт ветераны” исеменә лаек була.

Тормыш иптәше Гайнетдинов Нурулла белән Өтернәс авылында гомер итәләр. Өч бала тәрбияләп үстерәләр.

Флюра апа 2014нче елның 12нче декаберендә вафат була. Өтернәс авылы зиратына җирләнә.



**Гайнетдинов Нурулла Гайнетдин улы 1935нче елның 10нчы августында Саба районы Өтернәс авылында туган.**

Алар гаиләдә өч бала үсәләр: 1938нче елда туган сеңлесе – Гафифә һәм 1941нче елда туган энесе – Ислам. Әтиләр сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китеп бара һәм шул ук елны үлү турындагы хәбәре килә.

1953нче елда хезмәт юлын “ Транссигналсвязстрой”да монтер булып башлый.

1954-1957нче елларда ул Ватан алдындагы бурычын үтәп, Германиядә хәрби хезмәттә булып кайта.

1957-1963нче елларда Эзмә сигезьеллык мәктәбендә хезмәт укытучысы.

1963-1965нче елларда Эзмә сигезьеллык мәктәбендә директор.

1965-1967нче елларда Эзмә сигезьеллык мәктәбендә математика укытучысы.

1967-1974нче елларда Тимершык сигезьеллык мәктәбендә директор.

1974-1975нче елларда Шәмәрдән урта мәктәбендә директор.

1975- 1976нче елларда Эзмә сигезьеллык мәктәбендә хезмәт укытучысы.

1976-1984нче елларда Эзмә авыл советы рәисе.

1984-1994нче елларда хезмәт куркынычсызлыгы буенча инженер.

Хөкүмәт тарафыннан бирелгән бүләкләре: “Отличный связист” значогы, “Хезмәт ветераны” исеме.

Өтернәс авылында тормыш иптәше Гайнетдинова Флюра белән гомер итәләр. Өч бала тәрбияләп үстерәләр.

2011нче елдның 13нче декабрендә вафат була. Өтернәс авылы зиратына җирләнә.

## Аскаров Миннехуҗа Миннехан улы 1940нчы елның 1нче гыйнварында Саба районы Олыяз авылында туган.

Олыяз башлангыч мәктәбендә дүрт класс белем алган.

Авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт куйган. 1970нче елда тормыш корган. Балалары булмаган. Бүгенге көндә тормыш иптәше инде вафат.

Миннехуҗа абый  Олыяз авылында ерак туганнары тәрбиясендә яши.

**Гыйлфанов Рашат Гыйлфан улы, 1942 елның 5 гыйнварында Саба районы Олыяз авылында, әнисен, апасын куандырып дөньяга аваз салган.**

Разыя һәм Лотфулла Заһидуллиннар гаиләсе сугыш башланганда Ташкент шәһәрендә яши. Лотфулла абый да башкалар кебек армия сафларына чакырыла. Бер – берсен өзелеп яраткан, гомер буе янәшә атлыйсы бу гүзәл парны сугыш аера. Ирен озаткан Разыя апага олы кызы – Мәрьям һәм әле дөньяга тумаган сабые бу авыр көннәрдә зур таяныч була. Ул озак та уйлап тормый туган якларына, Олыяз авылына кайтып китә.
Разыя апа бик авырлык белән тормышны алып барган. Аңа апасы Мәрхәп бик ярдәм иткән. Хуҗалыкта булышкан, балаларны карашкан. Рашат абыйга фамилиясе, атасы исеме итеп тә менә шул Мәрхәп апаның ире исемен язалар. Ул аларның яраткан энеләре була. Сугыш тәмамлангач Разыя апа ике баланы алып кабат Ташкент якларына, ире кайтыр дигән ышаныч белән китә. Аның зур өметләре акланмый. Иреннән бер хәбәр дә булмый. Яшь ана ике баланы да балалар бакчасына бирә, үзе көне буе балаларны тук яшәтү өчен зур тырышлык куя. Сугыштан соңгы авыр еллар Ташкент шәһәрендә урап узмый. Яшәү тагы да кыенлаша. Разыя апа ике баланы алып кабат туган якларына юл тота.
Кайткан елны Рашат абый Олыяз башлангыч мәктәбенә укырга керә. Башлангыч белемне алгач укуын Эзмә урта мәктәбендә дәвам итә. 7 сыйныфны тәмамлагач ул сарык фермасына эшкә бара. Ул бочкалар белән сарыкларга су ташый. Сау – сәламәт егетне военкомат Кукмарага автомәктәпкә укырга җибәрә. Ул анда шофёр һөнәрен үзләштерә. 18 яше тулгач Рашат абыйны Совет Армиясе сафларына алалар. Ул Чиләбе өлкәсе Злато-Усь шәһәрендә 3 ел хезмәт итә. Яхшы хезмәте өчен аңа мактау кәгазьләре тапшыралар.
Армия сафларан намус белән хезмәт итеп Рашат абый туган авылына кайта һәм колхозга эшкә керә. Озак еллар сөт машинасында эшли, җитәкчеләрне йөртә. Һәр кушкан эшне җиренә җиткереп башкара.
Рашат абый 1967 елның 4 ноябрендэ тормыш иптәше Рәйсә апа белән гаилә коралар. Быел аларның бергә яши башлауларына 50 ел. Тормыштагы авырлыкларга сынмый – сыгылмый яшәүче әлеге пар бер ул, бер кыз үстерәләр. Бүгенге көндә балалар, оныклар бәхетенә куанып гомер итәләр.
- Рашат абый, синең нинди теләкләрең, киңәшләрең бар?- диеп сорадым мин аннан.
Ул:- Без бәрәңге басуыннан черек бәрәңге, кырдан башак җыеп тамак туйдырдык. Әле аны да агуланасыз дип җыйдырмыйлар иде. Бүгенге тормыш - ул җәннәт. Мин тормышымнан, аллага шокер, бик канәгать. Илебез күге гел аяз булсын, сугышлар булмасын! Быел 75 яшемне тутырдым һәм гомерем буе әти диеп әйтергә тилмереп яшәдем. Әтиле кешеләргә карап ак көнләшү белән көнләштем. Шуңа да иң зур теләкләремнең тагы берсе, балалар ятимлек ачысын тоймасын, эти дип, әни дип тулы гаиләдә яшәсен, үссен,- диде.
Чыннан да, сугыш вакытындагы авырлыкны башка күрергә язмасын. Һәркем бәрәкәтле, мул тормышларда гомер итсен иде.

# Бу альбомны Саба район ветераннар советы рәисе Сабиров Расих Хәсән улы җитәкчелегендә Саба муниципаль районы Эзмә урта гомумбелем бирү мәктәбе коллективы эшләде

2016 - 2017

***Алар сабый чакта ук ятим калган, “әти” сүзен әйтергә тилмереп яшәгән, бәхетле балачакларын сугыш урлаган авылдашларыбыз. Без аларны сугыш чоры балалары дип йөртәбез. Бик яшь килеш коточкыч сугышның ачы хәсрәтен үз җилкәләрендә татыган сабыр йөрәкләр шул алар. Аларның кайберләре әтиләрен бер күргәндер. Кайберләре, кечкенә булу сәбәпле, әтисенең йөзен дә хәтерләмидер, ә кайберләре әтиләре һәлак булганда хәтта тумаган да булгандыр... Алар ана назын да бик аз татыган, чөнки бөтен тормыш йөге тылдагы хатын-кызлар җилкәсендә булган бит.***

***Әйе, сугыш сабыйларга да ир-егетләр җаваплыгы салган. Бераз кул арасына керә башлаган малайлар, кызлар өлкәннәр белән беррәттән хезмәт иткән. Сугыш гарасаты тынганнан соң байтак еллар үтсә дә, аларның югалту ачылары бик ачы, яралары һаман ачык, күз яшьләре бик кайнар әле… Без тарих итеп тыңлаган хикәятләр дә аларның үз башларыннан үткән хатирә бит.***

***Әтиләре сугышып йөргән чакта***
***Аларның яңа туган елы булган.***
***Капчык аскан егермеләп хатын***
***Басуларга кайтып егылган.***
***Тәпи йөрер-йөрмәс бала-чага***
***Бураздадан билчән утаган.***
***Илгә – икмәк, авыл үзе өчен***
***Көлчә салган алабутадан.***
***Бер бәләкәй көлтә ега алган***
***Ул елларның хуҗасын.***
***Олылар кебек күтәргән бит шулар***
***Ил хәсрәтен, Ватан нужасын.***

***Сынаган сезне бу дөнья! Утларына салып яндырса да, бозларына салып туңдырса да сындырмаган, шөкер, бу дөнья! Туйдырмаган ләкин бу дөнья! Ә бит сындырырдай итеп сынаган…***

***Һәр өченче малай һәм кыз баланың әтисе, Ватанны фашизм коллыгыннан саклап, яу кырында ятып калган. Әлбәттә, бүген моны – ач калган һәм ятим балаларның ул чактагы хәлен-халәтен аңлавы кыен.***

***Шулай сугыштан соң да аталы балалар ата-ананың тигез канаты астында җылыга коенганда, алар сыңар канат астында «әти» дип әйтергә тилмергән. Япь - яшь килеш канатлары каерылган чибәр хатыннар солдат ирләренә булган мәхәббәтне гаҗәеп тугрылыкны соңгы сулышларынача саклаганнар. Аларны сагынып яшәгәннәр. Шул хисләрне балаларына да күчергәннәр. Сугыш чоры әниләре һәм сугыш чоры балалары – алар бүтән. Тормыш кыйммәтләрен алар башкача аңлый. Алар һаман көтеп яши.***

***Сезгә тыныч картлык, һәм тәүфыйклы оныклар телисе килә. Тагын күп еллар безне дә, якыннарыгызны да сөендереп яшәгез әле, яшәгез!***

***Гомерләребез сезнең дә безнең дә озын булсын,***
***Имин булсын иде дөнья –йортларыбыз,***
***Беркайчан да сүнмәсеннәр иде***
***Тәрәзәләрдә янган утларыбыз.***